ISSN 2618-9623

Төбәк тарихы буенча журнал

Краеведческий журнал

# Туган җир

# Родной край

2*2022


БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ
Татарстан Республикасы · Казан '92

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр
җәмгыяте

# ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

**2*2022**

Казан – 2022

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

# РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

**2*2022**

Казань – 2022

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

**Баш мөхәррир:**
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

**Web-редактор:**
Гарифуллин Илнар Зөлфәт улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Баш мөхәррир урынбасары:**
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Редакцион коллегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Габдрафиков Илдар
Гыйләҗев Искәндәр
Закиров Ринат
Измайлов Искәндәр
Салихов Радик
Ситдиков Айрат
Сафин Фаил
Тычинских Зәйтүнә
Хисамов Олег
Шәйдуллин Рафаил

**Редакцион-нәшер итү төркеме**
***Җаваплы сәркатип:***
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
***Корректор:***
Фәйзуллина Дания Илдус кызы

**Басманың адресы:**
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

**Главный редактор:**
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

**Web-редактор:**
Гарифуллин Ильнар Зульфатович,
кандидат исторических наук

**Заместитель главного редактора:**
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

**Редколлегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Салихов Радик
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ринат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зайтуна
Хисамов Олег
Шайдуллин Рафаиль

**Редакционно-издательская группа**
***Ответственный секретарь:***
Сагидуллина Мунира Халимовна
***Корректор:***
Файзуллина Дания Ильдусовна

**Адрес издания:**
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

**Туган җир:** Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал]. №2. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2022.

## Эчтәлек

Бөтендөнья татар конгрессы турында. ....................................................8

***Бөтендөнья татар конгрессына – 30 ел***

*И.Р. Таһиров.*
Гомумтатар оешмасының беренче адымнары. ........................................10
*Р.С. Вәлиев.*
Барлык юллар Казанга илткәндә... ..........................................................19
*Ф.Ә. Бәйрәмова.*
Татар конгрессы: оешу тарихы, сәбәпләре һәм нәтиҗәсе. ....................32
*Ф.А. Рәшитов.*
Конгресс татарның татарлыгын раслап, дөньяга чыгарды. ...................40
*Р.З. Закиров.*
Олы юлның узганы... ..................................................................................52

***Россия Федерациясе төбәкләрендәге милли оешмалар сөйли***

*И.М. Галәүтдинов, А.И. Минастинова.*
«Дуслык» Самара төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы тарихы. ................64
*А.Т. Шакиров.*
Марий Эл Республикасы татарлары. .......................................................71
*Ф.Ш. Гайсаров.*
Рухи күтәрелеш чоры. ...............................................................................75
*И.З. Гарифуллин.*
Башкортостан татарлары оешмалары: тарихы, хәзерге халәте һәм
саклану шартлары. .....................................................................................83
*И.Г. Миннемуллин.*
Удмуртиянең Татар иҗтимагый үзәгенә – 30 ел. ...................................91
*Р.И. Габбасова.*
Удмуртия татар төбәк милли-мәдәни автономиясе эшчәнлеге. ...........100
*С.Н. Назин.*
Без бергә. ...................................................................................................104
*З.А. Тычинских.*
Төмән өлкәсе татар иҗтимагый оешмалары. ........................................112
*Р.М. Сайганова.*
Омск өлкәсе татар иҗтимагый оешмалары эшчәнлеге. ........................129
*Ф.Ш. Мохтасаров.*
Мәскәү өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте иҗтимагый оешмасы. .145

***Чит илләрдәге татар оешмалары турында***

*Л.Р. Кутеева.*
Татар рухының кыйтгаларда чагылышы. ..............................................156

*Ю. Шамилуглы.*
Татарның космополит югары мәдәнияте һәм Бөтендөнья татар конгрессы. ....................171
*З.И. Канапацкая.*
XX гасыр – XXI гасыр башларында беларусь татарларының милли-дини күтәрелеше. .................... 178

**_Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр_**

*Н.В. Бекиров.*
Кырым татарлары: соңгы йөз ел (ахыры). ....................192

**_Төбәк тарихына караган тарихи чыганаклар_**

Бөтендөнья татар конгрессының 1992-нче елгы карары. ....................207
Дөнья халыкларына һәм дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Бөтендөнья татар конгрессы мөрәҗәгате. 1992 ел. .........209
XXI гасырда татар милләтен үстерү концепциясен формалаштырып («Татарский квадрат. Татар шакмагы» клубы утырышлары материаллары). I кисәк. ....................210

**_Шәхесләребез_**

*Р.Ф. Гатауллин.*
Рәсми булмаган, Мәхмүт Исхак улы Такумбетов турында. ....................221

**_Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар_**

Хроника ....................225

**_Милли ашлар, сәламәтлекне саклау юллары_**

*Д.И. Фәйзуллина.*
Гөбәдия. Корт. ....................230
*Г.А. Вәлиева.*
Өй печеньесы. ....................231

**_Юбилярлар турында сүз_**

*Ф.З. Мусин.*
Мәүлизә Гомәрова: Бәхетлеләрнең бәйрәме күбрәк була. ....................232
*З.Ә. Тычинских.*
Себер татарларының танылган шәхесе. ....................241

**_Авторлар буенча белешмә_**

## Содержание

О Всемирном конгрессе татар. ....................................................................8

### *30-летие Всемирного конгресса татар*

*И.Р. Тагиров.*
Первые шаги общетатарской организации. ...............................................10
*Р.С. Валиев.*
Когда все пути ведут в Казань... ..........................................................19
*Ф.А. Байрамова.*
Татарский конгресс: история создания, причины и последствия. .........32
*Ф.А. Рашитов.*
Конгресс подтвердил татарство татар и явил миру. ................................40
*Р.З. Закиров.*
Дорогой длинною... ..............................................................................52

### *Рассказывают татарские организации Российской Федерации*

*И.М. Галяутдинов, А.И. Минастинова.*
История Самарской региональной творческой общественной организации «Дуслык» («Дружба»). ...........................................................64
*А.Т. Шакиров.*
Татары Республики Марий Эл. ...............................................................71
*Ф.Ш. Гайсаров.*
Эпоха духовного возрождения. ...............................................................75
*И.З. Гарифуллин.*
Татарские организации Башкортостана: история, современное положение и условия сохранения. .......................................................83
*И.Г. Миннемуллин.*
Татарскому общественному центру Удмуртии – 30 лет. ........................91
*Р.И. Габбасова.*
О деятельности РНКАТ Удмуртии. .......................................................100
*С.Н. Назин.*
Мы вместе. ..........................................................................................104
*З.А. Тычинских.*
Татарские общественные организации Тюменской области. .............112
*Р.М. Сайганова.*
Деятельность татарских общественных организаций Омской области. ........................................................................................ 129
*Ф.Ш. Мухтасаров.*
Общественная организация «Региональная татарская национально-культурная автономия Московской области». .......................................145

***О зарубежных татарских организациях***

*Л.Р. Кутеева.*
Отражение татарского духа на континентах. ........................................156
*Ю. Шамильоглу.*
Космополитическая высокая культура татар и Всемирный конгресс татар. ..........................................................................................................171
*З.И. Канапацкая.*
Национально-религиозное возрождение белорусских татар в конце XX – начале XXI вв. ..................................................................................178

***Научные публикации по краеведению***

*Н.В. Бекиров.*
Крымские татары: последние сто лет (окончание). .............................192

***Исторические источники по краеведению***

Резолюция Всемирного конгресса татар 1992 г. ..................................207
Обращение Всемирного конгресса татар народам и государствам мира, ООН. 1992 г. ..........................................................................209
Формируя концепцию развития татарской нации в XXI в. (Материалы заседаний Клуба «Татарский квадрат. Татар шакмагы»). Часть I. ..........................................................................................................210

***Известные личности***

*Р.Ф. Гатауллин.*
Не официально, о Махмуте Исхаковиче Такумбетове. .......................221

***Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики***

Хроника ......................................................................................................225

***Национальная кухня, пути сохранения здоровья***

*Д.И. Файзуллина.*
Губадия. Корт. ...........................................................................................230
*Г.А. Валеева.*
Домашнее печенье. ...................................................................................231

***Слово о юбилярах***

*Ф.З. Мусин.*
Маулиза Гумерова: У счастливых праздника бывает больше. .............232
*З.А. Тычинских.*
Легенда сибирских татар. ........................................................................241

***Сведения об авторах***

# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ ТУРЫНДА

БТКның барлыка килүе бик үзенчәлекле шартларда булды – әле генә Татарстан суверенлыгы турында референдум үткәреп, анда республика халкының 64,2% тавышы алынып, Мәскәү белән алга таба сөйләшүләрнең нигезе барлыкка килгән иде. Әмма, мондый сөйләшүләр беренче чорда уңышсыз барып, татар җәмәгатьчелегендә республика хакимияте алып барган сәясәттән ризасызлык үсә барган дәвер башланды 1992-нче елны.

Шул шартларда Татарстанда радикаль рухта хәрәкәт иткән Милли Мәҗлес барлыкка килде (ул вакыттагы сәяси каршылыклар турында бу номерга куелган документаль материаллардан һәм Ф. Бәйрәмова мәкаләсеннән күрә аласыз). Ул барлыкка килде генә түгел, ә көчәя дә башлады һәм Бөтентатар иҗтимагый үзәге кебек урталыктан баручы оешмаларга да нык йогынты ясады, шул сәбәпле, БТИҮдә «сул» фикерле лидерлар җиңеп чыгып, Татарстанның сәяси кырында радикальлек нык үсеп китте. Менә шундый вазгыятьтә республика җитәкчелеге Бөтендөнья татар конгрессын үткәрү турында карар кабул итте дә. Булган мәгълүматлар буенча, мондый идеяне беренче булып шагыйрь һәм сәясәтче Ренат Харис формалаштырган һәм республикабызның югары даирәләренә җиткергән.

Әмма Казанда 1992-нче елның 19–21 июнендә җыелган БТКның бурычлары киңрәк булды – моны корылтайның резолюциясеннән һәм дөнья халыкларына мөрәҗәгатеннән (аларны бу номерда кабат бастырабыз) ачык күреп була. Ул документларда, татар милләтенең мөстәкыйль сәяси берләшмә буларак, Татарстан җөмһүриятен цивилизацияле дөньяга танытырга омтылу бар. Әйе, совет чорыннан чыгып барган татарлар, аерым сәяси көч буларак, бу корылтай исеменнән 1992-нче елның җәендә үз-үзләрен дөньяга да презентацияләделәр.

Тарих тиз уза, инде менә 30 еллык дәвер дә артта калды һәм бүген мондый сорау куя алабыз: нәрсә соң ул хәзерге иҗтимагый шартлардан чыгып караганда, Бөтендөнья татар конгрессы? Мондый сорауга җавап табу бер дә гади эш түгел.

Әгәр дә тулаем алсак, БТК – ул татар милләтенең бердәнбер легитим гомуммилли оешмасы. Шунлыктан, аны 1917-нче елда, революци-

он шартларда җыелган татар корылтайларының дәвамы итеп карап була. Була гына түгел, ул чынлап та шулай. Димәк, БТК йөзендә без милли үзбилгеләнүне башкарып чыга алырлык иҗтимагый оешманы күрәбез. Ләкин, иске заманнар белән чагыштырганда, хәзерге оешманың үзенчәлеге бар – бүген БТК белән беррәттән Татарстан Республикасы да яши, ә 1917-нче елны милли корылтайлар сәяси автономия булдыру өчен җыелганнар. Шушы ике иҗтимагый сәяси берләшмәне чагыштырып карасаң, түбәндәге нәтиҗә килеп чыга: Татарстан исеменең нигезендә «татар» этнонимы ятса да, ул барлык татар милләте исеменнән сөйли алмый, аның вәкаләте республика чикләре белән туры килә, ә җөмһүриятебез – күпмилләтле, монда татардан башка халыкларның да вәкилләре бар, шунлыктан ул милләт мәнфәгатьләрен өлешчә генә чагылдыра ала. Ә менә Бөтендөнья татар конгрессы – нәкъ менә милләтебез исеменнән сөйли һәм карар кабул итә ала торган дөньядагы бердәнбер халыкара дәрәҗәдәге оешма. Ягъни, БТК милләтебезнең суверенитетлыгын тулы килеш гәүдәләндерә. Димәк, бу төп мәсьәләне тулысынча гәүдәләндерү БТК кулында.

Бу әһәмиятле факторны БТК делегатлары һәрвакытта та исләрендә тотарга тиешләр. Әгәр дә БТКның VIII корылтаена җыелган делегатлар әйтелгән фикерләрне дөрес аңлап хәрәкәт итсәләр, аның җитәкче органнарын һәм аларны әйдәп баручы шәхесләрне уйлап сайласалар, милләтебез мәнфәгатьләре иҗтимагый тормышта югары урыннарга куелыр, әгәр дә әйтелгән өлкә турында артык уйланмыйча, кемне тәкъдим итсәләр, шуларга автоматик рәвештә кул күтәреп сайлап кына утырсалар, киләсе бишьеллыкта татар дөньясы артык зур уңышларга ирешә алмастыр...

*Дамир Исхаков, тарих фәннәре докторы*

## ГОМУМТАТАР ОЕШМАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАРЫ

*Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче рәисе, тарих фәннәре докторы, академик Индус Таһировның бу халыкара оешманың башлангыч адымнары турындагы хатирәләре*



Бөтендөнья татар конгрессының Беренче съезды үзгәртеп кору, демократия шартларында үтте. Моңа кадәр татар милли хәрәкәтенең дәүләт оешмалары белән рәсми төстә җыен үткәрү буенча хезмәттәшлек иткәне булмаган. Патша хакимияте, совет империясе чорында татарларның дини һәм милли тормышында алдынгы фикерле, талантлы һәм гыйлемле шәхесләре булса да, татар халкы һәм дәүләт белән элемтәдә торган иҗтимагый структура булмаган.

Үзгәртеп кору, совет системасының сүтелү чоры илдәге милли проблемаларны ачып салды һәм аларны чишү юлларын эзләргә мәҗбүр итте. Кыска гына вакыт эчендә искиткеч үзгәрешләр булды, чөнки төрле төбәкләрдә гомер итүче берничә миллион татар үзләре яшәгән илдә реаль рухи-мәдәни көч буларак танылган иде. Татарлар, берләшү форсатын көтеп торгандай, үз көчләрен, милли үзенчәлекләрен саклаган булып чык-

ты. Әле кайчан гына бер-беребезне күрергә тилмереп, Сак белән Сок кебек бер-беребезне сагынып яши торган заманнар бар иде. Совет чорында безне аерып торган тимер пәрдә юкка чыкты. Хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагына барып, милләттәшләребез белән аралашу мөмкинлекләре ачылды. Татар иҗтимагый үзәге, Милли Мәҗлес кебек оешмалар татар милли ихтыяҗларын, Тататарстан статусы мәсьәләләрен күтәрә башладылар. СССР таралганнан соң Россиядә һәм башка БДБ илләрендә татарларның тарихы, социаль-икътисади үсешкә керткән өлеше, иҗтимагый һәм иҗади активлыгы күзгә ташланып тора иде.

Хәзер татар уянды һәм ул халыкара мәйданга юл тота. Ул яшәгән һәммә җирдә төрле исемдәге милли оешмалар барлыка килде. Казан университеты доценты Марат Мөлекев җитәкчелегендә Татар иҗтимагый үзәге оешты. Аның татар яшәешен тәэмин итүче күп мәсьәләләр арасындагы төп бурычы – Татарстанның статусын күтәрү, союздаш республикага әверелдерү булды.

Шул елларны Фәүзия Бәйрәмова җитәкчелегендәге Милләт мәҗлесе халкыбызны туплау, аңа көч-куәт һәм дәрт биреп тору гамәлләрен җәелдереп җибәрде. Фәүзия ханым бүген дә шушы изге эшләрне дәвам итә, архивлардан татар язмышына багышланган яңа документлар таба, аларны өйрәнеп, тирән мәгънәле хезмәтләр яза. Бертуктаусыз диярлек, төрле җирләрдә яшәгән татарлар белән очрашып тора. Ул милләттәшләрдә тарихи үзаң, милли горурлык хисләрен уята.

Менә шушы дулкында Бөтендөнья татар Конгрессы барлыкка килде. Ул киң җәмәгатьчелек һәм Татарстан хакимиятенең, аның Президенты Минтимер Шәймиевнең уртак инициативасы иде. Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Ренат Харисның Татар конгрессы үткәрү турында Татарстан Президентына язган хаты мөһим, актуаль эшне башлап җибәрүгә сәбәп булды. 1992 елда, Беренче татар съездын үткәргәннән соң озак та үтмәде, Конгресс, кайнап торган татар дөньясының әзер җирлегенә таянып, үзенең эшен җәелдерде.

Аның Башкарма комитетына милләтебезнең күренекле шәхесләре сайланды. Беренче дистә ел дәвамында Башкрама комитет рәисе булып эшләргә миңа насыйп булды. Бу шактый четерекле, авыр чорда рәис урынбасарлары буларак «Сөембикә» журналының редакторы, татар хатын-кызлары җәмгыяте «Ак калфак»ны барлыкка китерүче Роза Туфитуллова, «Дөнья» газетасының мөхәррире, «Азатлык» радиосының Казан бүлеге җитәкчесе Римзил Вәлиев, «Мирас» журналының баш мөхәррире Флүн Мусин, шагыйрь, Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев эшләделәр.

Дәүләт, фән эшлеклеләренең Башкарма комитетка керүе бик мөһим иде. Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, Татарстан те-

лерадио компаниясе җитәкчесе Илгиз Хәйруллин, соңрак аның дәвамчысы Илшат Әминов, Мәгариф министры Васил Гайфуллин, Мәдәният министры Марсель Таишев, Матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мирфатыйх Зәкиев комитетка сайландылар. Бу кешеләрнең һәрберсе Конгрессны аякка бастыруга, аның эшчәнлеген җәелдерүгә нык ярдәм иттеләр.

Шушы еларны Татарстан Мәгариф министрлыгының 18 өлкә белән килешүе барлыкка килде. Бу әһәмиятле эшләрне башкаруга ул вакыттагы Мәгариф министры Фарис Фахраз улы Харисов зур өлеш кертте. Әгәр дә без Русия төбәкләрендә бары тик 232446 укучысы булган 1638 татар мәктәбе генә эшләп килгәнлеген һәм Русиядә милләтебезнең күпчелеге яшәгәнлеген искә алсак, моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген аңларбыз.

Татар мәктәпләре ул чорда аякка баса башлаган иде. Казанда гына түгел, Оренбургта, Самарада, Саратовта, Ижауда, Уфада, хәтта Мәскәүдә дә татар мәктәпләре барлыкка килде, өр-яңадан татар теле гамәлгә керә башлады. Күп санлы милли оешмалар үсеп чыкты. Алар ныклап милли агарту эшен башлап җибәрделәр һәм бүген дә аны уңышлы дәвам итәләр.

Телебезгә, гомумән үзебезгә, татар бердәмлеге беренче урынга чыгуы зарур иде. Күп шәһәрләрдә якшәмбе мәктәпләре эшли башлады, туган телгә тартылу артты. Халкыбызга милли рух һәм горурлык хисләре кайтты. Ул үзендә искиткеч, башкаларны таң калдырырдай, яшәү көче таба алды. Тиз арада Конгрессның җирле оешмалары барлыкка килде. 1998 елда Россия татарларының Милли-мәдәни мохтарияте оешты һәм тиз арада аның җирле оешмалары эшли башлады.

Самарадагы, Ульяновскидагы, Мәскәүдәге оешмалар бигрәк тә зур активлык күрсәттеләр. Мәскәүдәге «Туган тел» җәмгыятен Нур Гарипов кебек милләтпәрвәр татарлар җитәкләде. Монда татар телен өйрәнү курслары, тел өйрәнү дәреслекләрен булдыру эшләре җәелдерелде. Шушы хәрәкәткә шактый күп эшкуарлар кушылып, бу изге эшкә үз өлешләрен керттеләр.

Самарада Шамил Баһавединов, Равил Хәйруллин тирәсендә дистәләгән татар зыялылары тупланды. Шамил, сәләтле журналист буларак, «Азатлык» радиосы аша татар дөньясындагы яңалыкларны пропагандалауга зур өлеш кертте. Инде мәрхүм Равил абый Ягудин милли мәгъриф эшләрен җиренә җиткереп башкара иде. Самарада гына түгел, өлкәнең һәрбер авылындагы мәгариф эшләре аның игътибар үзәгендә булды. Шушындый милләтпәрвәрләр ничәмә-ничә мәктәпне ябылудан коткарып калды. Кирәк булса, Равил абый теләсә кайсы чиновникка, хәтта губернаторга да кереп, мәгарифебезгә бәйле мөһим мәсьәләне хәл итеп чыга иде.

Милли хәрәкәт киң җәелгән үзәкләрнең берсе Саратов булды. Монда Зөфәр Хәкимов, Митәсим Сөләйманов, Фрид Рәшитов, мөфти Мөкатдәс

Бибарсов һәм башка дистәләгән милләтпәрвәр шәхесләр бүгенге көнгә кадәр милләтебезгә багышланган зур эшләр башкаралар. Алар өчен төп мәсьәлә – милли мәгъриф, мәдәният, гореф-гадәтләребезне саклау. Аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә шәһәр уртасында татар гимназиясе барлыкка килде. Эшмәкәр Камил Аблязов шушы мәктәпкә ремонт ясатты, компьютерлар һәм интернетларын булдырды.

Иваново өлкәсе мөселманнары мөфтие Фәрит Ляпин җитәкчелегендәге милли-мәдәни автономия инде күптән милли эшләрне оештыручы төп көчкә әверелде. Монда якшәмбе мәктәбе эшләп килә, Сабантуйлар үткәрү традициягә кереп китте.

Ханты-Манси округындагы автономияне, ни кызганыч, хәзер инде мәрхүм, уңган Чистай егете Фәнис Гатауллин җитәкли иде.

Омск өлкә автономиясен күп еллар буе тәҗрибәле юрист Хәким Садыков җитәкләде. Бу автономия дә, зур авырлыкларны җиңеп, барлык булган милли оешмаларны берләштерә алды. Өлкә автономиясенең 37 җирле бүлеге булдырылды. Автономия, җирле хакимиятне әйдәп, татар теле укытучылары белән махсус эш алып бара. Татар балаларына телебезне өйрәтү, якшәмбе мәктәпләре булдыруга зур игътибар бирелде. Өлкәнең үзешчән коллективлары Омск татарларына гына түгел, хәтта күрше өлкәләргә дә хезмәт күрсәтәләр. Автономия кысаларында Сания Мирхалиева һәм Рузалия Сайганова ул дәвердә татарча радиотапшыру эшләрен җайга салдылар.

Мордовия милли-мәдәни автономиясен Шамил Зәкәрия улы Бикмаев барлыкка китерде. Ул – күп еллар губернатор киңәшчесе һәм республика парламенты депутаты булып торган тәҗрибәле шәхес. Булдыклы эшмәкәр буларак, милли эшләрне башкаруга ул күп чыгымнар сарыф итте. Аның һәм дәвамчыларының тырышлыгы аркасында республикада татар телен өйрәнүгә, мәктәпләр эшен җанландыруга, бигрәк тә яшьләр, балалар белән эшләүгә зур игътибар бирелде.

Түбән Новгородта да шуңа охшаш процесслар барлыкка килде. Мондагы «Туган як» җәмгыятенең төп эшләре районнарда, бигрәк тә Краснооктябрьск һәм Сергач районнарында алып барыла. Сергачта «Туган як» газетасы чыга иде. Монда шулай ук татар китаплары да нәшер ителеп килде. Редакция тирәсендә әдәби көчләр тупланды. Татарлар күпчелек тәшкил иткән Краснооктябрьский районында милли тормыш кайный иде. Иң зур һәм матур Сабантуйлар да шунда үтте.

Әмма милли эшләрнең идеология үзәге Түбән Новгород – Нижгарда булды. Анда милли яшәешкә фәнни төс бирү эшен Алимжан Орлов, Мансур Хафизов, «Туган як» җитәкчесе Марат Юнисов башлап җибәрделәр.

Мондый җаннары-тәннәре белән милли эшләребезгә бирелеп эшләгән дистәләрчә шәхесләребезнең исемнәрен булса да әйтеп китү урынлы булыр иде. Ульян өлкәседә – Азат Курчаков, Әстерханда – Әнвәр Алмаев, Наилә Потеева, Төмәндә – Хәнисә Алишина, Литвада – Атанас Асанавичюс, Ригада – Зөфәр Зәйнуллин, Илдус Сабитов һәм бик күпләр зур хезмәт куйдылар.

Удмуртиядә киң колачлы эш җәелдереп җибәргән Мәсхүт абый Гаратуевны искә алмасам, дөрес булмас. Ул – атказанган укытучы, тирән белемле, зирәк акыллы, милләтебезгә тулысы белән бирелгән шәхес иде. Милли эшләрнең башында буларак, ул, республикадагы татар мәгъриф эшләрен җайга салучы, үз тирәсенә дистәләгән активист туплап, максатчыл һәм эффектлы рәвештә эшли торган оешма булдыра алды. Ижауда татар газетасы чыга башлавында да аның роле зур булды.

Бу елларда туган телебезгә, гореф-гадәтләребезгә кайту, милләтебезне саклап калу, аның бөтенлеген тәэмин итү беренче урында торды. Бу эшнең башында торган «Ак калфак» оешмасы татар гаиләсе проблемаларын бөтен тулылыгы белән колачлый алды. Кыска гына вакыт эчендә төбәкләрдә оешманың 30дан артык бүлекчәсе барлыкка килде. Алар бүгенге милли яшәешебезгә, телебезгә куркыныч янаган шартларда эшләрен тагын да активлаштырдылар.



*Р.Р. Туфитуллова архивыннан*

Максатларыбызның берсе – татарлар яшәгән төбәкләрдәге хакимиятләрене татар проблематикасына якынлаштыру, җирле татар оешмалары белән аңлашуны булдыру иде. Шуңа ирешү өчен төбәкләрдә Конгресс-

ның Башкарма комитетының күчмә утырышларын үткәрү иң уңышлы чараларның берсе булды. Конгрессның беренче унъеллык дәверендә алар Екатеринбург, Төмән, Омск, Ульяновск, Казакъстанның Шымкент, Кыргызыстан башкаласы Бишкек шәһәрләрендә, Самара өлкәсенең Камышлы районында уңышлы үттеләр. Бу җыелышлар, җирле хакимият җитәкчеләре һәм киң җәмәгатьчелек катнашында үтеп, бер яктан, мондый чаралар тарафның үзара якынлашуна китерсә, икенче яктан, татар яшәешен бөтен тулылыгы белән күзаллауга юл ачты. Аларда кабул ителгән карарлар татар проблемасын хәл итү өчен мөмкинлекләр ача килде.

Кайбер мөһим мәсьәләләр Конгресс җитәкчелегенең Санкт-Петербург, Киев, Минск, Уфа, Әстерхан, Иваново, Нижневартовск, Чиләбе, Пермь шәһәрләрендәге очрашу-аңлашулар нәтиҗәсендә хәл ителә иде. Бу очрашуларның һәрберсен конгресс Башкарма комитетының дипломатик эшчәнлеге дип карарга була. Нәкъ менә шул чаралар аркылы бу һәм башка чараларның күбесендә җирле хакимият җитәкчеләре, губернаторлар үзләре катнаша килделәр. Милли эшләребезгә Екатеринбургта – Э. Россель, Саратовта – Д. Аяцков, Омскида – Л. Полежаев, Санкт-Петербургта В. Яковлев зур кызыксынучанлык күрсәттеләр. Аларның урынбасарларының Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышларында татарлар өчен кылган гамәлләре хакындагы чыгыш ясаулары, шуннан соң эчтәлекле фикер алышулар һәм бергәләшеп тиешле карарлар кабул итү гадәткә кергән иде.

Шушы күчмә утырышлар кысасында Татарстан Мәгариф, Мәдәният министрлыкларының җитәкчеләре үзләренең жирле коллегалары белән килешүләр төзүе гадәткә керде, җирле хакимият җитәкчеләре белән якынлашып, аларны татар проблемаларына җәлеп итү җайга салынды. Екатеринбургта Свердловски өлкә губернаторы Э. Россельнең безнең эшләребездә катнашуы әһәмиятле булды. Аның белән берничә мәртәбә очрашу безнең Уралдагы вәкиллегебезне ачуга юл ачты, ике яклы килешү төзүгә сәбәп булды.

Саратов губернаторы Д.Ф. Аяцков шулай ук татар мәсьәләләре белән ныклап кызыксына, татарларга ярдәм кулын суза тора иде. Шәһәр уртасындагы татар гимназиясе аның ярдәме белән аякка басты. Анда укырга керергә теләүчеләрнең саны артканнан-арта барды. Беренче класска керү өчен бер урынга конкурс алты кешегә җитте. Саратов татарлары аны яратып, Дамир Фатыйхович дип кенә атыйлар иде. Сабантуйларны җәйлап җибәрүләрдә дә аның өлеше зур булды.

Татар Конгрессы үзенең беренче унъеллык чорында Берләшкән Милләтләр Оешмасының информацион Үзәгендә теркәлде. Ул үткәргән чаралар турындагы мәгълүматның шактые шушы Үзәккә җибәрелүе дә

гадәткә керде. Башкарма комитет Бәйсез Дәүләтләр Парламентара Ассамблеясына да күзәтүче рәвешендә кабул ителде. Аның фән, мәгариф, культура эшләре буенча комиссиясенең эшендә актив катнашты. Боларны тормышка ашыруда Татарстанның Санкт-Петербургтагы ул вакыттагы даими вәкиле Шамил Әхмәтшинның өлеше зур булды.

Заманалар үзгәрә тора. Бер буын урынына икенчеләре килә. Аларның дөньяга карашларына да үзгәреш керә. Россия үзәге белән шартнамәле рәвештә яшәүгә нокта куелды. Аңа кадәр уку стандартларыннан милли-төбәк компоненты алып ташланды. БДИ имтиханын милли телләрдә бирү хокукыннан да ваз кичтерделәр.

Читтә яшәгән татарларыбыз нигездә шул ук шартларда яши: милли җәмәгатьчелек ничек үз тормышын оештыра, эшләр шулай бара. Соңгы елларда һәммә җирдә, хәтта ерак чит илләрдә дә, шул исәптән Нью-Йорк, Вашингтон, Сан-Франциско, Монреаль, Австралиянең Аделаидасында һәм берничә Төркия шәһәрләрендә, Ауропада гөрләп Сабантуйлар үткәрелә башлады. Җир шарының төрле почмакларында татар җыры яңгырый торган заман җитте. Үзешчән сәнгать коллективлары халыкның милли хисләрен уяталар.

СССРдан читтә яшәгән милләттәшләребез дә татар рухын, татар яшәешен саклый алдылар. Кытайдамы, Америкадамы, Финляндиядәме, татар кешесе туган теленә, гореф-гадәтләренә тугрылыклы булып, үзендәге яшәү көчен саклый алды.

Әгәр дә, 1930–40-нчы елларда Сеул шәһәрендә яшәгән 26 татар гаиләсе мәктәп ачып, уку китаплары бастырып, мәчет салып, мили тормыш булдыра алганнар икән, бу юкка гына түгел. Шушы мәктәптә белем алган бүген безнең арабыздагы Сәгыйт Сәлахның АКШка килеп ике югары белем алуы, докторлык диссертациясе яклап, атом тикшеренүләре өлкәсендәге күренекле галимгә әверелүе, Америка энциклопедияләренә керүе дә очраклы хәл булмас. Чөнки мондый шәхесләр халкыбызда бер ул гына түгел. Әле тагы Надир Дәүләт, Юлай Шамил, Айшә Рорлих, Рифат Таби, Әдиб Акчура кебек илдән читтә җитлегеп тә, татар рухына, татар яшәешенә тугрылыклы булып калган зур галимнәребезне дә саный алабыз.

Калифорниядә яшәүче Оркыя Сафалы да шундый ук юлны үткән ханым. Ул – үз балаларына гына түгел, башка яшь татарларга да милли оеткы салган изге зат. Ул, 1954 елны Нью-Йорк татар яшьләрен оештырып, Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын, аннары «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен сәхнәгә куйган шәхес Сан-Франциска шәһәрендә дә милли тормыш гөрләп торган, андагы татарлар да, театраль труппалар төзеп, сәхнә әсәрләрен куйганнар. Әгәр дә бүген Америкада Рөстәм Яхин, Салих Сәйдәшев һәм халык җырлары яңгырап тора икән, димәк, милли тормыш дәвам итә.

Финляндиядәге саннары 1 меңнән артмаган татарларның үз милли мәгариф системасын булдыра алулары, милли җыр-моң белән сугарылып яшәүләре, аларның җәмгыятьтә лаеклы урын биләүләре шулай ук милләтебезнең яшәү көчен раслый торган мисал. Төрле илләрдәге татар җәмгыятьләре тормышын чагылдыручы фактларны күпләп китереп булыр иде. Алар барысы да халкыбызның милли яшәешкә омтылуын раслыйлар.

Чит ил татарлары белән эшләүдә безнең кыйбла, стратегик принциплар нинди булырга тиеш соң? Без бу юнәлеш белән дә даими кызыксынып, фикерләр тупладык. БТК Башкарма комитетының 2001 елның 8 декабрендә Истамбул шәһәрендә үткән күчмә утырышы карарында шундый пунктлар бар:

1. Төркия Республикасының Истанбул, Анкара, Искешәһәр шәһәрләрендә татар җәмәгатьчелегенең милли тарихыбызга, туган телебезгә, мәдәниятебезгә ихтирам саклап, татар милләтен үстерүгә керткән өлешен билгеләп үтәргә.
2. Татарлар тупланып яшәгән шәһәрләрдә һәм мәхәлләләрдә, авылларда татар җәмгыятьләрен оештыруны, аларның эшен җанландыруны кирәк дип табарга.
3. Төркия Республикасы хакимият органнарының, фәнни, мәдәни оешмаларының татар зыялыларына, татар халкына рухи үсештә ярдәм итүен билгеләп үтәргә.
4. Төркиядә яшәүче татарларны, аларның җәмгыятьләрен, дәрнәкләрен, мәдәният үзәкләрен берләштерүче гомуми оешма, ассоциацияне булдыруны кирәк дип табарга.
5. Татарлар тупланып яшәгән мәхәлләләрдә, авылларда, шәһәрләрдә якшәмбе мәктәпләре, сәүдә һәм мәдәният үзәкләре ачу, Сабантуйлар, мәдәни кичәләр үткәрү өчен Татарстан һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән уртак чаралар гамәлгә куярга.
6. Төркиядә яшәүче татарларның Татарстан белән хезмәттәшлеген Татарстан белән Төркия арасында, Русия һәм Төркия арасында алып барылган күпьяклы хезмәттәшлек кысаларында бәяләргә.
7. Төркия татарлары үзләренең тарихи Ватаннарын Татарстанда һәм Идел-Уралда дип тану сәбәпле, Русия хакимиятләренең мөһаҗирләргә бирелә торган ташламаларын татар мөһаҗирләренә дә бирүне сорап, Русия Президенты В.В. Путинга һәм Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиевкә мөрәҗәгать итәргә.
8. Татарстандагы милли-мәдәни оешмалар, фәнни үзәкләр белән бергә татар мөһаҗирләренең тарихын булдыру, Төркия татарларының тарихын матбугатта бастыру өчен чаралар күрергә.

9. Татарстаннан читтә тупланып яшәүче татарларның милли-мәдәни мохтариятләр, милли җәмгыятьләр төзеп, якшәмбе мәктәпләре, театрлар оештырып, яшь буынга туган телебезне, милли гореф-гадәтләребезне аңлатуны, милләтне саклау өчен кирәк булган барлык чаралар күрүне әһәмиятле һәм зарур дип табарга.

Хәзер, 20 ел вакыт үткәч тә, Татар Конгрессының чит илләрдәге татарлар белән эшләүне чагылдырган бу карарга кергән фикерләр актуаль булып кала.

* * *

Хәзерге шартларда туган телебезнең, милләтнең исән калуы өчен, инкыйразга дучар булмавыбызны тәэмин итүче нинди мөмкинлекләр бар? Алар бармы, әллә юкмы? Төп таянычыбыз нәрсә һәм нинди булырга тиеш? Җавап шул: ата-бабаларыбыз калдырган мирас, динебез, гореф-гадәтләребез, тарих, милли мәгариф, мәдәният. Тик аларны хәрәкәткә китерү генә кирәк. Төшенкелеккә бирелмәү, бер җандай булып бердәмлегебезне ныгыту, бербөтен милләт икәнлегебезне тою хисләрен ояту – безнең бурычыбыз.

Татар Конгрессы, Милли Шура, милли-мәдәни мохтариятләр бу эштән читтә калмасыннар иде. Аларның моның өчен хәзер мөмкинлекләре җитәрлек. Ана телебезне гаиләгә кайтаруда хатын-кызларыбызның, яшьләрнең роле беренче урында булырга тиеш. Күп җирләрдә «Ак калфак»ның җирле оешмалары, «Гаилә» җәмгыятьләре, милләтебезгә тугрылыклы мәктәп укытучыларыбыз, йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары бар. Аларга рухи көч һәм матди ярдәм биреп тору кирәк.

Конгрессның башлангыч адымнары РФ төбәкләрендә чит илләрдә милли оешмалар төзү, аларның шул төбәкләрдәге хакимият, җирле халык белән хезмәттәшлеген җайлау татар милли тормышы һәм дәүләт органнары өчен зур яңалык иде. Иҗтимагый-сәяси тормышта татар хәрәкәтенә ышаныч белән карау, дәүләт белән милләтнең хезмәттәшлеген җайга салу БТКның хәзерге чордагы казанышлары өчен дә нигез булып хезмәт итәдер, дип уйлыйм.

*Индус Таһиров,*
*ТФА академигы, Бөтендөнья татар конгрессы*
*Башкарма комитетының 1992–2002 еллардагы рәисе*

# КОГДА ВСЕ ПУТИ ВЕДУТ В КАЗАНЬ...

***О первых годах Всемирной организации татар рассказывает очевидец и участник стартовых шагов Исполкома ВКТ***

***Римзиль Валеев***

## История не знала такого сбора

Первый съезд Всемирного конгресса татар, открывшийся 19 июня 1992 г., безусловно, войдет в хронику этнического развития татар, второго по численности народа России. Это был первый форум этноконфессиональных, региональных и социальных групп, проходивший при прямом участии и содействии органов государственной власти РТ. С уровнем представительства и легитимности данного собрания невозможно сопоставить более ранние форумы. На древних, средневековых «джыенах» и российских мусульманских курултаях рассматривались вопросы избрания предводителей кланов и ханов, отношения с Крымом, Астраханью и Сибирью, с русскими княжествами, проблемы войны и мира, религиозных прав мусульман. Но там, если не считать курултаев 1917 г., не рассматривалась судьба татарского народа в контексте происходивших вокруг событий в целом.



*Р.И. Валеев, Р.С. Валеев, И.Р. Тагиров*

Татарский конгресс ранней, постперестроечной эпохи, был собран для создания органов общественного самоуправления, разработки механизмов взаимодействия с органами власти, определения мер по изучению и сохранению языка, культуры, приобщению к объективной

истории, укреплению этнической идентичности лиц татарской национальности. Он состоялся при участии представителей практически всех регионов и стран проживания татар. Социальная база и география, идеологическое многобразие состава участников данного форума, были беспрецедентными.

Важнейшей особенностью этого мероприятия являлось следующее: время проведения и состав Организационного комитета по подготовке съезда были определены Указом Президента Татарстана М.Ш. Шаймиева, что свидетельствовало об участии в проведении важнейшего национально-культурного форума всех заинтересованных госструктур, использовании материально-технических и организационных возможностей всей республики.

Татарстан в это время пробивался по пути укрепления своей самостоятельности в рамках РФ. Взаимодействие Татарстана и стран, регионов РФ по удовлетворению культурно-просветительских потребностей татар, сотрудничество общественных организаций и властных структур, требовалось осуществлять на основе правовых норм и межрегиональных соглашений, что было бы невозможно силами только отдельных групп общиествнности.

Время показало, что события, происходивщие в Татарстане в 1990-х гг., не были проявлением «сепаратистских» тенденций. Выдвигались реальные повестки по укреплению правовой и организационной базы федеративного устройства обновленной России. В данный период еще шли переговоры по разграничению полномочий между органами власти РФ и Татарстана, в ходе которых следовало бы учитывать и потребности 5,5 млн татар России, их заинтересованность и роль в успешном развитии республики, являющейся духовным и культурным центром всех татар.

В марте того же 1992 г. состоялся рефрендум о государственном статусе Татарстана, а 6 ноября была принята новая Конституция РТ. В таких условиях и собрался Конгресс всех татар, который принял решение об избрании его постоянно действующего руководящего органа. С полным основанием можно считать, что Первый съезд Всемирного конгресса татар стал событием, повлиявшим на историческую судьбу татар и Республики Татарстан как одного из влиятельных субъектов Российской Федерации. Речь шла о создании условий для консолидациий и взаимодействия российских татар и диаспоры из других стран при посредничестве Всемирного конгресса татар.

Созыв и проведение Первого съезда ВКТ относится к ряду взаимосвязанных событий, которые вошли в новейшую историю РТ и Российской Федерации. В их числе:

– принятие Декларации о государственном суверенитете Татарстана;
– возрождение памятников истории и культуры в Казанском Кремле, Древнем Болгаре и острове-граде Свияжске, включение данных историко-культурных заповедников в список мирового наследия ЮНЕСКО;
– строительство мечети Кул Шариф в Казанском Кремле;
– реализация программы ликвидации ветхого жилья в Казани, предоставление 55 тыс. бесплатных или льготных квартир жителям трущоб и старых жилищ;
– открытие Казанского метро;
– проведение международных спортивных и культурно-просветительских форумов;
– открытие спутникового телеканала «Татарстан-Новый век» и др.

Данное событие было позитивно воспринято общественностью и партнерами Татарстана. Не случайно, в феврале 1994 г. было подписано известное Соглашение между федеральным центром и республикой, определившее новую модель федерализма в стране, форирующегося взамен супрецентрализовованной псевдоинтернационалистской, отжившей свое советской системы.

**Подготовка и проведение Конгресса**

С самого начала интерес к съездам Конгресса татар был огромный. Накануне открытия главного национального форума казалось, что все пути татарских деятелей ведут в Казань. Из некоторых регионов приезжали даже «параллельные» делегации.

Подготовкой и проведением съезда занимался Организационный комитет, созданный упомянутым выше Указом М.Ш. Шаймиева. Соответствующим ведомствам были даны поручения по встрече делегатов и гостей на вокзалах и в аэропорту, размещению их в гостиницах, по обеспечению культурной программой. Шла работа по формированию содержания и идеологии мероприятия. Все должно было быть на международном уровне, с раскрытием традиций, духовного и культурного потенциала народа, созидательного настроя Республики Татарстана.

Подготовка к учреждению Конгресса татар продолжалась в течение 4-х месяцев. Теперь ВКТ проводит ежегодно по 3–4 форума с участием 500–900 участников. В Татарстане и регионах сейчас знают план и программу, списки причастных к татарским делам активистов; общественные деятели и ответработники в курсе, что от кого можно ожидать. Но первый опыт мы получили в 1992 г., когда ничего из перечисленного выше ещё не было.

Тогда Организационный комитет состоял из представителей власти, общественных деятелей, научно-творческой интеллигенции и руководителей гуманитарных ведомств, научных центров и учебных заведений. Ещё не было создано и современное агентство «Россотрудничество». Но выяснилось, что деятельность общества «Ватан», созданного по примеру федерального общества «Родина» по работе с соотечественниками за рубежом, была востребована. Я был одним из организаторов общества по работе с татарской эмиграцией, выпускал тогда газету «Дөнья» («Планета»), даже избирался руководителем «Ватан»а после академика Мирзы Махмутова и журналиста, общественного деятеля Дамира Гисметдинова. Поэтому был кооптирован в список Оргкомитета Конгресса. На съезде татар на самом деле занимался преимущественно делегатами из дальнего зарубежья и информационным обеспечением.

**В этот исторический день...**

Прекрасно помню солнечный день 19 июня 1992 г. На площади Свободы впервые столь масштабно и празднично гремела татарская музыка. Было непривычно видеть, как пляшут вместе другими гостями и казанцами Президент и Председатель Госсовета Татарстана, а также другие известные личности. Я провел «свои» делегации в театр имени М. Джалиля и вышел на площадь, так как в зале было жарко и, главное, было нелегко справиться с волнением. Поскольку доклады и выступления транслировались на площадь Свободы, я слушал выступления делегатов съезда с репродукторов, занимаясь своими «оргвопросами» у входа на площади.

В президиуме сидели знаменитые татары со всего мира. Выступали гости высокога ранга от имени Президента страны, Председателя Правительства РФ и других больших руководителей, первые лица из Башкортостана, Астрахани, Республики Коми, Кировской области и других регионов. Стоит вспомнить вступительную речь Председателя Оргкомитета, Премьер-министра РТ Мухаммата Сабирова и большой, почти часовой доклад Минтимера Шаймиева, других официальных лиц и делегатов. Приветствовал съезд Премьер-министр Башкортостана Марат Миргазямов. Позже, уже на Втором съезде, с гордостью и достоинством, демонстрируя подлинное уважение к татарам и высокому собранию, выступал и Муртаза Рахимов. Тогда, накануне, 28 июня 1997 г., в Уфе состоялся прекрасно организованный съезд татар Башкортостана (каких никогда не было в истории ни до, ни после 1997 г.), где Муртаза Губайдуллович сидел в президиуме вплоть до избрания делегатов от республики на Второй съезд Всемирного конгресса татар. Так было и это – история.

**Что решили делегаты съезда?**

На съезде татар 1992 г. прозвучали не только приветствия официальных ораторов. Делегатами были тепло встречены яркие, эмоциональные выступления представителей национального движения – Председателя Татарского общественного центра Марата Мулюкова, руководителя Милли Меджлиса, пртендующего на статус Национального парламента, Мидхата Абдуллина, историка и писателя, Председателя партии «Иттифак» Фаузии Байрамовой, выступившей на Втором съезде в августе 1997 г., других деятелей национальной культуры и науки.

Обычно в программы съездов ВКТ включаются пленарные заседания, секции по направлениям работы (история, культура, образование, СМИ, эмиграция, бизнес и т.д.) Резолюции секционных занятий также содержат разумные предложения по актуальным проблемам. Эти идеи, наряду с решениями, принятыми на пленарных заседаниях, стоит проанализировать и сейчас, спустя многие годы. Многие аргументы и идеи не потеряли своей актуальности.

В резолюции Конгресса раскрываются роль и место татарского народа в современном мире, обозначаются стремление к сохранению идей государственности в исторической памяти татарского народа, указывается на расширение и развитие связей с соплеменниками, возрождение и развитие родного языка, культуры, традиций, обычаев.

Исполнительному комитету, который был избран делегатами Первого съезда, было поручено, не подменяя органы государственной власти и управления, взаимодействовать с ними.

В последующий период на основе резолюции Первого съезда были разработаны программные и нормативные документы ВКТ. До настоящего времени ВКТ осуществляет выполнение задач, определенных Первым съездом, совершенствуя формы и стиль работы, расширяя свое влияние в регионах и странах проживания татар. Вкратце эти задачи были определены так:

- объединение татарского народа;
- помощь в социально-экономическом, национально-культурном, а также политическом и духовном развитии Республики Татарстан;
- участие в исследовательской и миротворческой деятельности, осуществление связей с международными гуманитарными организациями, сотрудничество с государственными органами, культурно-просветительскими учреждениями, национально-культурными объединениями, религиозными организациями, а также отдельными гражданами;

– участие в деятельности по разрешению этнорегиональных проблем татар на основе соблюдения демократических принципов, норм международного права и законов стран проживания татар;
– разработка и содействие реализации целевых программ в области национально-культурного развития – языка, науки, образования, культуры, демографии, исторического наследия, педагогики;
– регулярное взаимодействие с татарской диаспорой;
– сбор и распространение информации о Республике Татарстан и татарском народе, издание газет и журналов, видео и аудиопродукции в установленном законом порядке, взаимодействие со средствами массовой информации в регионах проживания татар.

Благодаря реализации принципов и установок, определенных на Первом и последующих съездах ВКТ, эта международная организация татарского народа сейчас признана эффективным инструментом народной дипломатии.

ВКТ изначально играл и играет важную роль в расширении позитивного влияния российской общественности в качестве «мягкой силы», укрепления дружбы между народами.

**ВКТ открывает двери**

Создание ВКТ как Международного Союза общественных объединений открыло новую эпоху в жизни татарского народа и в деятельности гуманитарных учреждений Татарстана. Актуальная ситуация предъявила высокие требования к новой структуре, породила повышенные ожидания относительно эффективности и масштабов этнокультурного развития татар. Возникла необходимость в разработке параметров и критериев эффективности национального самосохранения и этнического развития. Несмотря на изменение условий, востребованность в реализации данной задачи сохраняется вплоть до настоящего времени.

В течение первого, «стартового» десятилетия, ВКТ и его Исполком в составе 25 человек (после Второго съезда – 38 членов) во главе с академиком И.Р. Тагировым, занимался разработкой идеологии, методов и форм деятельности Конгресса татар, созданием и поддержкой деятельности отраслевых и региональных структур. В первую очередь были созданы и зарегистрированы более 50 региональных организаций, которые до настоящего времени служат базовыми центрами в регионах, взаимодействуя с Исполкомом ВКТ и ассоциациями, отраслевыми объединениями ВКТ.

Члены Исполкома, являющиеся руководителями важных гуманитарных ведомств, отраслей и научно-образовательных учреждений, в первое десятилетие возглавили комиссии Исполкома по направлениям – культу-

ре, образованию, науке, СМИ, предпринимательству и экономическим связям и т.д. Являвшиеся членами Исполкома министры РТ, президент Академии наук РТ, ректоры вузов и НИИ, главы администрации Казани и Набережных Челнов участвовали в работе Исполкома ВКТ как общественные деятели, выполняли поручения, реагировали на запросы с мест. Их внимание акцентировалось на отработке взаимодействия общественных формирований с органами региональной и муниципальной власти.

Большой объем управленческой и консультативной работы приносит результаты в тех случаях, когда национальные организации возглавляют компетентные в идеологических, политических, юридических и экономических вопросах активисты, а управленцы проявляют заинтересованность в гармонизации межнациональных отношений.

**Тогда действовал неформальный «протокол...»**

В 1990-е гг. в РФ только формировались основы государственной службы и системы взаимодействия частных, общественных и государственных структур. Не были в достаточной степени отработаны протокольные аспекты контактов общественности с органами власти. Поэтому с представителями власти татарских регионов устанавливались контакты как в официальной, так и в неформальной формах. И.Р. Тагиров в большинстве случаев использовал свои научные связи, так как практически во всех городах и районах Поволжья и Урала работали его бывшие студенты или аспиранты, коллеги по проведению научных конференций. Редакторам и журналистам, представляющим Исполком ВКТ, в общественных делах помогали профессиональные контакты и проведение совместных мероприятий по развитию СМИ.

Р.Р. Туфитуллова в качестве главного редактора женского журнала и руководителя общества «Ак калфак» вела большой объем работы по своей тематике, приобщая свой актив к вопросам ВКТ. Аналогично действовали и другие члены и активисты ВКТ.

Каждый член Исполкома или работник аппарата, выезжая на места, принимая посетителей, представлял не только себя, но и всю организацию, интересы всего татарского сообщества. Председатель Исполкома неоднократно встречался с первыми руководителями большинства крупных регионов, городов с татарским населением. И не для галочки или ради протокола.

Наиболее показательным, например, можно считать поездку делегации ВКТ в Волгоград в октябре 1999 г. Накануне этой поездки И.Р. Тагиров был включен в делегацию под руководством М.Ш. Шаймиева для поездки в Финляндию. Поэтому, в Волгоград неожиданно было поручено поехать заместителю Председателя Исполкома ВКТ, а в делегацию вхо-

дили также генерал-полковник Р.С. Акчурин, муфтий Равиль Гайнетдин, бизнесмен и будущий депутат Госдумы Ильяс Муслимов и др. Мне, как заместителю Председателя Исполкома ВКТ, пришлось возглавить делегацию, ведь формат диалога был определен как встреча губернатора области с представителями ВКТ и Татарстана. В этой поездке никто не придал значение статусным перекосам. Никого не смущало, что зампред Исполкома общественной организации выступает раньше генерала и Председателя Совета муфтиев. Встреча с губернатором прошла успешно, руководитель области Н.К. Максюта вечером пришел на концерт татарских артистов. Этот эпизод показывает: официальных политиков и администраторов привлекают влиятельность татар, их способность играть заметную роль в избирательных компаниях и т.д.

Небольшой аппарат ВКТ тогда состоял из 4–5 человек (после Второго съезда сотрудников стало 6–7 чел.) и члены бюро Исполкома регулярно совместно обсуждали актуальные вопросы. Почти ежедневно, не менее 2–3 раз в неделю, устраивались дискуссии, «круглые столы», презентации научно-исторических книг на национальные темы. В ходе таких встреч любые вопросы ставились открыто, неформально, приоритетным был поиск решения проблем.

**Перепись как источник повышенной опасности?**

В августе 1997 г. с трибуны Второго съезда ВКТ были озвучены численность преселенцев в республику. За 5 лет переселились 100 тыс. мигрантов, из них 73% были татарской национальнсоти. Татары уже составляют более 52% жителей республики. Миграция и демография самым прямым образом отражаются на межнациональных отношениях и деятельности этнокультурных организаций.

К слову, ситуация с татарским вопросом в Башкортостане актуализировалась накануне Всероссийской переписи населения 2002 г. Тогда заранее была развернута агитационная компания в татарских районах РБ относительно того, что сотни тысяч татар западных районов РБ якобы являются башкирами, хотя они, несмотря на многолетнюю промывку мозгов населения, сохраняли свою идентичность и несомненную принадлежность к татарской культуре и языку. К этой «спорной» категории населения фактически могли быть отнесены не только 250 тыс. татар Западной Башкирии, но и все 1,5 миллионное татароязычное население Башкортостана. Отдельные этномиссионеры башкирами объявляли и объявляют также татар, живущих на востоке Татарстана, включая родной для Шаймиева Актанышский район и население бывшего Мензелинского уезда!

Публикации в печати, телерадиопередачи у соседей велись в 2002 г. с размахом, что вызвало протест у татар РБ. 30 августа 2002 г. директор Белебеевской татарской гимназии Нурмухамет Хусаинов выступил с речью на встрече В.В. Путина с делегатами Третьего съезда Конгресса татар, состоявшегося в Казанском Кремле. Хусаинов передал настроение татар в год переписи. Фраза, прозвучавшаяся в его выступлении, стала слоганом: «Быть татарином в Башкирии нелегко!» Президент РФ тогда осудил практику искажения данных об этнических сообществах, попыток ограничить обучение родному языку в школах, назвав это «полной дурью». Как сказано на президентском сайте, на той встрече В.В. Путин высказался против каких бы то ни было запретов на изучение национальных языков: «Подобные запреты абсолютно недопустимы, тем более в России, которая является средоточием такого языкового культурного богатства, которого в мире нигде нет» [http://www.kremlin.ru/events/president/news/27352].

Точность и объективность данных о национальном составе, родных языках связаны с четким соблюдением порядка переписи и влияют на организацию образовательного процесса, изучение родного языка и культуры. После Третьего съезда ВКТ, где даннный вопрос рассматривался на высоком уровне, ситуация с переписью в татарских районах Башкирии практически не изменилась. Вероятно, заранее была сделана установка на завышение численности титульного народа республики за счет уменьшения татар. Было видно, что М.Г. Рахимов не отменил свою «отмашку» на демографический «приступ», что продолжается до сих пор и что отравляет атмосферу на границах двух республик. Всероссийская перепись 2002 г. прошла в конце-концов с уменьшением числа татар РБ на сотни тысяч человек.

До сих пор этот статистический казус вдохновляет отдельных этнологов и политтехнологов, которые используют искаженные данные о национальном составе жителей РБ, взможно для умышленного обострения татаро-башкирских отношений.

Итоги переписей удивительны: в Илишевском районе, где вроде бы нет ни одного башкирского села, «нашли» 80% башкир. В следующем, 2003 г., на выборах Президента РБ примерно такая же часть избирателей проголосовала против Муртазы Рахимова. Эти манипуляции с переписью идут еще с 1950–1960 гг., их суть и реальный национальный состав населения северо-западных районов Башкирии знают и «простые» татары и башкиры, да и власти, политтехнологи и провокаторы, которые не могут придумать иных путей к властвованию, кроме разделения и противопоставления двух братских народов.

**Поиск истины и согласия**

Исполком Всемирного конгресса татар с первых шагов своей деятельности стремился вести диалог с органами власти, татарскими, башкирскими этнокультурными организациями о формах сотрудничества, об изучении и применении родного языка, культуры. Председатель Исполкома ВКТ и его заместители регулярно посещали татарские организации Башкортостана, проводили встречи с лидерами БНЦ «Урал» и Всемирного курултая башкир, принимали в Казани делегации башкирских ученых, с которыми вели научные дискуссии по национальным проблемам.

Эксперты и ученые, обсуждая дикуссионные вопросы, ориентировались не на пропагандистские вбросы и провокации, а на концептуальные идеи и серьезные открытия объективных ученых, на создание и продвижение серьезных, глубоких научных трудов об истории татар старого Уфимского уезда и современнного Башкортостана.

Сегодня можно заявить: в 1992–2002 гг. ВКТ поддерживал дружеские, партнерские отношения с татарскими и башкирскими организациями РБ. Во время переписей наблюдались, это надо признать, факты записывания татар башкирами, что порождало трения и приводило к не всегда конструктивным дискуссиям этнологов и отдельных общественников. Татаро-башкирское население не поддерживает противопоставление двух этносов с общей религией, языком, культурой, взаимно близким и привлекательным фольклором, современной музыкой, обычаями и этическими нормами. ВКТ стремился и стремится развивать сотрудничество в целях сохранения самобытной культуры и идентичности татар, башкир других народов, живущих в регионах Поволжья и Урала.

**Незабываемые и неповторимые...**

Какие же действия и решения сохранились в памяти спустя 2–3 десятилетия? Объективные факты в мемуарных записях и в зрительной памяти, благодаря их значимости и напряженной организационно-аналитической работе, до сих пор помню. Было бы целесообразно подготовить и научно-документальные труды с использованием архивных материалов для сохранения истории. Вот, например, наиболее значительное из того, что помню.

В первые же годы была поставлена задача налаживания сотрудничества с международными организациями. В итоге ВКТ был принят в статусе наблюдателя в Межпарламентскую ассамблею стран СНГ, которая заседала в Таврическом дворце Санкт-Петербурга. При разработке законопроектов новых независимых государств мы представляли интересы татар, живущих в бывших союзных республиках. По поручению Пред-

седателя Исполкома однажды я принял участие на выездном заседании Межпарламентской ассамблеи стран СНГ, проходившем в Армении.

На I съезде ВКТ была поставлена задача налаживания связей с ООН, что было маловероятно, так как в этой организации состояли независимые государства. Но мы смогли зарегистрироваться в секретариате информационного центра ООН в Москве, собирали и представляли информацию о татарах мира. Начиная с 1990 гг. Конгресс взаимодействовал с ОНН – Организацией не представленных народов и наций, в которой мы состояли до 2008 г. То есть до изменения политического контекста вокруг этой организации.

Многие из таких действий по налаживанию контактов стали возможными благодаря существовавшим в России демократическим процессам, неформальному общению представителей общественности, использованию фактов богатой истории татар и высокого авторитета лидеров Республики Татарстан в годы укрепления ее самостоятельности.

В ноябре 1993 г. в Зеленодольске состоялось совместное семинар-совещание Госкомитета РФ по делам Федерации и национальностей, Национального отдела аппарата Президента РТ, Кабинета Министров РТ и Исполкома Всемирного конгресса татар по теме «Развитие тюркских народов». В те же годы в рамках подписания и реализации Соглашения между органами власти РФ и РТ Президентом РФ Б.Н. Ельциным были даны 17 поручений по оказанию помощи татарам регионов страны в удовлетворении их культурных запросов. Исполком ВКТ совместно с работниками аппарата исполнительных органов оперативно собирал информацию о выполнении президентских поручений с ответственными органами и учреждениями.

В июне 1996 г. в Казани был проведен семинар руководителей министерств, департаментов регионов компактного проживания татар при участии лидеров татарских национально-культурных обществ, созданных под эгидой ВКТ.

28 августа 1997 г. в АН РТ состоялась масштабная научно-практическая конференция по теме «Татары в современном мире», на которой наряду с учеными и экспертами приняли участие делегаты II съезда ВКТ. Материалы данной конференции были изданы в специальном сборнике объемом 800 страниц.

Такие мероприятия помогли обеспечению делового взаимодействия Конгресса татар и его отделений с органами управления в целях удовлетворения культурно-образовательных запросов российских татар.

В 1996 г. в Шымкенте Казахстана на выездном заседании бюро Исполкома ВКТ были рассмотрены вопросы, связанные с татарами республик

Средней Азии. На данном заседании приняли участие представители всех 19 акиматов Казахстана, ставшие также участниками совместного Сабантуя татар Казахстана, Узбекистана, Кыргызстана.

8 декабря 2001 г. в Стамбуле состоялось выездное заседание бюро Исполкома ВКТ по национально-культурным вопросам в условиях Турции и других стран зарубежья. После детального обсуждения предлагаемых мер по совершенствованию работы была принята резолюция из 9 пунктов.

До сих пор помню, как подробно обсуждали пункт, согласно которому взаимодействие татар Турции с организациями, учреждениями и гражданами, живущими в Татарстане и других регионах, предлагалось вести в рамках сотрудничества России и Турции, связей Татарстана и Турции. Речь, прежде всего, шла о правах на льготы при получении виз и оформлении перевозок личного имущества и товаров. Были и сомневающиеся по поводу возможности приобщения к нормам межгосударственного сотрудничества. Но после детального сопоставления законодательных норм двух стран все убедились в преимуществах предлагаемого порядка. Да и остальные 9 пунктов решения бюро Исполкома до сих пор не потеряли своей актуальности!

### Иногда мечтали о невозможном

В те годы для развития культуры и образования было меньше материальных и финансовых возможностей, но зато был создан более конструктивный фон правового и «бюрократического» регулирования.

Информационная открытость ценилась высоко. Я, тогда как зампред Исполкома ВКТ, иногда параллельно превращался в «главного редактора иновещания». Была поставлена задача: надо, чтобы татары мира услышали нас! Иностранное радио «Азатлык» освещало деятельность татарских общин. Но мы хотели открыть свой, российский вариант коротковолнового вещания. Такую мечту мы выражали, сами не слишком веря, что такое возможно. А ведь получилось! Благодаря позитивному отношению государства и общественности к национальному развитию, в короткие сроки удалось организовать совместную редакцию Исполкома ВКТ и государственного (по нынешнему – федерального) радио «Татарстан» для радиовещания на коротких волнах через ретранслятор системы гражданской обороны, находившейся в Самаре. Решать сложные технические и финансовые вопросы помогла поддержка руководителя ГТРК, а потом заместителя Премьер-министра РТ Ильгиза Хайруллина. Вещание началось в 1995 г. До сих пор продолжается трансляция ежедневной часовой передачи «Голос Татарстана» на FM диапазоне. С той же позывной заставкой на основе мелодии песни «Уян, татар», которую для нашей ра-

диостудии «Дөнья» замечательный композитор и аранжировщик Вадим Усманов записал в своей звуковой студии в Салмачах.

И мир не только услышал, но и увидел татар! В 1998 г., за 4 года до открытия спутникового канала «Татарстан – Новый век», в Исполкоме ВКТ состоялся семинар с участием зам. министра связи РТ В.Н. Якимова, представителей ГТРК «Татарстан». Обсуждали проекты кабельного и спутникового телевидения по примеру канала НТВ+ только на татарском языке, для вещания на регионы и страны проживания татар. Тогда слабо верилось, что такое получится, но появилось осознание того, что это необходимо, а затем и возможно. Можно поискать материалы этого заседания, часть из них я прочитал в книге И.Р. Тагирова «На изломе истории».

Возможно, были в стартовые годы Конгресса недоработки и упущения. Многих не устраивало наше увлечение научно-идеологическими вопросами, «дипломатические» меры по стилю и продвижению татарской повестки. Максималисты требовали больше перемен, конкретной работы с охватом всех сторон жизни. Не спорю, в первое десятилетие мы больше внимания обращали концептуальным, идеологическим вопросам. После 2002 г. более важной признали «конкретную» работу. Каковы результаты – мне трудно судить, так как работа была продолжена командой нового руководства.

* * *

Давно пора написать реальную историю сотрудничества татарского движения с регионами и властными структурами, создать музей Конгресса татар. Нужны воспоминания общественных деятелей. Почти нет фильмов и телерепортажей о первых съездах Конгресса. У нас даже не было отдельного своего PR-проекта по созданию имиджа ВКТ – просто тогда было не до этого. Обычно журналисты и активисты сами интересовались, спрашивали и писали по своему разумению о разных сторонах татарской «культурной революции». Судя по интересу к национальным вопросам равнодушных к татарскому возрождению в те годы не было.

*Римзиль Валеев,*
*заместитель председателя Исполкома*
*Всемирного конгресса татар*
*в 1992–2002 гг.*

*Ф.Ә. Бәйрәмова*

# ТАТАР КОНГРЕССЫ: ОЕШУ ТАРИХЫ, СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ НӘТИҖӘСЕ



Бөтендөнья татар конгрессының оешу тарихын һәм аның сәбәпләрен белү өчен, моннан утыз ел элек булган вазгыятьне күз алдына китерергә кирәк. Бигрәк тә, туксанынчы еллар башын. Бу чор – йөз елга бер килә торган геополитик үзгәрешләрнең, зур тетрәнүләрнең башы булды. Бер илләр юкка чыгып, икенчеләре барлыкка килгән, бер система-режимнар җимерелеп, яңалары туган тарихи көчеш чоры иде. Һәм гасырлар дәверендә зур югалтулар кичереп, шушы чорга хәтле килеп җитә алган, иреккә сусаган татар халкының күтәрелү, уяну чоры да шул заманга туры килде...

Әйе, шушы XX гасырда гына да татар халкы өч тапкыр бәйсезлеккә омтылып карады – гасыр башында, 1905 елгы инкыйлабтан соңгы милли уяну, 1917 елгы Февраль революциясеннән соң рухи-сәяси күтәрелеш һәм 1990 еллардагы дәүләти омтылыш. Әйе, гасырлар буе милли азатлыкка омтылган татар халкы, аның зыялылары, сәяси элитасы тарих биргән бер генә форсатны да кулыннан ычкындырмады, үз максатларын тормышка ашырырга тырышты.

Туксанынчы елларда да шулай булды. Ул елларда вакыт безгә эшләде, без исә, бердәм булып, милләткә эшләдек. СССРда беренчеләрдән булып, милли күтәрелеш Балтыйк буе илләрендә башланды, аннан бу хәрәкәт Кавказга таралды, Урта Азия республикаларына исә бу уяну соңрак килеп җитте. Без, татарлар, Балтыйк буе халыклары белән бергә аякка бастык, милли көрәштә алар тәҗрибәсен өйрәндек, аны үзебездә файдаландык. Шулай ук Азәрбайҗандагы рухи күтәрелеш, алар алып барган милли сәясәт тә безнең өчен үрнәк булды. Шушы нигездә, 1988 елда ук Татар иҗтимагый үзәге оешты, 1989 елда аның I съезды, 1991 елда II-нчесе булды. Төп максат – Татарстанның сәяси статусын күтәрү – союздаш республика дәрәҗәсенә җиткерү, шул рәвешле, татар милләтен саклап калу,

аның рухи-икътисади һәм мәдәни үсешенә ирешү булды. Татар иҗтимагый үзәге исә милли рухтагы зыялыларны берләштерде.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу башлангыч чорда Татарстан җитәкчелеге милли хәрәкәткә каршы килмәде, киресенчә, кайбер эшләрне килешеп тә башкардылар, чөнки республиканың дәүләти статусын күтәрү аларның үзләренә дә кирәк иде. Милли хәрәкәтнең эшчәнлеге мәйданнарда, җыеннарда гына түгел, республика парламентында да дәвам итте, чөнки 1990 елгы демократик сайлауларда күп кенә татар зыялылары, милли хәрәкәт җитәкчеләре депутатлыкка үттеләр. Халык депутатлары арасында Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Тәлгать Абдуллин, Фәндәс Сафиуллин, Җәмил Сафиуллин, Дамир Сираҗиев, Раиф Галиев, Азат Зыятдинов, Рүзәл Йосыпов, Мөнир Әһлиуллин, Фрил Әхмәтов, Наил Мансуров, Мөдәрис Шәйхиев, язучылар Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис һәм башкалар бар иде. Тиз арада милли рухлы бу депутатлардан «Татарстан» төркеме төзелде, һәм республика өчен, милләт өчен иң мөһим карарларны һәм кануннарны алар әзерләде, парламентта кабул иттерүгә иреште.

Татар иҗтимагый үзәгеннән тыш, ул чорда тагы берничә милли оешма – «Суверенитет» комитеты, «Азатлык» татар яшьләре берлеге, «Иттифак» партиясе, бераз соңрак Милли Мәҗлес барлыкка килде, алар инде тагын да кискенрәк максатлар һәм зуррак бурычлар куйдылар. 1990 елны «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясе төзелде, 1991 елның 13–14 апрелендә аның I корылтае булды. «Иттифак» фиркасе үзенең төп максаты итеп, Татарстанның дәүләт бәйсезлеге һәм татар халкының милли бәйсезлеге өчен көрәшне билгеләде. Аның программ документларында шулай ук Татарстанда демократия һәм гаделлек өчен көрәш, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның хокукларын яклау, татар халкының хак тарихын торгызу, милләтнең асыл сыйфатларына кире кайту, ислам динен үстерү һәм тарату бурычлары да чагылыш тапкан иде. Татар иҗтимагый үзәгеннән аермалы буларак, «Иттифак» партиясе Татарстанның дәүләт бәйсезлеге өчен көрәшәчәген, бу максатка, сайлауларда актив катнашып, парламент юлы белән ирешергә омтылуын игълан итте. Фирканең программасында хакимияттәге гаделсезлекне фаш итү бурычы да чагылыш тапты. Бу исә «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясенең, Татар иҗтимагый үзәгеннән аермалы буларак, сәяси таләпләр куюын һәм демократик юл белән хакимияткә килергә дәгъва кылуын аңлатты.

1992 елның 1–2 февралендә Казан шәһәрендә татар халкының мең кешелек җыены булды, анда Милли Мәҗлес, ягъни, Милли парламент сайлап куелды. Бер караганда, инде югарыда санап киткән милли оешмалар тулы куәтенә эшләп килә, тагы бер яңа оешма – Милли Мәҗлес нигә

кирәк булды соң? Моның исә җитди сәбәпләре бар иде. Билгеле булганча, 1991 ел Татарстан өчен дә, Россия, хәтта СССРның үзе өчен дә бик катлаулы ел булды һәм соңгысының юкка чыгуы белән тәмамланды. Бу давыллы елга Татарстан Президентын сайлау, милләтпәрвәрләрнең Казан уртасында сәяси ачлык игълан итеп, республикада Россия Президентын сайлатмавы, ГКЧП вакыйгасы һәм Татарстан җитәкчеләренең аны яклавы, халыкның бәйсезлек даулавы һәм 15 октябрьдә Ирек мәйданындагы канлы бәрелешләр дә туры килде...

Әйе, Россия белән СССР арасындагы көрәш, аларның лидерлары каршылыгы Татарстанга да нык тәэсир итте, ул ике арада калды. 1990 елның 30 августында, Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителгәннән соң, республиканың статусын күтәрү буенча кайбер омтылышлар ясалса да, алар әллә ни нәтиҗә бирмәде, Мәскәүдә аңлау һәм яклау тапмады. Бу хәлләр татар милли хәрәкәтендә зур ризасызлык тудырды, Татарстанның дәүләт суверенитетына куркыныч янавын аңлап, алар республика җитәкчеләреннән бу юнәлештә катгый адымнар ясавын таләп иттеләр. Милли хәрәкәтнең көчле басымы астында, 1991 елның 24 октябрендә Татарстан Югары Советы «Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында Акт» турында карар кабул итте.

***«“Об Акте государственной независимости Республики Татарстан” Постановление Верховного Совета Татарской ССР***

*Основываясь на Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР, принимая во внимание создавшуюся ситуацию, при которой Республика Татарстан лишена квоты в Верховном Совете СССР и Права участия в подписании Договора об экономическом сообществе независимых государств, Верховный Совет Татарской ССР постановляет:*

1. *Верховный Совет Республики Татарстан подтверждает свою приверженность принципам Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР, не подлежащим какой-либо ревизии. Реализация этих принципов, реальное наполнение суверенитета является обязанностью всех органов государственной власти и управления.*
2. *Республика Татарстан, как суверенное государство, выражает волю и решимость иметь полноправное непосредственное представительство в Верховном Совете СССР, других государственных и межреспубликанских органах Союза ССР, их структурах, а также заявляет о своем праве участвовать в подготовке и заключении соглашений между республиками, затрагивающих интересы Республики Татарстан.*

3. *Учитывая чрезвычайную важность Акта о государственной независимости Татарстана, сознавая ответственность, которая возлагается в связи с этим на высшие органы власти республики, на ее многонациональный народ, поручить Кабинету Министров в месячный срок представить на рассмотрение Верховного Совета ТССР анализ-прогноз изменения политико-правового, социально-экономического положения Республики Татарстан в результате принятия Акта о государственной независимости.*
4. *На основе рассмотрения представленных материалов Верховному Совету подготовить и провести всенародное голосование (референдум) граждан Республики Татарстан по вопросу о государственном статусе Республики Татарстан.*

**Председатель**
**Верховного Совета ТССР Ф. МУХАМЕТШИН**
***Казань, 24 октября 1991 г.»***

*[Республика Татарстан: Новейшая история. События. Комментарии. Оценки / авторы-составители Ф.Х. Мухаметшин и Л.В. Агеева. Казань, 2000. С. 265]*

Дөрес, бу әле дәүләт бәйсезлеге турындагы Акт үзе түгел, ә аны әзерләү буенча карар гына иде, әмма ул тормышка ашырылмады. Югыйсә, Советлар Союзы җимерелеп барган, алдагысы билгесез булган бу катлаулы чорда күп кенә союздаш республикалар дәүләт бәйсезлеге турында актлар кабул итеп куйдылар, Татарстан бу мөһим эшне ярты юлда калдырды. Ул гына да түгел, Татарстанның Россия белән төрле өлкәләрдә килешүләр төзү буенча сөйләшүләр алып баруы да ачыкланды. Моның нәтиҗәсендә суверенитетка куркыныч янавын аңлаган татар милли-азатлык хәрәкәте ашыгыч рәвештә корылтай җыярга һәм Милли Мәҗлес сайларга, дигән карарга килә. Аны оештыру эшләрендә «Иттифак» партиясе, «Суверенитет» комитеты, «Азатлык» татар яшьләре берлеге, «Мәрҗани» җәмгыяте, Татар иҗтимагый үзәгенең Чаллы һәм кайбер бүлекләре катнашты. Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең төп оешмасы Милли Мәҗлесне оештыру эшләрендә катнашмый, безгә билгеле булганча, алар хакимият белән берләшеп, үз Милли Мәҗлесләрен төзергә уйлаганнар, соңыннан бу проект Бөтендөнья татар конгрессын оештыруда чагылыш таба. Әйе, ул чорда СССРның ил буларак юкка чыгуы, миллионлаган татарның читтә аерылып калуы, Татарстан җитәкчеләренең үз милләтенә карата битарафлыгы, зур авырлыклар белән яулап алган бәйсезлекнең юкка чыга баруы татар милләтчеләрен Халык Парламенты – Милли Мәҗлес төзүгә этәрде. Мондый катлаулы сәяси шартларда татар халкының язмышын үз кулына алырлык экстерриториаль милли идарә органы кирәк иде, һәм

Милли Мәҗлес шул эшкә алынды. Корылтай, беренче эш итеп, үзенең вәкаләтләре турында Декларация кабул итте, 6 пункттан торган бу документта корылтай татар халкының мәнфәгатьләрен чагылдыручы бердәнбер орган, дип игълан ителде, аңа татар халкы исеменнән үзбилгеләнергә вәкаләт бирелде, шулай ук корылтайга татар халкы исеменнән дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итәргә хокук бирелде, корылтай араларында эшләү өчен Милли Мәҗлес сайларга рөхсәт ителде.



*1991 ел*

Татар халкының I милли корылтае утызга якын мөһим документ кабул итте, шулар арасында «Милли Мәҗлес турында закон», «Халык җыеннары һәм Милли Мәҗлеснең җирле үзидарә органнары турында закон», «Татар халкының Милли Нәзарәте турында закон», «Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында закон», шулай ук Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Ислам Конференциясенә, дөнья илләренә һәм халыкларына Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеген тануны сорап кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне әйтергә була.

Корылтай шулай ук Милли Мәҗлескә 100 депутат сайлап куйды, Милли Мәҗлеснең беренче рәисе итеп Татарстан Югары Советы депутаты Тәлгать Абдуллин сайланды. Милли Мәҗлес депутатлары арасында Татарстан Югары Советы депутатлары да шактый иде, шулардан Фәүзия Бәйрәмова, Җәмил Сафиуллин, Раиф Галиев, Тәлгать Шиһабиев, Мөдәрис Шәйхиев һәм башкаларны әйтергә була. Милли Мәҗлеснең беренче сессиясендә үк, башкарма орган буларак, Милли Нәзарәт төзелде, аның рәисе итеп Илгиз Бариев билгеләнде. Милли Мәҗлес каршында

милли мәдәният, милли мәгариф, халыкара эшләр, хокук, милли икътисад, дин, экология буенча комиссияләр төзелде, шундый ук комитетлар Милли Нәзарәт каршында да эшли башлады.

Әмма Татарстан җитәкчеләре, хокук саклау органнары, урыс халкы Милли Мәҗлес төзелүне тыныч кына кабул итте, дип әйтеп булмый. Иртәгә корылтай буласы дигән көнне, 31 гыйнварда, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев иҗтимагый оешмаларга каршы указ чыгарды, аларны дәүләт эшләренә тыкшынсалар, җәза көтәсен кисәтте. Ә инде корылтай узып, Милли Мәҗлес төзелгәч, бу мәсьәлә хәтта 7 февраль көнне Татарстан Югары Советы сессиясендә дә каралды, «федералист» урыс депутатлары Милли Мәҗлесне дәүләткә каршы оешма дип гаепләп чыктылар. Нәтиҗәдә, Югары Совет Милли Мәҗлеснең корылтайда кабул иткән карарларын законсыз, дип тапты һәм бу хакта үз карарын кабул итте. Тарих өчен әһәмиятле булганга, аны укучыларга да тәкъдим итәбез:

«Из постановления Верховного Совета РТ

На состоявшемся в городе Казани 1–2 февраля 1992 г. курултае представителей части татарского народа образован Милли Меджлис (Национальное собрание) Татарстана и приняты ряд актов, не имеющих юридической силы.

Учитывая, что в соответствии с Законом Республики Татарстан “Об основах народовластия Республики Татарстан” ни одна партия, ни одна общественная организация не могут присвоить себе право на осуществление государственной власти в Республике Татарстан, Верховный Совет Республики Татарстан постановляет:

1. Признать недопустимыми попытки решения кем бы то ни было неконституционным путем вопросов национально-государственного, экономического и социального развития многонационального народа Республики Татарстан.

*Ф. Мухаметшин,*

*Председатель Верховного Совета Республики Татарстан.*

*7 февраля 1992 года».*

Күрәсез, Татарстан җитәкчеләре Милли Мәҗлеснең хакимияткә килүеннән курыкканнар, аңа каршы хәтта дәүләт дәрәҗәсендә карар кабул ителгән. Әйе, Милли Мәҗлес дәүләтчелек һәм милли мәсьәләләрдә Татарстан җитәкчеләренә көчле басым ясады, чигенүләр булса, Югары Советны үзләре белән алыштырасыларын белдерде. Милли хәрәкәтнең шушы көчле басымы астында, Югары Совет 20 февральдә Татарстанда бәйсезлек буенча референдум үткәрү турында карар кабул итте, ул референдум 21 март көнне үтте һәм Татарстан файдасына булды. Шулай ук

Милли Мәҗлеснең, Татарстан Югары Советындагы милләтче депутатларның көчле басымы астында, 1992 елның 6 ноябрендә Татарстанның яңа Конституциясе кабул ителде. Болар – татар милли хәрәкәтенең һәм Татарстан хакимиятенең уртак башкарган соңгы зур эшләре иде, моннан соң алар бер-берләренә каршы оппозициягә бастылар. Ә хакимияткә, кирәк чакта таяныргa яңа милли оешма кирәк булды, Бөтендөнья татар конгрессы менә шундый вазгыятьтә барлыкка килде дә. Милли Мәҗлес астан, халык арасыннан үсеп чыкса, Татар конгрессы Татарстан Президенты фәрманы белән туды, югарыдан оештырылды. Инде күпләр таныганча, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Мәҗлескә алмашка, аңа альтернатива буларак оешты.

Шушы аермалыкларга һәм каршылыкларга карамастан, Милли Мәҗлес һәм Бөтендөнья татар конгрессы чирек гасырга якын янәшә бардылар, чөнки милләт бер иде. Бу елларда Милли Мәҗлес эчке сәясәт өчен «Татар Кануны», «Гаилә кодексы», «Милли мәгариф концепциясе», «Милли мәхәллә һәм җирле үзидарә программасы» кабул итте, аны халыкка таратты, шулай ук тышкы сәясәттә Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларациясен тануны сорап, Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Халыкара хокук яклау оешмаларына, дөнья парламентларына мөрәҗәгать итте. Бөтендөнья татар конгрессы урыннарда үзенең структураларын, бүлекчәләрен барлыкка китерде, алар барысы да диярлек татар милли хәрәкәтенең элеккеге оешмалары иде. Һәм төбәкләрдәге күпчелек милли лидерлар Бөтендөнья татар конгрессы эшендә дә катнашып киттеләр. Әйткәнемчә, Татар конгрессы зур сәясәткә катнашмады, күбрәк мәдәни юнәлештә эшләде, төрле тармаклар буенча комитетлар төзеп, аларны зур форум-җыеннар дәрәҗәсенә хәтле үстерә алды. Әйе, Бөтендөнья татар конгрессының милләт алдында иң зур эше – ул төрле өлкәдәге белгечләрне барлый һәм берләштерә алды. Һәм болар барысы да минем күз алдымда, минем дә катнашымда булды.

Мин Бөтендөнья татар конгрессының I корылтаенда катнашмадым, чөнки Америкадан, төрки лидерлар форумыннан кайтып җитә алмадым. 1997 елда үткән II корылтайда мин инде делегат буларак катнаштым, секцияләрдә чыгыш ясадым. 2002 елда үткән III корылтайда мине Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитетына сайлап куйдылар, мин анда 2017 елга кадәр хезмәт иттем. Бу елларда без дин әһелләре, авыл эшмәкәрләре, төбәк тарихчылары хәрәкәтләренә нигез салдык, мин өчесендә дә идарәдә идем. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән Сахалин утравында, Ерак Көнчыгышта, Себердә булдым, анда яшәүче милләттәшләребез турында тарихи-документаль китаплар яздым. Шулай ук Татар конгрессының махсус проекты буенча, Чиләбе өлкәсенең

«Маяк» атом берләшмәсеннән зур зыян күргән татарларның тарихын һәм язмышын өйрәнеп, документаль китаплар яздым. Узган гасырның утызынчы елларында Магнитогорскига сөрелгән татарлар турында, кат-кат урынга барып, өйрәнеп, фәнни-популяр һәм әдәби хезмәтләр дә иҗат иттем. Әйе, мин Конгресс мөнбәрен һәм мәйданын милләткә хезмәт итүгә файдаландым һәм моның өчен үкенмим. Әмма минем Бөтендөнья татар конгрессын милләтнең хокук яклаучысы итеп күрәсем килде, Татарстанның дәүләт суверенитетын, татар телен, милли мәктәпләрне, хаксызга рәнҗетелгән милләттәшләребезне яклап, үз сүзен әйтүен ишетәсем килде. Әмма Татар конгрессы хакимият куйган чикләрдән үтә алмады...

Кызганычка каршы, бүген элеккеге милли хәрәкәт юк инде – ул бастырылды, туздырылды, таркатылды, вакыт та үзенекен эшләде. Әмма алар күтәргән идеяләр, милләтнең бәйсезлеккә омтылуы – үлемсез, алар хыялланган гадел тормыш – җәмгыятьнең нигезе, һәм яңа буын, үз вакыты җиткәч, бу идеяләрне тормышка ашырачак әле, ин ша Аллаһ! Һәм киләчәктә Татарстанның, милләтнең бу утыз еллык үзгәрешләр чорына нәкъ менә татар милли-азатлык хәрәкәте гамәлләренә карап бәя биреләчәк. Ә Бөтендөнья татар конгрессы – мондый болганчык чорда, милләт бөтенләй юкка чыкмасын, төпкә китмәсен өчен бер таяныч-мәйдан булып тора алды. Аның язмышы исә Татарстан язмышы белән бик нык бәйләнгән, алга таба Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан булганда гына яши алачак. Шуңа күрә Татар конгрессы берничек тә сәясәттән читтә кала алмый, ул Татарстанның дәүләт суверенитетын күкрәген куеп якларга тиеш булачак, чөнки милләтебезнең башка киң колачлы оешмалары калмады. Татар конгрессы исә татар тормышына, милләт яшәешенә тагы да якынаерга тиеш, югыйсә, ул моңа кадәр иҗтимагый-икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнмәде, шунлыктан җәмгыятьтән шактый ерак торды. Татар конгрессы һәр татар өчен ачык булганда гына милләт тормышына үтеп керә алачак. Ул оешма йөзендә милләт үзенең яклаучысын таба икән, халык аның артыннан китәчәк, Татарстанның дәүләтчелеген саклап, тагы мәйданнарга чыгачак, көрәшкә күтәреләчәк. Язмышыбыз үзебезнең милли азатлыгыбыз өчен туктаусыз көрәштән гыйбарәт, һәм ул тарих бүген дә языла...

Бөтендөнья татар конгрессы өстендә менә шундый олы җаваплылык. Милләтебез һәм дәүләтчелек өчен гасырларга сузылган көрәшне алар дәвам итә алырлармы – монысын вакыт күрсәтер. Дөнья яңадан бүленеп ятканда, Бөтендөнья татар конгрессының Стратегиясе ачык.

***Ф.А. Рәшитов***

# КОНГРЕСС ТАТАРНЫҢ ТАТАРЛЫГЫН РАСЛАП ДӨНЬЯГА ЧЫГАРДЫ



***Аннотация:*** *Ветеран татарского национального движения из Саратова делится своими воспоминаниями о I, II и III съездах Всемирного конгресса татар. Проводится мысль о своевременности и полезности создания этой международной организации. Съезды ВКТ, принятые на них документы, деятельность его Исполкома, способствовали консолидации нации под историческим этнонимом «татары», вывели ее на широкую мировую арену. Вместе с тем отмечается, что положение татарской нации в нынешней РФ ухудшается. Не оправдываются оптимистические ожидания от реисламизации татарского социума. Нация стоит перед выбором новой стратегии своего развития.*

***Ключевые слова:*** *татары, Всемирный конгресс татар, Татарстан, национально-культурная автономия, мусульманская мечеть.*

30 еллык тарихы булган Бөтендөнья татар конгрессы турында фикер йөртү бик тә катлаулы эш. Миңа, Конгрессның беренче оештыру съезды делагаты һәм дә алдагы елларда милли хәрәкәттә якыннан торып катнашкан кеше буларак, бу чорда күп санлы милләттәшләр белән очрашып аралашырга, язмалар, документлар белән танышырга туры килде. Әлбәттә инде, болар барысы да күптөрле хисләр, уй-фикерләр тудырып, аңга сеңеп калганнар. Хәзер минем шушы истә калган вакыйгаларны яңартып, аларны анализлап, бербөтен фикергә килү, үткәнне бәяләү бурычы тора. Ничек кенә катлаулы булмасын, ул юлны үтәргә кирәк.

Башта берничә сүз милли хәрәкәткә килүем турында. Мин элеккеге Саратов губернасы Хвалын өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы) Мостяк авылында туып үстем, туган авылымда татар телендә

җидееллык мәктәпне бетердем. Аннары Пенза өлкәсе Сосновобор эшчеләр бистәсендәге педучилищеның татар бүлегендә укыдым. Шуның өстенә, Саратов университетын тәмамлаганнан соң, бер ел диярлек Иске Кулаткыда 1930 елдан бирле татар телендә чыга торган «Күмәк көч» гәзитендә эшләдем. Кыскасы, минем татар теле, татар мохите белән элемтәм яшьтән үк бик тыгыз һәм нык булды. Менә бу мәкаләмне дә татар телендә үзем язам.

Шул ук вакытта мин кечкенәдән үк безнең татар өчен рус теленең, рус культурасының зарурият икәнлеген аңлап үстем, рус халкының бөек әһелләреннән Пушкин, Толстой, Ленин һ.б. үрнәк алырга тырыштым. В. Ленинга ышанып һәм ияреп, рус патшаларының һәм руханиларының шовинистик сәясәтләрен сүктем, Интернационал ягында булдым.

Саратов университетының аспирантурасын бетергәннән соң, озак еллар шул ук уку йортында студентларны укыттым, анда кандидатлык диссертациясен якладым. Фәнни тикшеренүләр өлкәсендә минем төп игътибарым 1917 елгы Бөек рус революциясенә, революциядә туган Совет дәүләтенә юнәлдерелгән иде. Соңрак игътибарымны Совет власте һәм Сталин чорында аның демократик асылын бюрократик бозу проблемасы җәлеп итте. Ә инде милли мәсьәләгә, татар милләтенең хәленә килгәндә, болар мине борчымады диярлек. Татар халкының саны һәр үткән халыкны исәпкә алуда арта барды, татар китап-журналлары басылды, Казан артистлары Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров һ.б. даими рәвештә Саратовка килеп, концертлар куеп йөределәр. Без хәлебезнең начарайганын тоймый да калдык, дисәк, дөрес булыр.

«Перестройка», «гласность», «демократия» дигән лозунглар күп кенә проблемаларга, шул исәптән милли проблемага да, күзебезне ачты. Дикъкать беләнрәк карасак, СССР / Рәсәйдә без белем алган, татар телендә укыткан мәктәпләр бөтенләй беткән икән бит. Хәтта күп кенә мәктәпләрдә татар балаларына туган телләре дә укытылмый икән. Халыкның күпчелек өлеше яшәгән шәһәрләрдә бернинди дә милли-мәдәни оешмалар юк. Татар баласы булып туган, әмма татар телен белмәүчеләр саны бик тиз арта барган икән, ләбаса.

Менә шушы мөшкел хәлләр татар милли хәрәкәте тууына этәргеч булды да. 1988 елда Казанда университет доценты (КПСС тарихы кафедрасы) Марат Мөлеков җитәкчелегендә Татар иҗтимагый үзәге (ТОЦ) барлыкка килде. Ул үзенең төп максаты итеп Татарстанны СССРның союздаш республикасы дәрәҗәсенә күтәрүне куйды. ТИҮнең тарафдарлары Рәсәйнең төрле төбәкләрендә, шул исәптән Саратовта да, күренә башлады. 1989 елда, югарыда әйткән максатны яклап, бер миллионга якын имза җыелды.

Тора-бара милли хәрәкәттә радикал төркемнәр барлыкка килде. Болар 1990 елның март аенда «Иттифак» исемле Татар милли бәйсезлек фиркасе төзеделәр. Аның лидеры Фәүзия Бәйрәмова Татарстан РСФСРдан чыгарга һәм үзен бәйсез дәүләт дип игълан итәргә тиеш, дигән фикерне алга сөрде.

Шулай итеп, Совет дәүләтенең, ТАССРның яшәеше белән бәйле ыгы-зыгылар, көннән-көн кызып, киеренке төс алды. Бу хәрәкәткә Саратов татарлары да тартылдылар. Шәһәр мәчетенең яшь имамы Мөкаддәс Бибарсов, аның иярченнәре Рушан Сәйфетдинов, Митасим Сөләйманов ТИҮнең съездында катнаштылар. 1988 елның җәендә алар шәһәрдә татар теле курслары оештырдылар. Анда укытучы итеп пединститут доценты Мавия Фатыйхович Зәйнетдиновны чакырдылар. Ул минем өлкән дустым, шуның өстенә авылдашым да иде.

Ниһаять, 1989 елның башында Саратовта татар җәмгыяте, яисә, ул вакыттагы терминология буенча, Иҗтимагый үзәге төзү фикере туды. Әмма бу инициативаны җирле партия – совет җитәкчеләре хупламады. Ахыр чиктә, компромисс буларак, бу җәмгыятьне төзүдә һәм аны алып баруда татар коммунистлары, абруйлы кешеләр катнашырга тиеш, дигән карар чыгарылды. Шундый кешеләр сафына М.Ф. Зәйнетдиновтан тыш, Саратов университетының физика факультеты доценты Р.Ш. Әмиров, Саратовта фабрика директоры М.А. Багдалов һәм шушы юлларны язучы доцент Ф.А. Рәшитов булдылар. Без барыбыз да бу эшкә бик теләп керештек. М.А. Бибарсов һәм аның тарафдарлары белән уртак тел табылды, эшләр җайга салынды. Мин булачак җәмгыятьнең устав проектын төзедем. Һәм 1989-нчы елның 21 маена Саратов татарларының җыелышы билгеләнде. Оештыру комитеты җәмгыятьнең рәисе булырга мине күндерде.

Әйтергә кирәк, Казандагы кебек үк, бездә дә ике фикер булды. Берләре – Фәүзия Бәйрәмова куйган максатны хуплады, икенчеләре – Татарстанның дәрәҗәсен күтәрү яклы иде. Оештыру мәсьәләсендә дә ике төрле фикер бар иде. Бибарсов «партиясе» безнең җәмгыятьнең ТИҮ составында һәм җитәкчелегендә эшләве яклы, ә минем «партия» мөстәкыйльлек ягында булды.

21 май көнендә филармониядә узган зур җыелышта Казаннан ТИҮ вәкилләре катнашты. Монда булган дискуссия нәтиҗәсе буларак, мөстәкыйль оешма төзелде. Ул «Саратовское татарское общественное культурно-просветительное обьединение» дип аталды. Берләшмәнең 30 кешедән торган Советы рәис итеп мине сайлады. Мөкаддәс хәзрәтнең тарафдарлары – Р.И. Сәйфетдинов һәм М.Ш. Сөләйманов рәиснең урынбасарлары булдылар. Берләшмә (аңа тиздән «Идел» исеме бирелде) җирле хакимият органнары белән аңлашып эшләде. 1990-нчы елның

җәй башында Саратовта, тарихта беренче буларак, Сабан туе үткәрелде. Көзен татар якшәмбе мәктәбе ачылды.

Минем милли хәрәкәткә килүем менә шулайрак булды. Әлбәттә, башлап йөргән эшләребез бик тә уңышлы булды, дип әйтә алмыйм. Акчабыз да, җыелырга урыныбыз да юк иде. Мин сәүдә институтында доцент, кафедра мөдире вазифаларын үтим, шуның өстенә докторлык диссертациясе өстендә эшли идем, шунлыктан җәмәгать эшенә вакыт бик аз кала иде. Өстәмә рәвештә тагын бер «йөкне» алдым: җәмгыять әгъзаларына, барлык милләттәшләргә татарның килеп чыгуын, тарихын аңлату. Шушы темага лекция яздым һәм аны җәмгыятьнең җыелышында укыдым. 1991-нче елда бу материал мәкалә формасында Саратовта «Волга» журналында, Казанда «Идел» журналында басылып та чыкты. Ул вакытта, билгеле булганча, «татарчылар» белән «болгарчылар» арасында бәхәс кызып китте. Болгарчылар, безнең милләткә татар исемен большевиклар көчләп тактылар, бу безгә ят исем, дип дәлилләргә тырыштылар. Мин борынгы татарлар да, болгарлар да, кыпчаклар да, хәтта һуннар да, безнең бабаларыбыз дигән фикерне якладым. Татар исемен, большевиклардан элегрәк халкыбызның мәшһүр уллары Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Дәрдемәнд, Габдулла Тукайлар милләт исеме итеп таныганнар һәм югары дәрәҗәгә күтәргәннәр бит.

Шушы киеренке, кызу бәхәсләр барган дәвердә, Мәскәү һәм Казанда зур сәяси вакыйгалар булды. 1990 елның 12 июнендә Русия Федерациясенең дәүләт суверенитеты Декларациясе кабул ителде. Шул ук елның 30-нчы августында ТАССРның Югары Советы Татарстан Республикасының дәүләт суверинента Декларациясен кабул итте. 1991 елның 12-нче декабрендә Советлар Союзы юкка чыгарылды. 1992 елның 21-нче мартында Татарстанда үткәрелгән референдумда Республиканың суверенлыгы гомумхалык хуплавын алды.

1992 елның башында Татарстанның җитәкче даирәләре Казанда татар милләтенең Бөтендөнья форумын үткәрү турында карар чыгарды. Бу җыенда Бөтендөнья татар конгрессы төзү күздә тотылды. Җыенны җәйнең иң матур вакытына, Казандагы Сабантуйларына яраштырып, 19–21 июнь көннәренә билгеләделәр. Ул чараны әзерләү махсус Оештыру комитетына йөкләнде.

Оештыру комитеты Татарстаннан, Рәсәй төбәкләреннән, чит илләрдән киләчәк депутатларның санын билгеләде. Безнең 55 мең чамасы татар кешесе яшәгән Саратов өлкәсенә 3 делегат урыны бирелде. «Идел» берләшмәсенең Шурасы утырышында делегатлар итеп Солтан Рәис улы Әхмәров, Фрид Айни улы Рәшитов һәм Митясим Шиһабетдин улы Сөләйманов сайланды. Тиздән һәркайсыбызга Оештыру комитеты исеменнән Конгресска

чакыру хаты килде. Аны Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы, Татарстан Республикасы хөкүмәте имзаланнар. Бу чакыру минем архивымда сакланып килә.

Казанда, форумда үткәрелгән өч көннең һәрбересе бик тә мәгънәле, уй-хисләргә бай булды. Бигрәк тә Ирек мәйданында башланып, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Пленар утырыш үткәрелгән беренче көн. Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевнең чыгышы тирән эчтәлекле һәм тәэсирле булды. Чыгыш текстында Казан галимнәренең, беренче чиратта, Индус Ризакович Таһировның, Рафаэль Сибгатович Хәкимовның зур, мөһим мәсьәләләрне анализлау һәм тасвирлау сәләте сизелде. Бирелдә ике төп фикер алга сөрелде. Беренчесе: безнең халык, күп гасырлы юл үтеп, шул чорда күп санлы төрки телле кабиләләрне үз эченә алып, татар милләте булып формалашкан һәм безнең изге бурычыбыз, – татар исеме белән, тарихыбыз, телебез белән горурланып яшәргә, милләтебезне саклап калырга, тагы да үстерергә тиешбез. Икенчесе: дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәүче татар кешеләрен бергә туплау, татарны киң дөньяга чыгару һәм таныттыру.

Мин бу юлларны М.Ш. Шәймиевнең чыгышы текстына карамыйча яздым. Минем зиһенемдә бу чыгышның төп эчтәлеге шулай сакланган. Нәкъ шушы эшләр съезда төзелгән Бөтендөнья татар конгрессы программасының үзәгендә торды, дип уйлыйм.

Шулай итеп, 1992-нче елда үткәрелгән съезд «Без кем – татармы, болгармы?» дигән сорауга катгый рәвештә «без – татарлар!», дип җавап бирде.

Биредә шулай ук икенче мәсьәлә дә күтәрелде. Пленар утырышта БТИҮ әгъзаларыннан торган бер төркем делегатлар, татар халкының мәнфәгатьләрен кайгыртуны Милли Мәҗлескә бирергә кирәк, дигән тәкъдим белән чыктылар. Әмма съезд моны хупламады. Ул вакытта инде Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең көче дә, абруе да шактый кимегән иде.

Шулай да проблема – милли хәрәкәттә дәүләт органнарының һәм җәмәгатьчелекнең тоткан урыны, аларның бер-берсе белән мөгамәләсе – кала бирә. Бу – бик җитди, актуаль проблема.

Съездның икенче көнендә делегатлар секцияләрдә эшләделәр, милләтебезнең язмышына кагылышлы төрле мәсьәләләрне карадылар. Мин татарның тарихына багышланган секциядә булдым. Ул Казан университетының тарих факультетында шул факультетның деканы профессор И.Р. Таһиров җитәкчелегендә эшләде. Шунда Индус Ризакович белән танышып, аннары бик якын фикердәшләр, хәтта дуслар булып киттек. Бу турыда соңрак язармын.

Шул ук көннең ахырында съездның икенче пленар утырышы булды. Анда Бөтендөнья татар конгрессы булдыру турында карар кабул ителде.

Конгрессның Башкарма комитеты сайланды. Башкарма комитетның рәисе итеп И.Р. Таһиров расланды.

Өченче көн, 21 июнь, бәйрәм көне, Сабан туе көне булды. Делегатларны Казанның төрле урыннарында үткәрелгән бәйрәмгә алып киттеләр. Безнең делегация Дербышка бистәсендә матур урман эчендә гөрләп үткән Сабан туена эләкте. Мондый тамашаны минем гомеремдә беренче күрүем булды!

Казаннан без канатланып кайттык, җиң сызганып эшкә керештек. Эшебездә дә уңай хәлләр булды. Саратовның Идел буе район Башкарма комитеты, «Идел» берләшмәсенең үтенеченә җавап итеп, татар балалары өчен 1992-нче елның 1-нче сентябреннән махсус урта мәктәп ачарга карар чыгаргач, мәктәпне урнаштырыр өчен уңайлы бина бирелде. Тик бу бинаны ремонтлау татар берләшмәсе өстенә төште. Ничек кенә кыен булса да, бу эш эшләнде һәм мәктәп 1 сентябрьдә ачылды. Бу эшләрдә мәктәпнең мөдире Зәкия Идрис кызы Саласкинаның өлеше гаять зур булды.

Кечкенә генә, йөз баладан торган мәктәбебездә, М.Ф. Зәйнетдинов татар телен, мин тарих дәресләрен алып барырга күндек. Алга таба мәктәп шактый үсеп, зураеп китте, яңа укытучылар килде. Күбесе татарлар булды. Ә инде 1995-нче елда аңа милли татар гимназиясе статусы бирелде. Бу уку йортында бүген 400 бала укып, милли-мәдәни тәрбия ала. Гимназия Саратовта чын мәгънәсендә рәсми рәвештә алып барылган милли тормышның үзәге һәм терәге булып тора.

Эшебез төрле юнәлештә җанланып китте. Җирле телевидениедә, радиода татар тематикасына багышланган төрле тапшырулар, гәзит-журналларда мәкаләләр, интервьюлар чыга торды. Һәр ел июнь аенын беренче шимбәсендә зур күләмле Сабан туе була торды һәм башкалар.

Менә минем кулымда зәвыклы гына ясалган буклет. Аның тышлыгына язылган: «23–29 марта 1993 г. Неделя татарской культуры в Саратовской области, посвященная 750-летию образования татарского государства Золотая Орда». Шушы фестивальнең программасында төрле конкурслар, күргәзмәләр, концертлар белән беррәттән, Казан һәм Саратов галимнәренең, «Золотоордынский период в истории татарского народа» темасына фәнни конференция үткәрү каралган. Чыннан да, бу конференция 1993-нче елның 30 мартында өлкә төбәкне өйрәнү музее бинасында үтте. Мин анда спикер вазифасын үтәдем. Ә инде чыгыш ясаучыларга килгәндә, Казаннан университет профессоры И.Р. Таһиров һәм Ә.Г. Мөһәммәдиев, Саратовтан университет тарихчылары доцентлар Н.М. Малов һәм В.Г. Миронов булдылар. Бу, Рәсәйдә Алтын Урдага багышланган бик күп вакыттан соң үткәрелгән, беренче фәнни конференция булды бугай. Әлеге чара Саратов җирендә урнашкан Алтын Урданың Укәк шәһәрлеген өйрәнүгә зур этәргеч иде.

Казан белән элемтәбез һаман ныгып торды. 1994-нче елның октябрь аенда Саратовта И.Р. Таһиров инициативасы белән һәм аның катнашында конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышы узды. Шуны да әйтеп үтәсем килә: шул ук 1994-нче елның 17 декабрендә Саратовта мин докторлык диссертациясен якладым. Рәсми оппонентларның берсе Татарстан Фәннәр Академиясенең академигы Индус Ризакович Таһиров булды.

**Дәвамы рус телендә**

Последующие годы наши дела в целом шли неплохо. Огромное значение как для Татарстана, так и для России как федеративного государства, имело подписание 15 февраля 1994 г. Договора о разграничении полномочий и предметов ведения. Новые штрихи в национальные отношения в Российской Федерации вносил Федеральный закон «О национально-культурной автономии» от 17 июня 1996 г. В Саратове татарская национально-культурная автономия была создана в феврале 1997 г. активистами объединения «Идел». В конце августа того же года мы участвовали в работе II съезда ВКТ. Он прошёл в обстановке празднования 7-летия Декларации о государственном суверенитете Татарстана. В мае 1998 г. наша национально-культурная автономия участвовала в учредительной конференции Федеральной национально-культурной автономии татар. Замечу, что ни тогда, ни в последующие годы так и не были найдены оптимальные варианты функционирования Федеральной автономии и взаимодействия последней со Всемирным конгрессом татар.

Важное значение для меня лично имела преподавательская деятельность (по совместительству) в национальной татарской гимназии. Разработал учебную программу и специальный курс «История татарского народа» для старших классов гимназии. При этом широко использовал материалы, научные и учебно-методические публикации казанских коллег: И.Р. Тагирова Р.У. Амирханова, Р.Г. Фахретдинова и др. В течение нескольких лет проводил уроки по данному курсу в нашей гимназии. В 2001 г. в Саратовском издательстве «Детская книга» было опубликовано моё учебное пособие по этому курсу.

Рубежными как для России, так и для татарского национального движения, стали первые годы XXI в. К руководству Россией пришёл новый Президент – В.В. Путин. В августе 2002 г. в Казани состоялся III съезд ВКТ. В составе Саратовской делегации я тоже принимал участие в его работе.

Многого ждали делегаты съезда, вся татарская общественность от встречи с приехавшим в Казань новым Президентом РФ. Участвовать на этой встрече мне не довелось. На неё был приглашён руководитель нашей делегации К.А. Аблязов. Отзывы об обстановке встречи, тоне высказываний Путина были положительные. Хозяин Московского Кремля

обещал разобраться с поставленными делегатами съезда вопросами, решить их. Однако, как показала практика, в национальной политике РФ существенных изменений к лучшему позже не произошло. Ни празднование в 2005 г. под эгидой Москвы тысячелетия Казани, ни создание Булгарского музея-заповедника не привели к улучшению положения татар в РФ. В первое десятилетие XXI в. происходило обезлюживание и вымирание татарских сел, закрывались школы, библиотеки. В период между переписями 2002 и 2010 гг. татарское население Саратовской области сократилось на 5000 человек. Ещё более высокими темпами шёл процесс потери татарами родного языка.

Положительное значение как для татар, так и для РФ в целом, имело подписание 27 июня 2007 г. В.В. Путиным и М.Ш. Шаймиевым обновлённого варианта Договора между Федеральным центром и Республикой Татарстан. Как отмечает И.Р. Тагиров, Договор «преодолевая определённые проимперские тенденции в современном российском обществе, расчищает путь для демократического развития страны, укрепляет её договорно-федеративные основы» [История татар в VII томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI вв. Казань. 2013. С. 740]. Дальнейший ход событий, к сожалению, не оправдал этих оптимистичных ожиданий.

III съезд ознаменовался сменой руководства ВКТ. На пост нового председателя Исполнительного комитета был предложен и избран Р.З. Закиров. Уход И.Р. Тагирова многие делегаты восприняли с недоумением. Нам казалось, что он ещё далеко не исчерпал свои возможности и мог принести много пользы в качестве руководителя ВКТ.

Свершившееся означало окончание первого, начального этапа в истории данной международной организации. Главная особенность этого этапа, как определил его и сам И.Р. Тагиров в своём выступлении на съезде, была выработка национальной идеологии [Тагиров И.Р. Наш след в истории (на татарском языке). Казань, 2016. С. 363].

Суть национальной идеологии определяет высшую цель – её сохранение и дальнейшее развитие татарской нации. Главные опоры на пути достижения этой цели: национальная семья, национальная жизнь (община), национальное государство. Собирание, тщательное изучение и умелое использование накопленного исторического опыта как важнейшее условие достижения цели. Описывая, таким образом, национальную идею, Индус Ризакович оставил без внимания то положение, что в любом классовом обществе формируются и существуют и идеологии более высокого порядка, идеологии, выражающие интересы и цели общественных классов. При этом господствующие позиции занимает идеология того класса, в чьих руках находится собственность и власть. Как известно, в

1990-е годы в России произошёл переход большей части общенародной собственности в частные руки. На этой основе произошло формирование новорусской (новотатарской и т.д.) буржуазии, укрепление последней у власти. Соответственно, идеология этого класса заместила бывшую в СССР господствующей идеологию рабочего класса – коммунистическую идеологию, научно-теоретическое обоснование которой дали в своё время классики марксизма-ленинизма.

Индус Ризакович определяет эти процессы как «исчезновение марксизма-ленинизма» и считает это нормальным явлением [Указ. раб. С. 370]. Дело, к счастью, обстоит, не так печально. Марксизм-ленинизм, как и коммунистическая идеология, никуда не исчезли. Буржуазные правительства России, начиная с Б. Ельцина, сделали всё для того, чтобы оболгать, оклеветать и низвести на нет научное марксистско-ленинское учение, лишить рабочий класс идеологии. Взамен ему подсунули псевдоидеологию – ложную идеологию-религию.

Констатируя этот факт, мы вместе с тем не забываем: во-первых, Россия – это не весь мир; во-вторых, действие инъекций официальной буржуазной пропаганды не может длиться вечно. Класс наемных работников еще придет к свей собственной идеологии, станет «классом для себя».

Тогдашние лидеры татарского национального движения, люди, несомненно, умные, просвещенные, почти сплошь с университетским образованием, с учёными степенями и званиями, не рассмотрели главного: на смену застойному, бюрократизированному советскому социализму шел бесчеловечный строй капитализма. Мы приняли этот строй, связывая именно с ним свои надежды на сохранение и свободное, и полноправное развитие татарской нации. Теперь пусть каждый решает: оправдались ли эти надежды, правильным ли был сделанный выбор?

Следующие 15 лет были временем руководства Конгрессом Р.З. Закирова. Хорошо подготовленный, опытный, преданный делу человек. Работал много и плодотворно. Это было время, когда новое общественное устройство в России прочно утвердилось и стало показывать свои «прелести». Большинство россиян оказались на положение наёмных рабов у современных олигархов. Пышным цветом расцвели коррупция, мошенничество, массовые банкротства. Оказавшееся у власти консервативное крыло новорусской буржуазии, вдохновляемое стародавней идеей «единой и неделимой», усиленно строит новую Российскую империю. В этой империи, разумеется нет и не будет места для свободы и самоопределения нерусских народов. Для них готова тюрьма, правда новая, современная и вполне комфортная Им уготована почётная миссия – участвовать в строительстве «Великой русской нации».

В жизни татар и Татарстана за эти годы произошли важные события, мы, татары продолжали идти тем же курсом капитализма, буржуазного обновленчества.



*М.З. Закиев, М.Х. Хасанов, Ф.А. Рашитов, Н.Ш. Хисамов*

На этом пути имеются определённые успехи. Нас радуют достижения Татарстана во многих областях. Вместе с тем мы видим, что продолжаются процессы депопуляции, деэтнизации, постоянно возникают угрозы остаткам государственного суверенитета Татарстана. Может быть, следует поменять стратегию развития? К сожалению, данный вопрос в татарском обществе не обсуждается. Принятый в 2020 г. документ, получил название «Татары: стратегия действия». Хороший, содержательный документ, но в нём нет даже попытки определить стратегию развития нации: откуда и куда идём, на какое наследие опираемся, что отвергаем, что принимаем, утверждаем. Отсутствует объективный анализ и четкая оценка советского периода нашей истории с точки зрения состояния и развития татарской нации. А между тем этот анализ показал бы, что это был самый успешный, плодотворный период в истории татар. Несмотря даже на имевшие место в сталинское время отступления от ленинских принципов национальной политики, на факты грубых нарушений этих принципов. Чего стоит хотя бы советская система школьного образования детей на их родном языке! Возродить бы сегодня эту систему и стало бы гораздо меньше молодых татар без знания родного языка.

При выработке национальной стратегии следует более внимательно, более ответственно разобраться с фактором ислама. В данном вопро-

се мы часто встречаемся с тремя ошибочными позициями. Во-первых, явно преувеличивается роль ислама, мечети в этнокультурной истории татар. К тому же эта роль изображается как однозначно положительная. Во-вторых, резкое снижение роли мечети в советский период рассматривается исключительно и всецело как результат репрессивной политики Советской власти. При этом игнорируются многочисленные факты, свидетельствующие о том, что еще в дореволюционный период в самом татарском обществе появилось критическое отношение к мечети и мусульманскому духовенству, наметился отход передовой части общества от религии. Здесь достаточно назвать имена Габдуллы Тукая, Гаяза Исхаки, Фатиха Амирхана, Галимджана Ибрагимова, их высказываний на этот счет. В послеоктябрьский период добровольный, осознанный отказ от религиозного мировоззрения, атеизм приняли массовый характер. Хотя, конечно, нельзя отрицать того, что в больших масштабах проводилась антирелигиозная работа, причем зачастую топорно, грубыми методами. В третьих, возвращение к исламу безосновательно обьявляется необходимым условием духовно-нравственного оздоровления общества, сохранения и укрепления татарской идентичности, самой татарской нации. Отсюда – курс на массовое строительство и открытие мечетей, подготовка кадров мусульманских священнослужителей, издание массовыми тиражами религиозных книг, журналов и газет и т.п.

А ведь идея исламизма была развенчана в самом начале XX в. сыном муллы, будущим великим татарским писателем Гаязом Исхаки. В своей антиутопии «200 елдан соң инкыйраз», он назвал в качестве первой причины будущего исчезновения татарской нации именно господство мусульманского духовенства в обществе.

Трудно сказать, насколько прав был молодой выпускник Казанской татарской учительской школы в этом своем утверждении. Примерно тогда же еще один будущий национальный гений, выпускник медресе «Мутыгия» в Уральске Габдулла Тукай, провозгласил, что пока существует капитализм, пока капитал служит завесой истины, он не может считать себя мусульманином.

Является ли случайностью тот факт, что именно после того, как мусульманское духовенство и мечеть перестали играть какую-либо заметную роль в татарском обществе, а капиталистические порядки в России были ликвидированы, татарская нация добилась небывалых успехов в своем развитии? Является ли далее, случайностью тот факт, что в постсоветский, капиталистический период нашей истории, когда небывало высокими темпами идет реисламизация татарского общества, этнокультурное состояние нашей нации не только не улучшается, а напротив, ухудшается.

Массовое строительство и открытие мечетей в татарских селах идет параллельно с закрытием школ. Так, в моем родном с. Новый Мостяк в 1996 г. была построена мечеть, а в 2005 г. закрыта восьмилетняя школа, в которой в советское время обучалось 140–150 детей. Здание школы, построенное сельским обществом в 1929 г., стоит в полуразрушенном состоянии как немой укор нерадивым хозяевам. Здание мечети новое, добротное, со всеми удобствами и с отоплением. Но, по словам имама, бывшего учителя школы, махалля состоит всего лишь из 15–17 стариков, а на пятничный намаз приходят 5–7 человек. Ученые вывели закономерность: возвышение в идентичности религиозности ведет к умалению этничности. Вот и пусть подумают татарские предприниматели и высокие чиновники: что строить – мечети или национальные образовательные и культурно-просветительские учреждения?

В свете сказанного представляется контрпродуктивной практика, когда на мусульманскую мечеть возлагают функции воспитания татар в национальном духе. Для этого существуют светские национально-культурные организации. Пусть каждый занимается своим делом. Необходимо при этом озаботиться тем, чтобы не нарушались свобода совести и светский характер государства.

Хотелось бы также обратить внимание на проблему сохранения и углубления демократических принципов и самодеятельных начал в деятельности наших национально-культурных автономий и других национальных организаций. Милли Шура ВКТ и Совет Федеральной НКА татар должны вовремя реагировать на появление в той или иной организации авторитарных, застойных тенденций, негативных явлений и оказывать помощь в оздоровлении обстановки.

Создание в июне 1992 года Всемирного конгресса татар было, несомненно, правильным шагом. Конгресс выполнил задачи огромной важности: консолидировал нацию под историческим именем «татары» и вывел татарскую нацию на широкую мировую арену. Сегодня перед Конгрессом стоит новая, не менее важная задача: мобилизовать и направить ресурсы нации на сохранение родного языка и культуры, татарской идентичности. Предстоит построить и открыть в местах компактного проживания татар десятки, сотни татарских национально-культурных центров, наладить их плодотворную работу. Пожелаем всем нам удачи в этой работе.

*Р.З. Закиров*

## ОЛЫ ЮЛНЫҢ УЗГАНЫ...



Мәгълүм булганча, Европаның күпчелек милләтләре XIX гасырда оеша. Бу үзгәрешләрдән татар халкы да читтә калмый, нәкъ шул чорда татар буржуазиясе барлыкка килә, ул шактый капитал туплый. Әлеге капитал нигезендә милли мәгариф көчле үсеш ала, күпләп татар китаплары бастырыла башлый һ.б... Ә 1905 ел татар тарихында аерым урын алып тора, шул чордагы революциядән соң киң күләмле татар матбугаты барлыкка килә, яңа татар әдәбияты һәм журналистикасы туа, татар театры һәм музыка сәнгате барлыкка килә. Ул дәвердә тарих мәйданына милләтнең көчле шәхесләре чыга: Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Муса Бигиев, Габдрәшит Ибраһимов һ.б. Бу бөек шәхесләр үзләренең эшчәнлеге белән татар халкының дәүләтчелеген торгызырга нигез әзерлиләр. Нәтиҗәдә, 1917 елдагы илдә барган үзгәрешләрдә татар милләте сәяси һәм иҗтимагый яктан әзерлекле булуын күрсәтә. Әлбәттә, татарларның шундый алдынгы карашлары, әзерлекле булулары, яңа хакимиятләргә ошамый. Татарстан Республикасы оешканда, безнеңчә аны 1920-нче елны автономия статусы белән чикләүне шуның белән генә аңлатып була.

Шулай да, берничә гасырдан соң автономия кысаларында гына булса да дәүләтчелекне торгызуны зур казаныш дип санарга кирәк. Иң мөһиме, Татарстан Республикасы, үз статусында каралган бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, көчле үсеш алды. Кыскасы, Татарстан совет автономиясе халкыбыз өчен яңа чорда дәүләтчелек мәктәбе булды. Илдә демократик үзгәрешләр башлангач, халкыбыз янә милли хәрәкәткә күтәрелде һәм 1990 елның 30 августында Татарстан Республикасының Суверенитет Декларациясе игълан ителде. Шулай итеп, Татарстан Республикасы үзенең яңа дәүләтчелек тарихын башлап җибәрде. Бу хәлләргә дә инде 30 елдан артык вакыт узды, шуны әйтергә кирәк – татар халкы нык үзгәрде, аның милли горурлыгы үсте, рухы күтәрелде. Безнеңчә, Татарстан Республикасының алга китеше, алдынгы сафларга чыгуы нәкъ шушы ха-

лыкта барган үзгәрешләр белән бәйле. Бу елларда татар халкының гасырлар буенча басылып килгән дәрте уянды, башкарылган эшләрдән канәгатьлек хисе туды. Мондый яшәү рәвеше кешенең тормышына мәгънә бирә, халыкны берләштерә, яңа үрләргә өнди.

Татарстанның яңа дәүләтчелеге бөтен татар дөньясын берләштерергә мөмкинлек ачты. Мәгълүм булганча, Татарстан Республикасында татар халкының 30% гына яши. Совет автономиясе чорында чит төбәкләрдәге, бигрәк тә чит илләрдәге татарлар белән элемтәләр нык чикләнгән иде. Шушыны истә тотып, 1992 елда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Бөтендөнья татар конгрессын җыю турында фәрман чыгарды һәм шул ук елның җәендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының I съезды җыелды. Дөньяның төрле кыйтгаларыннан килгән делегатларның күпчелеге Казанга беренче тапкыр килгәннәре ачыкланды. Беренче съезд, һичшиксез, татар дөньясында тарихта калырлык зур вакыйга булды. Ул съездда Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты оештырылды, ә аның рәисе итеп танылган галим, академик Индус Таһиров сайланды.

Ул вакыйгалардан соң, узган 30 ел гомер эчендә БТК зур юл үтте. Шушы дәвердә татар дөньясы Татарстан белән бер дулкында яшәүгә иреште. Бүген дөньяның 42 илендә, РФнең 70тән артык төбәгендә татарның 458 милли һәм дини оешмалары эшли, үзара хезмәттәшлек итә. Татарстан Республикасы һәм Бөтендөнья татар конгрессы тырышлыгы белән бүгенге дөньяда татар факторы көчәеп бара. Кайсы гына өлкәне алма – мәгарифме, фәнме, спортмы, икътисадмы, авыл хуҗалыгымы, һәр тармакта милләттәшләребез үзләрен иң яхшы яктан күрсәтә.

Конгрессның III съезды алдыннан, 2002 елда, Татарстан җитәкчелеге миңа оешманы җитәкләргә тәкъдим ясады. Әлбәттә, бу минем өчен көтелмәгән вакыйга булды. Мин бу тәкъдимгә тиз генә ризалашмадым, чөнки аның ни дәрәҗәдә җаваплы булуын сизә идем. Ләкин Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиевнең үтемле сүзләре мине бу вазифага алынуга күндерде. Шулай итеп, III съездда мине БТКның Башкарма комитеты рәисе итеп сайладылар. Әлбәттә, оештыру эшләрендә шактый тәҗрибә туплаган кеше буларак, мин Конгрессның эшчәнлеген дә яңа юнәлешләргә үзгәртергә булдым. Минем аңлавымча, Конгресс эшчәнлегендә аерым чаралар гына түгел, ә системалы киң күләмле хәрәкәт кирәк иде. Күп катламлы һәм күптармаклы татар дөньясын бер юнәлештәге, төрле тармаклы хәрәкәткә китерү – ул үзе катлаулы бурыч булып тора иде. Шушы бурычны аңлап, без зур масштаблы чаралар уздырырга карар кылдык һәм эшкә керештек. Бу чаралар ясалма нигездә түгел, ә татар тормышының үзеннән барлыкка килде.

Әйтергә кирәк, III съездда күп кенә делегатлардан татар яшьләрен милли хәрәкәткә җәлеп итү турында фикерләр яңгырады. Ә Башкарма комитет әгъзасы, Сарытау татарлары лидеры Камил Әбләзов 22 пунктан торган тәкъдимнәрен БТК рәисе өстәленә кертеп салды. Әле дә истә, аның беренче пунктында чит төбәкләрдәге һәм чит илләрдәге татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларында укыту мәсьәләсе куелган иде. Бу проблемалар шактый киң кырлы һәм катлаулы булып чыкты, күп мәсьәләләрне федераль хакимиятләр һәм төбәк җитәкчеләре белән хәл итәргә кирәк булды. Без исә киңрәк бурыч – татар дөньясындагы үзебезнең оешмаларга бәйле аерым яшьләр хәрәкәтен оештыруга алындык. Нәкъ шул вакытта махсус татар яшьләре оешмалары барлыкка килде, аларның саны 50дән артты.

Татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларында укыту турында аерым әйтәсем килә. Бу өлкәдә без махсус программа булдыруга ирештек. Ел саен йөзләгән татар баласы Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, БТК юлламасы белән республика югары уку йортларына укырга керә башлады.

БТКның бу проекты чит илләрдә яшәүче яшь милләттәшләребез өчен бигрәк тә кулай булып чыкты. Әйтик, Кытайдан чыккан 100дән артык татар яшьләре төрле елларда Казан югары уку йортларында уку бәхетенә иреште. Бу гамәл халкыбыз тарафыннан ерак гасырлардан килгән элемтәләрне яңарту буларак кабул ителде. Бүген шушы яшь белгечләр Татарстанда һәм үз илләрендәге җәмгыять тормышында лаеклы урын алдылар. Яшьләр белән тыгыз элемтәдә эшли башлагач, бу эшчәнлекнең төп оештыручысы кирәклеге ачыкланды. Шулай итеп, без 2004 елда, беренче Бөтендөнья татар яшьләре форумын уздырдык, һәм ул чара яшьләргә кагылган бөтен эшчәнлекне колачлады. Ике ел саен уза торган бу форумнар дөньядагы татар яшьләрен берләштерде һәм рухландырды, һичшиксез, яшьләр – милләтебезнең киләчәге, шуңа да алар белән эшчәнлек туктап торырга тиеш түгел. Бу эштә бушлык барлыкка килсә, аны башкалар тутырырга мөмкин.

Илдәге демократик үзгәрешләр чорында иң көчле күтәрелеш дин өлкәсендә башланды, халык рухи азыкка сусаган иде. Шушы күтәрелешнең нәтиҗәсе буларак, Казанның меңьеллыгын бәйрәм итү кысаларында Кол-Шәриф мәчете төзелде һәм ачылды. Шул ук вакытта дин өлкәсендә шактый катлаулы проблемалар булуы да ачыкланды. Иң мөһиме, дин әһелләре арасында бердәмлек булмавы үзен нык сиздерә башлаган иде. Шуны аңлап, БТК дин әһелләрен аралаштыру өчен бер мәйданчык булдырырга алынды. Әлбәттә, ул чорда бу бик четерекле мәсьәлә иде, шуңа да Конгресс башта илдәге мөфтиләрне генә җыйды. Уртак фикергә килү

ул вакытта да җиңел булмады. Ә шулай да бу очрашу тәмамлангач, күпчелек хәзрәтләр Конгресска рәхмәтләрен җиткерделәр. Менә шунда без бу эшнең никадәрле әһәмиятле һәм кирәкле булуын аңладык. Бу уңыштан соң без имамнарның зур күләмле җыеннарын уздырырга кирәк, дигән карарга килдек. Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов бу эшне хуплады һәм ул өлкәдә бик зур ярдәмен дә күрсәтте.

Конгресс дин өлкәсендә эшләр башлаганда, аны аңламаучылар да шактый булды, янәсе, «дин ул башка юнәлеш, безгә кагылмый». Дөресен әйтергә кирәк, үткән дәвердә Конгресс чынлап та бу эшләрдә катнашмаган. Әмма бүгенге дөньяда ислам дине милләтебезнең төп билгеләренең берсе булуы – көн кебек ачык. Шуңа да Конгресс илкүләм хәзрәтләр җыеннарын «Дин һәм милләт» шигаре астында уздыра башлады. Беренче форумнардан ук билгеле булды, татар дин әһелләре аралашуга, фикер алышуга бик мохтаҗ икән. Кыска гына вакыт эчендә катнашырга теләүчеләр саны меңнән артты. Соңрак, илдән җыелган дин әһелләре форумның Координацион Шурасын сайладылар, аның рәисе итеп галим, академик Рафикъ Мөхәммәтшин билгеләнде. Шулай итеп, форумның оештыру эшләре бер системага салынды. Хәзер башта форумнарның көн тәртибе һәм иң четерекле мәсьәләләр шушы Координацион Шура утырышларында тикшерелә.

Дин әһелләре форумнарының милли тормышка тәэсире бик тиз сизелде. Яшерен-батырын түгел, мәчетләребездән татар телен кысрыклап чыгара башлаганнар иде. Мондый күренешләр Рәсәй төбәкләрендә генә түгел, Татарстанның үзендә дә пәйда булды. Бу тискәре күренештән арыну йөзеннән, татар дин әһелләре җомга вәгазьләрен татар телендә генә укырга, дигән карарга килделәр. Күп кенә мәчетләрдә бүген бу карар үтәлә. Татарстан Диния нәзарәте һәм аның җитәкчесе мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин бу эшне эзлекле һәм кыю алып бара. Шулай итеп, дин әһелләребез татар телен саклау эшенә дә лаеклы өлеш кертәләр. Кызганыч, кайбер төбәкләрдә бу эшнең никадәр мөһим булуын аңлап бетермиләр. Нәтиҗәдә, андый төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез хәтта тарихи татар мәчетләреннән дә читләшәләр. Күп кенә төбәкләрдә имамнар «татарлар мәчеткә йөрмиләр», дип зарланырга яраталар, ә бит сәбәбе бик гади – дин белән милләт эше тыгыз бәйләнештә, әгәр моны инкяр итәләр икән, милләттәшләребезнең мәчеттән читләшүләре бер дә гаҗәп түгел.

Моның хаклыгын Иваново шәһәрендәге мәчет мисалы раслый. Андагы милли оешма җитәкчесе дини эшләрне дә үзе җитәкли. Бу – Фәрит Ляпин. Аның мәчете кырында милли-мәдәни үзәк тә уңышлы эшли. Мәчеттә татар теле дәресләре дә бирәләр. Әлбәттә, татарлар да бу мәчеткә бик теләп йөри.

Мәгълүм булганча, татар халкында Бөек Болгар тарихына ихтирам һәрвакыт зур булды. Элек-электән изге Болгар җире халкыбызны үзенә тартып торды, һәр заманда әби-бабаларыбыз анда барып дога кылуны изге гамәл дип санадылар. Дини яңарыш башлангач, халык анда күпләп йөри башлады. Шуны күреп, БТК бу эшне яңача оештыруның кирәклеген аңлады. Илдәге барлык дин әһелләре белән киңәшкәннән соң, без «Изге Болгар җыены» дип аталган яңа чараны гамәлгә куйдык. Аның беренчесенә үк, Конгрессның чакыруын кабул итеп, 50 меңнән артык дин кардәшләребез җыелды. Бүген инде бу чарага һәр елны алдан әзерләнеп, барлык төбәкләрдән меңләгән кеше килә, Татарстан Республикасы Шәһре Болгарны торгызып, аны дөньяга танытуга күп көч куйды һәм куя. Моны халкыбыз югары бәяли, чөнки ул милләтне берләштерә, Татарстан тирәсенә туплый.

Конгресс эшенә керешкәч, төбәкләргә йөри башлагач, милли тормышны дин белән бергә алып бару кирәклеге ачыкланды. Әйтик, төбәкләрдә татар имамнарына мохтаҗлык зур. Шуны аңлап, без Казандагы Русия Ислам институты белән хезмәттәшлек итә башладык. Безнең тырышлык белән бу уку йортында татар теле барлык студентлар өчен төп фәннәрнең берсенә әйләнде. Бу фәнне укытуның максаты – барлык яшь белгечләр татар телендә камил итеп вәгазь сөйли белергә тиешләр, һәм бүген бу таләп, шактый кыенлыкларга да карамастан, үтәлә башлады. Әйтергә кирәк, Казанга татар оешмалары юлламасы белән укырга килгән яшьләрнең бер өлеше нәкъ шушы Ислам институтын сайлый. Мондый эш максатчан алып барыла. Яшь белгечләр исә, үз төбәкләренә кайтып, дин эшләрен җитәкләргә тиешләр. Әлбәттә, бу өлкәдә проблемалар әлегә җитәрлек, әмма мондый милли кадрлар әзерләнә икән, алга китеш, һичшиксез, булачак.

Илебез базар шартларына күчкән чорда милләттәшләребез арасыннан бик күп уңган, булдыклы кешеләр килеп чыкты. Аларның шактый өлеше урыннардагы милли тормышның чыгымнарын үз өсләренә алдылар. Ә кайберләре милли оешмаларны җитәкләп тә киттеләр. Оешкан көннәреннән башлап, БТК шушындый эшлекле милләттәшләргә таянды. Мин Конгресска эшкә килгәндә «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумнары инде уздырыла башлаган иде. Хәтерлим, бу форумнарда һәрдаим Татарстанда җитештерелгән продукцияне төбәкләрдә сату мәсьәләсе күтәрелә иде. Ә бу эшне нәкъ татар эшмәкәрләре җитәкләде. Утызлап төбәктә «Татарстан сәүдә йортлары» барлыкка килде, әмма аларның хокукый статуслары сай булу сәбәпле, кызганыч, бу эшләр әллә ни күтәрелеп китә алмады.

Татар эшмәкәрләренең милли тормышта катнашулары турында аерым әйтәсем килә. Мәсәлән, Сарытау шәһәрендәге эре бизнес вәкиле

Камил Әбләзов озак еллар үз хисабыннан татар мәктәбенә ярдәм күрсәтә. Ул шулай ук Алтын Урда чорына караган Үкәк шәһәренең тарихын өйрәнү мәсьәләләрен, аңа багышланган конференцияләр уздыруны, тарихка багышланган китаплар чыгаруны үз өстенә алды. Мондый мисаллар күп кенә башка төбәкләрдә дә бар. Самара шәһәре бизнесмены Фәхретдин Канюкаев Камышлы район үзәгендә узган Бөтенрусия авыл Сабан туеның 5 миллион сум чыгымнарын берүзе күтәрде. Ә Ульян өлкәсе эшмәкәре Эдуард Ганиев үзен данлыклы татар меценаты итеп танытты. Аның күп санлы изге гамәлләрен үз җирендә генә түгел, башка бик күп төбәкләрдәге милли һәм дини оешмалар тоеп яшәде. «Түгәрәк уен» татар фольклор бәйрәмнәрен финанслауны да ул үз өстенә алды һәм озак еллар бу эшне алып барды. Эдуард Ганиев инде безнең арабызда юк, әмма аның якты истәлеге күңелләребездә бүген дә яши. Якташлары аның истәлегенә «Ганиев укулары»н башладылар. Әлеге чара һәр елны Ульян өлкәсенең Кулатка район үзәгендә БТК катнашында уза.



*«Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы*

Соңгы елларда татар тормышының иң авырткан мәсьәләсе – татар авыллары яшәеше. Сер түгел, авылларда халык картая. Бу тискәре күренешләрне Татарстан авылларына керткән зур инвестицияләр дә әлегә әкренәйтә алмый. Бер буын яшәешендә авылларда балалар саны нык кимеде, шул сәбәпле халкыбызга зур шәхесләр биргән атаклы мәктәпләр дә күзгә күренеп сүрелә бара. Ә соңрак, «оптимальләштерү» шаукымына эләгеп, аларның инде шактые ябылды. БТКна эшкә килгәч, минем өчен бернәрсә ачыкланды: шәһәр белән авылда милләт яшәеше бер-берсеннән нык аерыла, һәм Конгресс эшчәнлегендә моны исәпкә алмау – зур ял-

гышлык булыр иде. Мин үзем авыл баласы булсам да, бүгенге авылның үзгәрешләрен якыннан күрү теләге белән, илдәге уңышлы татар авылларын йөреп чыгарга булдым. Шулар арасында Самара өлкәсенең Гали, Чувашстанның Шыгырдан һәм Тукай авыллары, Мордовиянең Азүркә, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авыллары. Бу авыллар мине таң калдырды: андагы матур-матур йортлар һәм мәчетләр, асфальт түшәлгән юллар, ә иң мөһиме – балаларның күплеге. Бу могҗизаның серләре бик гади булып чыкты: андагы халык, шәхси милеккә таянып, эшмәкәрлеккә керешкән. Хәтерлибез, базар шартларына күчү беркем өчен дә җиңел булмады, ә бу авылларда һәркем үз көнен үзе күрергә әзер булган. Әйтик, шул ук Гали авылында күпчелек гаиләләр, бәрәңге бакчаларында парниклар корып, яшелчә үстерергә керешкән. Продукцияне күпләп җитештерә башлагач, якындагы шәһәр ширкәтләре ул товарны урынга килеп сатып ала башлаганнар. Күрәбез, андагы халык хөкүмәттән дә, «инвесторлардан» да нидер көтеп ятмаган, авыл кешеләре үз көчләре белән яшәүне өстен күргән. Бу авылларның тагын бер үзенчәлеге турында әйтмичә булмый: аларда мәхәлләләр оешкан һәм анда дини тормыш яхшы куелган. Эшмәкәрләр төзегән өр-яңа мәчетләр мәхәллә тормышының үзәге булып тора.

Урта Әләзән авылында исә 11 мәчет тирәсендә милли тормыш кайнап тора. Авыл муниципаль берәмлеге җитәкчесе үзенең эшчәнлегендә әлеге мәхәлләләргә таянып эш итә.

Мондый авыллар тәҗрибәсе белән танышканнан соң, без, Конгресс аша, аны илдәге башка татар авылларына таратырга кирәк, дигән фикергә килдек. Шулай итеп, 2012 елның язында I Бөтенрусия татар авыллары эшмәкәрләре форумы узды. Әлеге чара татар дөньясында зур кызыксыну уятты, шушы нигездә Бөтенрусия татар авыллары оешмасы барлыкка килде. Аның беренче рәисе итеп Чувашстанның Озын Куак авылы эшмәкәре Рәшит Сәнҗапов сайланды. Бүген бу оешманы Башкортостанның Туймазы районы Төмәнәк авылы эшмәкәре Фәнир Галимов җитәкли. Алар икесе дә эшмәкәрлек белән бергә җәмәгать эшләрен дә оста алып баручы шәхесләр.

Конгрессның эшмәкәрләр белән эшләп китүе Татарстан җитәкчелегендә зур кызыксыну уятты. Гали авылындагы гаиләләрнең эш тәҗрибәсе белән танышканнан соң, Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов әлеге тәҗрибәне республика авылларында таратырга, дигән күрсәтмәсен бирде. Быел бу җыеннарның инде унынчысы узды, бер чорда анда катнашучыларның саны меңнән арткан иде, соңгысында, пандемия сәбәпле, 500 делегат белән генә чикләнергә туры килде. Бүген авыл мәсьәләсе нинди генә катлаулы булмасын, без илдәге эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек алып барып, бу вакытлы кризистан чыгу юлларын таптык кебек һәм авылларны күпчелек халкы катнашкан эшмәкәрлек хәрәкәте коткарачак.

БТКның мәдәният, халык традицияләренә кагылган проектлары турында да әйтеп китәсем килә. Болар: Сабантуй бәйрәмнәре, фольклор фестивальләре, «Татар кызы» конкурслары, жыр фестивальләре. Шушы чаралар нигезендә күпчелек төбәкләрдә дистәләгән иҗат коллективлары барлыкка килде. Алар өчен Татарстанга килеп чыгышлар ясау зур дәрәҗә булып тора һәм без аларга мондый мөмкинлекләрне бирдек. Мондый чыгышлар мөмкинлеге илебездәге коллективлар белән бергә чит илләрдән килгән милли төркемнәргә дә бирелде. Татарстан халкы әлеге чыгышларны аеруча җылы кабул итә, шулай итеп, читтә яшәп тә халкыбыз моңнарын, аның рухи байлыгын саклаган өчен рәхмәтле булуын күрсәтә. Татар халкын берләштереп торучы төп чара – Сабантуй. Бүген илебезнең күпчелек төбәкләрендә Сабан туе андагы рәсми бәйрәмнәр исемлегенә кертелде, һичшиксез, мондый күренеш Татарстан Республикасы һәм аның Президенты Р.Н. Миңнехановның абруе турында сөйли. Бу чара аша төбәкләрдәге милләттәшләрнең андагы тормышка йогынтысы да арта бара.

Татарлар яшәгән чит илләрдә дә Сабантуйлар үткәрү гадәткә керде. Төркия, Кытай, Австралия, АКШ, Канада илләрендә Сабантуйлар инде күптән оештырылып килсә, Аурупа берлегенә кергән илләр өчен бу әле яңалык. Соңгы елларда Бөтенаурупа сабантуйлары Рига (Латвия), Берлин (Алмания), Вильнюс (Литва), Таллин (Эстония) шәһәрләрендә уңышлы узды. Шушы уңышларны күреп, Русия тышкы эшләр министры С.В. Лавров чит илләрдәге татар оешмаларының эшчәнлеге турында: «Бу – илебезнең йомшак көче», – дип әйтте. Мондый сүзләр юкка гына әйтелмәгән, БТК дистә еллар инде Тышкы эшләр министрлыгы белән хезмәттәшлек итә.

Мин БТК җитәкчелегенә килгәч, Мәскәүдә Халыкара Русия ватандашлары оешмасы барлыкка килде, безнең Конгресс аны оештыручыларның берсе булды.

Татар Конгрессы өчен ул елларда иң четерекле мәсьәлә – Башкортостан татарларының мәнфәгатьләрен хәл итү булып тора иде. 2002 елның декабрендә халык санын алу чарасы мәсьәләне тагын да катлауландырды. Берише милли активистлар Башкортостан җитәкчелеге белән турыдан-туры каршылыкка керделәр, һәм, әйтергә кирәк, мондый каршылык андагы татарларның тормышын тагын да катлауландырды. Ике республика арасында мәдәни багланышлар нык кимеде. Татар телендәге тапшыруларга зур мохтаҗлык булуга карамастан, Татарстан телевидениесен Башкортостан кабель челтәрләренә кертмәделәр. 2007 елгы IV съездга әзерләнгәндә, без мондый каршылыкны туктатырга кирәк, дигән фикергә килдек. IV съезд татар һәм башкорт халыкларына юнәлтелгән махсус мөрәҗәгать кабул итте. Ул мөрәҗәгатьтә ике тугандаш халыкның уртак тарихы,

мәдәнияте һәм мәнфәгатьләре турында тәфсилләп әйтелгән иде. Мондый гамәлләрдән соң, вазгыять шактый йомшарды, ниһаять, Башкортостанда да Татарстан телевидениесен карый башладылар, ике республиканың иҗат коллективлары янә бер-берсенә гастрольләргә йөри башлады, Башкортостаннан чыккан татарның бөек шәхесләренә дә мөнәсәбәт үзгәрде, аларны зурлау мөмкинлеге ачылды. Бүген Башкортостан җирлегендә ике профессиональ татар театры, дистәләгән фольклор коллективлары иҗат итә. Кыскасы, яңа гасыр башында килеп чыккан киеренкелек кимеде кебек. Бу, әлбәттә, татар халкының мәнфәгатьләренә туры килә.

Мәскәүдәге ватандашлар оешмасы нигезендә чит илләрдәге татар оешмалары белән эшләү шактый җиңеләйде. Тышкы эшләр министрлыгының «Россотрудничество» оешмасы аркылы чит илләрдәге татарлар мәнфәгатьләрен андагы илчелекләр аша яклау мөмкинлеге ачылды. Нәкъ шул чорда БТК «Россотрудничество» оешмасы белән ике яклы килешү имзалады һәм шуның аша чит илләрдә эшчәнлекне киңрәк җәелдерде. БТК һәм Европа Берлегендәге татар оешмаларының кыю хәрәкәт итүе турында аерым әйтәсем килә. 2013 елда Европа парламенты бинасында Европа татарлары Альянсының (АТА) оештыру җыелышы узды, ул җыелышта Русия тышкы эшләр министрлыгы вәкилләре дә катнашты. Шул җыелыштан соң, әлеге оешма Бельгиядә рәсми теркәлү узды. Шуның аша андагы татарларга мәдәни чаралар уздырганда төрле халыкара оешмалар ярдәменә таяну мөмкинлеге ачылды. Инде телгә алынган Аурупа сабантуйлары нәкъ шул нигездә оештырылды. Бу эштә Русия Тышкы эшләр министрлыгы да читтә тормады, һәр елны Сабантуйлар уздыруга махсус акчалар да бүлеп бирде.

Шулай ук Татарстан Президенты чит илләргә рәсми сәфәр белән килгәндә, андагы татар оешмалары төрле мәдәни чаралар уздыралар. Татарстан Президенты катнашында Габдулла Тукайга багышланган юбилей кичәләре Анкарада (Төркия), Дрезденда (Алмания), Хельсинкида (Финляндия) узды. Шулай ук Р.Н. Миңнеханов катнашында зур мәдәни чаралар Брно (Чехия), Оттава (Канада), Сан-Франциско (АКШ), Будапешт (Маҗарстан), Урумчи (Кытай), Аделаида (Австралия), Астана (Казакъстан) һәм Бишкәк (Кыргызстан) шәһәрләрендә узды.

Татар тарихына кагылган халыкара чаралар турында да әйтәсем килә. Мәгълүм булганча, Польша-Литва дәүләтләрен саклау сугышларында татар гаскәрләре электән мөһим урын тоткан. Шуңа күрә ул дәүләтләрдә татарларга хөрмәт бик зур. 2010 елда Польшаның Гданьск шәһәрендә тантаналы рәвештә татар гаскәриенә һәйкәл ачылды. Бу чарага Татарстан вәкилләре дә чакырылган иде, шулай итеп анда миңа катнашырга туры килде. Тантана исә халыкара мәгълүмат чараларында да киң яктыртылды.

Татарның йогынтысы көчле булган чит илләр бар, шулар арасында Үзбәкстан дәүләтен, Казакъстанны һәм Кыргызстанны билгеләп үтәргә була. Бу илләрдә татар зыялылары инде XIX-нчы гасырда ук мәгърифәт-мәдәният өлкәләрендә тәрбия-агарту эшләре алып барганннар. Татар мөгаллимәләре һәм мөгаллимнәре ерак кышлакларга килеп мәктәп-мәдрәсәләр ачып, балаларга белем биргәннәр, олыларны уку-язуга өйрәткәннәр. Татар укытучылары аша бу илләрдә җәдиди мәктәпләр барлыкка килгән, ул мәктәпләрдә җирле халыктан милләт зыялылары тәрбияләнгән. Мондый йогынты читтән торып тәэсир итү генә булмаган, анда килеп төпләнгән татарларның бик күпләре җирле халык белән туганлашкан, үзара мөселман гаиләләре корылганнар. Шундый гаиләләрдән чыккан атаклы шәхесләрнең булуы, мондый күренешнең киң таралуын тасвирлый. Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов, Бибигөл Түләгәнова, Камил Муллашев, Чыңгыз Әхмәров, Мидхәт Булатов, Латыйф Хәмиди, Айсылу Токымбаева, Фуат Мансуров кебек шәхесләрнең исемнәре бөтен дөньяга билгеле. Аларның иҗатлары җирле мәдәнияткә хезмәт итсә, исемнәре татар халкын зурлый, бүгенге буыннарда милләтебез өчен горурлык хисләре уята. Бу илләрдә татар оешмалары иң көчлеләрдән санала, чөнки аларның нигезе бик нык һәм тирән тамырлы. Андагы татар зыялыларының яңа буыны да үзен сынатмый һәм югары дәрәҗәдә милли эшчәнлек алып бара. Бу илләрдә бүген дә татарлардан чыккан зур галимнәр, сәнгать әһелләре, музыкантлар, рәссамнар, артистлар, җырчылар бар.

Бу илләрдәге татар оешмалары турында шуны әйтергә кирәк, көчле диаспора булган җирдә милли оешмалар да көчле. Андый оешмалардан чын лидерлар да үсеп чыга. Үзбәкстан татарлары җитәкчесе Ришат Нәбиуллин, Казакъстан татарларыныкы – Тәүфикъ Кәримов, Кыргызстан татарлары лидеры Гөлсинә Ульмаскулова шундыйлардан.

Алар өчесе дә озак еллар дәвамында татар тормышын әйдәп баралар. Аларның тырышлыгы белән, җирле хакимиятләрнең татарларга карата уңай мөнәсәбәте урнашты. Бу дәүләтләрдә Татарстанның югары дәрәҗәсе, андагы татарларның абруе, тоткан урыны белән бәйле дип карарга кирәк. Шулай итеп, чит илләрдәге татар диаспоралары илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүдә дә үзен сиздерә.

1990-нчы еллардагы милли күтәрелеш халкыбызда үз тарихы белән кызыксынуны нык арттырды. Сер түгел, совет чорында татар тарихын өйрәнү шактый чикләнде, ә Алтын Урда тарихы гомумән тыелган иде. Татарстан мөстәкыйльлеге республиканың Фәннәр Академиясен ачарга мөмкинлек бирде. Академия кысаларында профессионал тарихчыларны туплаган махсус институт эшли башлады. Шушы елларда, институт тырышлыгы белән, 7 томлы «Татар тарихы» дигән фәнни хезмәт тә нәшер ителде.

Бөтендөнья татар конгрессы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә булды. Халкыбызда милли үзаң тәрбияләүдә алар актив катнаштылар. Конгресс һәм аның оешмалары уздыра торган күп санлы фәнни-гамәли конференцияләр, төрле юбилейлар, тарихи вакыйгалар һәм бөек шәхесләргә багышланган «укулар» һәрвакыт бу институт галимнәре катнашында узды. Икенче яктан, тарихи эзләнүләргә күп санлы һәвәскәр тарихчылар да килеп керде. Аларның хезмәтләре күпчелек очракта җирле халыкның һәм татар авылларының тарихларын өйрәнү белән бәйле. Әлеге һәвәскәр тарихчылар, шушы эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, үз хисапларына матур-матур китаплар чыгара башладылар, һичшиксез, бу күренеш халкыбызның иң асыл сыйфатларын тасвирлый, бу – милләтебезнең үзеннән чыккан хәрәкәт. Мондый басмалар саны йөзләр белән исәпләнә башлагач, БТК бу хәрәкәтне үз тирәсендә тупларга кирәк, дигән фикергә килде. Шулай итеп, Конгресс Бөтенрусия төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыятен оештырды. Ә илебезнең бик күп төбәкләрендә әлеге җәмгыятьнең оешмалары барлыкка килде. Һәвәскәр тарихчыларның хезмәтләре белән танышкач, Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов аларны югары бәяләде һәм Конгресска хәрәкәтне киңәйтергә, дигән күрсәтмә бирде, һичшиксез, мондый күренеш татар халкында югары үзаң булуны тасвирлый һәм бу юнәлеш гамәли нәтиҗәләр дә бирә башлады. Әйтик, Конгрессның бу юнәлештәге яңа проекты барлыкка килде. Ул илнең һәм чит илләрнең шәһәрләрендә яшәп килгән татар бистәләрен өйрәнү, саклау һәм торгызуга багышланган, һәм бу проектка йөзләгән һәвәскәр тарихчылар кушылды.

Татарстан Президенты фәрманы белән барлыкка килгән Бөтендөнья татар конгрессы халкыбызның милли бердәмлеген төп максат итеп куйды. Шушы бердәмлек аша дөньяга сибелгән татар халкы Татарстан тирәсендә ныграк туплана башлады. Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды – меңләгән кеше катнашында зур чаралар уздырганда, милләттәшләребез, кайда гына яшәсәләр дә, хәтта дөньяның иң ерак почмакларыннан, үз акчаларына Казанга килеп җитәләр иде. Шөкер, бу күренеш бүген дә шулай дәвам итә.

Әлегә чаклы халкыбызның бу сыйфатына сокланып яшим. Татар кешеләренең Казанга тартылуын күргәч, без Конгресста этнотуризм юнәлешен башлап җибәрергә булдык, һәм бу эш бик уңышлы китте, Конгресс аппаратында махсус кешеләр билгеләп, күпләп милләттәшләребезне кабул итә башладык.

Аларның юл чыгымнары һәм яшәүләре үз өсләреннән булса, мәдәни чараларны һәм экскурсияләрне Конгресс оештыра иде. Сәфәрләре

тәмамланганда безнең бинада аралашып, китаплар бүләк итеп, милләттәшләребезне озата идек.

Бигрәк тә Башкортостаннан килгән төркемнәрнең күплеге хәтердә саклана. Алар арасында укытучыларның, әти-әниләренә ияреп килгән балаларның да булуы күзгә ташлана иде. Ике як өчен дә зарыгып көтеп алган мондый аралашулар, күңелләрне нечкәртеп, бик җылы уза торган булды. Милләттәшләребезнең «без әле монда яңадан кайтабыз», дип аерылганнары әле дә хәтердә.

Шушы этнотуризм кысаларында күп кенә төбәкләрдән һәм чит илләрдән милләттәшләребезнең иҗат төркемнәре килде. Аларның Казан сәхнәләрендә һәм Татарстан районнарында уңышлы һәр чыгышы милләт бәйрәменә әверелде. Мондый чараларның тәрбияви әһәмияте ике як өчен дә бәяләп бетергесез. Шул елларда Конгресс кабул иткән иҗат төркемнәре Финляндиядән, Төркиядән, Австралиядән, АКШтан, Кытайдан, Үзбәкстаннан, Казакъстаннан һәм илебезнең дистәләгән төбәкләреннән килде. Бу Русия халыклары өчен уникаль күренеш һәм монда халкыбызның никадәр көчле-кодрәтле булуы күренә.

БТК эшчәнлеген Татарстан Республикасы уңышларыннан аерып карау мөмкин түгел. Конгресс – Татарстанның иң уңышлы проектларының берсе, дип әйтсәк, ялгыш булмас. Шушы проект татар дөньясын берләштерде, аның куәтен бер максатка юнәлтә алды. Миллионлаган милләттәшләребезнең яшәешенә бу уникаль оешма мәгънә бирде, аның аркылы илдә татар факторы барлыкка килде. Татарлар бүген илдә иң югары даирәләргә үтеп керделәр. Алар Русия хөкүмәтендә дә, Дәүләт парламентында да, төбәкләр җитәкчелегендә дә, зур бизнеста да, фән, сәнгать, спорт өлкәләрендә үзләрен иң яхшы яктан күрсәтәләр. Мондый уңышлар халкыбызның көч-куәтен ачып сала, аның якты киләчәгенә өмет уята. Әгәр БТК 30 ел дәвамында уңышлы эшләп килә икән, моның нигезендә, һичшиксез, халкыбызга таяну төп фактор булып тора. Безнең чит илләрдәге милләттәшләребез дә сынатмый. Конгрессның алар белән эшчәнлеген илнең Тышкы эшләр министрлыгы да югары бәяли. Русия ватандашларының халыкара җыеннарда тышкы эшләр министры Сергей Лавров һәрвакыт Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеген башкалар өчен үрнәк итеп куя. Бу – Татарстан Республикасы өчен дә зур дәрәҗә, чөнки шундый бәя илнең төбәкләре арасында аның аерым урынын билгели.

## Россия Федерациясе төбәкләрендәге милли оешмалар сөйли
## Рассказывают татарские организации Российской Федерации

*И.М. Галяутдинов,*
*А.И. Минастинова*

# ИСТОРИЯ САМАРСКОЙ РЕГИОНАЛЬНОЙ ТВОРЧЕСКОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ «ДУСЛЫК» («ДРУЖБА»)

На нынешнем этапе своего развития татарская нация находится на пути консолидации сил в целях сохранения своих исторических корней, богатого национального языка, культуры, традиций, своей духовности. Огромную роль в этом процессе играет Международный Союз «Всемирный конгресс татар» (ВКТ) как наиболее оптимальная организационная форма, вобравшая в свою орбиту всех татар, проживающих в Российской Федерации, а также почти во всех странах мира. Он является не формальной организационной структурой, а живым организмом, который повседневно занимается реализацией «Стратегии действия», разработанной недавно на основе учета исторического прошлого, настоящего и будущего татарского народа.

В целях активного вовлечения татарского сообщества в реализацию «Стратегии», ВКТ опирается на национально-культурные общественные организации в регионах компактного проживания татар, на их опыт, активно поддерживая и стимулируя их активность, самостоятельность.

Примером этому может служить деятельность татарских национально-культурных общественных организаций в Самарской области. Среди десятков подобных организаций и творческих коллективов наиболее деятельной является Самарская региональная творческая общественная организация (СРТОО) «Дуслык» («Дружба»), созданная более десяти лет по инициативе ее президента Канюкаева Фахрутдина Бадретдиновича. Являясь членом Национального Совета ВКТ, он стал подлинным проводником идей «Стратегии» в регионе. Задачей его деятельности стало объединение и направление усилий многочисленных национальных общественных организаций в единое русло. Работая в тесном контакте с Областной национально-культурной автономией, которую возглавляет Анвар Горланов, с руководством Регионального Духовного управления мусульман, возглавляемым муфтием Талипом Яруллиным, а также

другими общественными организациями и творческими коллективами, Фахрутдин Канюкаев достиг главного – согласованности действий при проведении национально-культурных общественно-значимых мероприятий в городах и районах области.

Самарская региональная творческая общественная организация «Дуслык» («Дружба») была создана 10 мая 2011 г. Созданная при СРТОО «Дуслык» («Дружба») с 2015 г. действует Самарская региональная общественная организация татарских женщин «Ак калфак».

Основными целями деятельности этих организаций являются: содействие развитию культуры татарского народа, всестороннему развитию личности средствами культурно-просветительской деятельности; создание условий для практического осуществления программ сохранения и возрождения традиций народного творчества, поддержки инициатив самодеятельных коллективов и содействие их реализации; содействие творческой профессиональной деятельности работников социально-культурной сферы; создание условий для сохранения национального языка; возрождение приверженности к национальным, духовно-нравственным обычаям и традициям; выявление и поддержка талантливой молодежи, обеспечение условий для саморазвития и содействие росту самосознания молодого поколения; пробуждение и укрепление интереса молодежи к всестороннему развитию, укреплению дружбы; повышение культурного уровня жителей Самарской области.

Название организации «Дуслык» переводится с татарского как «дружба». Это означает, что деятельность в рамках данной организации основана на общности интересов, взаимном уважении, взаимопомощи, доверительности, доброжелательности. А именно дружба объединяет членов организации, способствует сплочению, укреплению их единства и помогает использовать и направить имеющийся потенциал на возрождение и развитие национальной культуры, языка и традиций.

Общественная организация «Дуслык» («Дружба») ведет свою деятельность в следующих направлениях:

– ***литературное направление:*** пробуждение интереса к татарскому искусству через ознакомление с творчеством известных татарских писателей и поэтов, донесение до молодежи социальной значимости их произведений, привитие уважения и почитания к великим татарским поэтам и писателям.

Так, в мае 2011 г. в Доме дружбы народов Самарской области был проведен «Вечер поэзии», посвященный 125-летию Габдуллы Тукая, на котором зрителей познакомили с биографией и творчеством великого татарского поэта, прозвучал блок стихов о любви, родине, Великой Отечественной войне, а также была проведена интересная викторина.

По инициативе СРТОО «Дуслык» («Дружба») и СОТНКА, ежегодно проводится конкурс «В мире поэзии» («Шигърият дөньясында»), который в 2021 г. стал межрегиональным. В 2021 г. конкурс прошёл под девизом: «Сохраняем культурное наследие татарского народа».

– ***спортивное (физкультурно-оздоровительное):*** проведение спортивных мероприятий с целью поддержания физического здоровья, улучшения работоспособности и пропаганды здорового образа жизни. Движение – это жизнь, поэтому организация стремится донести до молодежи важность занятий спортом, помогать повышению двигательной активности.

Для реализации данного направления в мае 2011 г. был организован выезд на базу отдыха «Полет», где прошли соревнования по волейболу. Также еженедельно все желающие собираются в спортзале татарской школы «Яктылык» для игры в волейбол.

Стало традицией проведение зимне-весенних спортивных праздников – состязаний на лыжах с участием людей всех возрастных категорий, сопровождаемых национальными играми, песнями, хороводами и т. д.

С 2019 г. в Самаре по инициативе СРТОО «Дуслык» («Дружба») и городской школы «Яктылык» проводится уникальный, яркий национальный праздник – «День здоровья». В них активное участие принимают наш земляк, чемпион мира по биатлону Эдуард Латыпов, герой России И.В. Станкевич и другие знаменитости.

За эти годы школьное спортивное мероприятие смогло перерасти в городское мероприятие, в котором кроме учащихся с большим удовольствием принимают участие все желающие жители Самары – а это люди разных национальностей и возрастов, связанные узами дружбы, взаимоуважения и любви к родному городу. Сегодня «День здоровья» – это большой национальный праздник со спортивными состязаниями, культурной программой, угощениями татарской национальной кухни.

Пропаганда здорового образа жизни, особенно среди молодежи, вовлечение их в спортивные школы, секции – одно из привлекательных качеств Фахрутдина Канюкаева. Являясь 3-х кратным чемпионом мира по шашкам, он в областном центре создал шашечный клуб, где занимаются сотни ребят и взрослых, ежегодно проводятся шашечные турниры.

В 2018 г. был проведён Чемпионат Самарской области по шашкам имени Габдуллы Тукая. Ставший уже традиционным турнир по шашкам имени Габдуллы Тукая, проводимый в с. Мочалеевка, в 2018 г. получил новый статус и стал главным соревнованием проводимым федерацией шашек в Самарской области, прочно закрепив за Мочалеевкой звание столицы шашечного спорта нашего региона. У турнира, который носит

имя национального татарского поэта Габдуллы Туая, идейный вдохновитель – Канюкаев Фахрутдин Бадретдинович – президент СРТОО «Дуслык» («ДРУЖБА»).

### *Знание родного языка – ключ к познанию культуры своего народа*

Познание языка проходит через организацию воскресных школ. С разной степенью активности такие школы работали в городах Пушкино, Орехово-Зуево, Краснозаводск Сергиев-Посадского района, Дубна, Щелково и др. Ежегодно проводили Олимпиаду «Туган тел» и поощряли наиболее успешных учеников. Еще одной формой мотивации было ежегодное направление учащихся в летние лагеря отдыха в РТ: по линии Министерства образования и науки РТ, а также – Молодежного центра «Идель».

С течением времени эта форма начала угасать: нет учителей татарского языка, сложнее становится привлекать детей (занятость в других кружках и отсутствие настроя у родителей, так как они работают – зарабатывают на жизнь). Поэтому для дальнейшего развития выбрана форма создания семейных клубов «Дуслык». Реализуя эту задачу, выполнили 2 проекта на грант МК РТ, итогом которых являются изданные методические брошюры и видео-рекомендации по проведению занятия Семейного клуба.

Очевидно, что для проведения занятий необходимы учителя, которых пока что приходится изыскивать внутри своего города. Практика организации деятельности Семейных клубов началась в Дубне и имеет перспективу.

### *Поддержка молодежного движения*

Представители татарской молодежи Московской области с самого начала принимают участие в мероприятиях местных и областной организаций. Одним из проектов является проект «Татарская молодежь – детям». В его рамках в течение нескольких лет группа молодежи посещала с культурно-развлекательной программой детские дома Подмосковья. Одновременно, молодежь организует детский Сабантуй в рамках Программы областного Сабантуя. По плану РТНКА МО периодически организовывались молодежные форумы по разной тематике, в которых принимали участие ученые (профессора А. Бурганов и Б. Усманов), деятели культуры, общественные деятели. Логичным развитием форумов стал форум «Урман күле», который первый раз был проведен в 2017 г. в Дмитровском районе МО при грантовой поддержке Министерства культуры РТ. Следующие два форума прошли в парке «Пространство детской мечты» Домодедово (2018 г. и 2020 г.). Автором и организатором форумов является Р. Гумирова – председатель Комитета по делам молодежи РТНКА МО.

По инициативе наших активистов в 2019 и 2020 годах при поддержке ДУМ МО, ВКТ и ВФТМ были организованы и проведены летние палаточные фестивали под открытым небом «Йолдызлар яңгыры» (в Ногинском и Старо-посадском районах Московской обл.), на которых приняли участие и соотечественники из других регионов, артисты и спикеры из Татарстана.

Представители молодежи Московской обл. являются постоянными участниками лагерей отдыха и школы лидеров Молодежного центра «Идель», делегатами ВФТМ, организуемого Исполкомом ВКТ.



*Молодежный форум-2017, Дмитровский район Московской области*

### *Экскурсионные поездки в Татарстан*

Начиная с 2003 г. в течение ряда лет организовывали для активистов Автономии экскурсионные поездки в Татарстан. Прием и содержательную программу обеспечивал Исполком ВКТ. Такие экскурсии способствовали еще большему познанию истории и культуры татарского народа нашими соотечественниками и представителями других народов России.

Благодаря этой инициативе, в Татарстане побывали свыше 500 активистов и друзей другой национальности, проживающие в разных городах Московской обл.

### *Информационное взаимодействие*

С 2010 г. РТНКА МО имеет собственный сайт «mosobltatar.ru» и аккаунты в соцсетях. В 2015 и 2016 гг. совместно с Союзом журналистов Подмосковья было проведено два областных конкурса журналистских работ «Татары Подмосковья», в котором приняло участие более ста работ, из них работы 18 человек были удостоены наград. В 2021 г. сайт «mosobltatar.ru» был признан Победителем конкурса медиа-сайтов Подмосковья «ТОЧКА.RU» в номинации «Некоммерческие организации».

### *Деятельность местных организаций*

На местах работа общественных объединений зависит от инициативности и активности руководителей, их умения выстраивать человеческие отношения с людьми и наладить конструктивное взаимодействие с Ад-

министрацией города (района). Местные автономии сотрудничают и с религиозными общинами мусульман, поддерживая традиции и обычаи, благодаря которым наш народ смог сохраниться как нация. И здесь очень важно гармоничное взаимодействие сторон, способствующее дальнейшему развитию и сплочению татарского народа.

Местные организации в разной степени принимают участие в областных мероприятиях, организуемых Региональной Автономией (Сабантуй, фестиваль). Они также проводят определенную работу по своим планам.

Поскольку важной задачей национально-культурных объединений является и содействие формированию культуры межнационального общения, становится также актуальным инициирование создания в муниципальных образованиях Центров национальных культур. С учетом сказанного приведем примеры деятельности отдельных членов Региональной автономии.

В ***Пушкино*** в 2003 г. был открыт первый Центр (Дом дружбы), и одним из инициаторов создания и организации полнокровной деятельности была Х. Рамаева – председатель Местной татарской национально-культурной автономии Пушкинского района «Вазыфа». Сегодня этот Дом объединяет несколько национально-культурных объединений района и общественную организацию «Жители блокадного Ленинграда». Надо отметить, что в Пушкинском районе, начиная с 2004 г., проводился местный Сабантуй, который также пронизан духом дружбы народов. После определенного перерыва (после ухода из жизни Х. Рамаевой) проведение праздника возобновлено, и в этом активную роль выполняет руководитель религиозной общины мусульман Рамиль Фасхутдинов.

В ***Орехово-Зуево*** по инициативе руководителя МТНКА И. Измайлова построен Татарско-исламский культурный центр. Он открылся в 2011 г. В нем проводятся и интернациональные мероприятия, направленные на воспитание у молодежи чувств патриотизма и взаимоуважения независимо от национальности и конфессии. Одним из них является ежегодное мероприятие, посвященное Дню победы, куда приглашаются ветераны всего города и гости из других городов Подмосковья. Следует подчеркнуть, что именно в Орехово-Зуево было положено начало движению Московского областного Сабантуя. Последние три фестиваля «Музыкальное искусство татарского народа – культурное достояние России» состоялись также в Орехово-Зуево и оставили очень яркий след.

***Дубненскую автономию*** в 2013 г. возглавил И. Газизов. В этом же году в городе начал свою работу Центр национальных культур. Это стало возможным благодаря активному и настойчивому взаимодействию Дубненской ТНКА с Администрацией города. И нашлось хорошее решение:

Центр был оборудован на площадях городской библиотеки семейного чтения. В ремонте и оборудовании приняли материальное участие члены татарской автономии, спонсоры и Администрация. С тех пор ежегодное проведение Дней татарской культуры стало традицией. Также положено начало работе Семейного клуба, в рамках которого с детьми проводятся занятия по основам татарского языка, творческие мастер-классы, а также беседы для взрослых и детей по истокам татарского народа. Вокруг Центра сплачиваются и представители других национальностей и землячеств города. В декабре 2021 г. в Дубне при грантовой поддержке Главного управления социальных коммуникаций Московской обл. прошел Фестиваль национальных культур «Радуга цветов», посвященный 65-летию города и 30-летию создания татаро-башкирского культурного общества «Идель», который был преобразован в 2000 г. в Дубненскую татарскую национально-культурную автономию. Программа фестиваля, включающая в себя различные конкурсы и мастер-классы для детей, выставку национальной одежды и быта, а также содержательный концерт с участием татарских артистов, содействовал еще большему сближению соотечественников и сплочению представителей разных народов, проживающих в Дубне.

Очень важным вкладом татарского Общества в сохранение обычаев стало выделение по решению городской администрации участка земли для мусульманских захоронений (1998 г.). Вскладчину был поставлен забор вокруг территории. В настоящее время идет подготовка к установке ограждения уже вокруг дополнительной площади – за счет взносов людей и премии губернатора, выделенного за проект «Дни татарской культуры в Дубне».

***Люберецкий округ*** – это территория, где зародилась РТНКА Московской области. С 2015 г. местную автономию возглавляет Р. Хансверов. За прошедший период был организован ряд общественно значимых мероприятий. Среди них: Неделя татарской национальной культуры Люберецкого района и Сабантуй в пос. Малаховка (2016 г.), Первые татарские межнациональные люберецкие игры (2018 г.). Эти проекты удостоены премий Губернатора Московской области «Наше Подмосковье». В ноябре–декабре 2018 г. был проведен Месячник татарской национальной культуры городского округа Люберцы. 2020 г., как и у ряда других общественных организаций, по причине пандемии стал годом организации материальной помощи членам автономии, а также содействия ДУМ МО в раздаче продуктовых наборов нуждающимся.

Одним из достижений МТНКА ***Коломны*** является открытие музея татарской культуры и быта, созданного благодаря инициативе и усилиям

Д. Юсупова – члена Совета РТНКА МО, зам. председателя МТНКА Коломны. Автономия принимает активное участие в программах городских фестивалей национальных культур. Ярким мероприятием, проведенным по ее инициативе, является фестиваль «Джалилевские литературные чтения» по сценарию поэта и композитора С. Бакаева (2019 г.).

Очевидно, что в одной статье сложно отразить разностороннюю деятельность как региональной, так и местных организаций. Самое главное, что наши активисты искренне вносят свой вклад в благородное дело по сохранению традиций, культуры и духовности нашего народа. И они, несомненно, заслуживают благодарности от наших соотечественников и будущих поколений.

**Предложения по улучшению деятельности ВКТ, его Милли шуры и Исполкома.**

- *Разработка Положения об условиях приема татарских общественных объединений в состав ВКТ и вывода из него.*
- *Инициирование создания условий в Татарстане для возможности летнего отдыха (возможно, и зимнего отдыха во время каникул) татарских семей с детьми, проживающими в регионах, с познавательной программой по языку и культуре. Это позволит еще шире охватить татар с регионов и повысить эффективность деятельности по сохранению татарской нации.*
- *Введение рейтинга деятельности региональных национально-культурных объединений – членов ВКТ. Пяти лучшим по итогам года выделять премии для реализации уставных задач.*
- *Создание приложения «Татары» для смартфонов, который могут использовать соотечественники.*
- *Выделение субсидий на выпуск татарских СМИ.*
- *Оказание в необходимых случаях юридической поддержки татарам, попавшим в сложную жизненную ситуацию, через Центр правовой поддержки татар при ВКТ;*

**Варианты новых направлений (разновидности) деятельности татарских общественных объединений, которые нужно развивать.**

- *Поскольку мы живем не в замкнутом пространстве, а просветительская деятельность автономий нацелена и на укрепление межнациональных отношений, то важным направлением, требующим системного развития, является идея создания Центров Национальных культур в муниципальных образованиях региона, а также региональных Домов дружбы.*

- *Организация в рамках Общественной организации предпринимательской деятельности, а также активизация работы по взаимовыгодному сотрудничеству с предпринимателями для успешной реализации уставных задач, а также формирования фонда оплаты труда и фонда социальной взаимопомощи Общественной организации.*
- *Активная и последовательная работа по привлечению энергичных кадров в сферу национально-культурного движения. Для этого: периодически организовывать семинары, конференции, «круглые столы», тренинги и уроки для активистов по различным вопросам межнациональных и межконфессиональных отношений, миграционных вопросов, а также по вопросам организации деятельности Общественных организаций.*
- *Ведение рейтинга деятельности местных отделений Региональных национально-культурных объединений, троим из которых (лучшим по рейтингу) выделять премии по итогам года для использования в реализации уставных задач, в том числе для приобретения необходимых национальных костюмов и оргтехники.*
- *Периодическое проведение в регионах журналистского конкурса на татарскую тематику.*

**Заключение.**

Время идет. Жизнь подкидывает разные испытания. Ветераны общественной деятельности по состоянию здоровья уже не так активно могут принимать участие в организации мероприятий и очень важно подтягивать в эту благородную сферу более молодых соотечественников. Самое главное, следует всегда помнить, что только целенаправленные и постоянные действия дают ощутимый результат. В этой связи роль активной объединяющей деятельности ВКТ только возрастает.

В завершение приведем строки из стихотворения Г. Тукая «Мышь и молоко», в которых великий поэт, как бы предвидя будущее, образно заложил свой призыв к татарскому народу:

«О мой родной! Ты хоть в воде, хоть в молоке ты утопай,
Будь терпелив, настойчив, смел – отчаянью не уступай!»

## Чит илләрдәге татар оешмалары турында
## О зарубежных татарских организациях

*Л.Р. Кутеева*

### ТАТАР РУХЫНЫҢ КЫЙТГАЛАРДА ЧАГЫЛЫШЫ



Мәгълүм ки, татар халкының 70% өлеше Татарстаннан читтә яши, шуларның миллионнан артыгы чит илләрдә. Бүген Татарстан – РФдә ватандашлар белән күләмле һәм системалы эш алып баручы төбәкләрнең берсе. Республикада ватандашларга ярдәм итү эше, дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә куелып, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләрне ныгыту вәкаләте Татарстан Конституциясенең 14 маддәсенә һәм «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» программасына нигезләнеп алып барыла.

Республикада шулай ук ватандашларның мәнфәгатьләрен кайгыртучы тагын ике программа эшләп килә: «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» һәм «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» буенча. Шулай ук үзен татар дип танучы яисә татар халкына катнашы барлыгын тоючы кешеләрнең уртак ихтыяҗларына нигезләнеп, 2020 елның 29 августында Казанда узган «Милләт Җыены» вакытында «Татарлар: гамәл стратегиясе» кабул ителде. Аның төп максатлары: бай тарихи-мәдәни мирас белән кызыксынуны көчәйтү; туган телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклауга һәм үстерүгә өлеш кертү; татар халкын берләштерү һ.б.

Бүгенге көндә чит илләрдә гомер итүче татарларның Татарстан белән тыгыз элемтәләре корылды. Бу эшчәнлек Татарстан хакимиятләре белән дә, федераль даирәләр белән дә хезмәттәшлек нигезендә алып барыла. Һәм, әйтергә кирәк, Татарстанның уңышлы тәҗрибәсен федераль хакимиятләр дә хуплый. 2021 елның 15 октябрендә Мәскәүдә узган VII Бөтендөнья ватандашлар конгрессында Россия Федерациясенең тышкы эшләр

министры Сергей Лавров үз чыгышында күпмилләтле һәм күп конфессияле Россия алдында торган бурычларның берсе – милли төркемнәр арасында диалогны тирәнәйтү, дип билгеләп үтте. Мисал итеп ул Россиянең һәм чит илләрнең күп миллионлы татар җәмәгатьчелеге вәкилләрен берләштергән Бөтендөнья татар конгрессын атады. Әлеге конгресс утырышында, чит илләрдәге татар иҗтимагый берләшмәләреннән 17 вәкил катнашып, Перудагы «Татлам» (Латин Америкасы татарлары) иҗтимагый берләшмәсе җитәкчесе Алисә Гыйләҗева ватандашларның Бөтендөнья координацион берлегенә әгъза булып та сайланды.

Шулай ук 2021 елның 2 февралендә Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге, чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлык (Россотрудничество) җитәкчесе Е.А. Примаков, үзенең Татарстанга рәсми сәфәре кысаларында БТК Башкарма комитетына килеп, аның эшчәнлеге белән танышты һәм биредә ул чит илләрдәге татар иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре белән онлайн очрашуда катнашты. Очрашу барышында Евгений Примаков җитәкләгән агентствоның БТК белән ныклы хезмәттәшлек итүенә өмет белдерде һәм татар оешмаларына мөмкин булганча ярдәм күрсәтергә әзер булуын әйтте. Ассызыклап узасым килә, Азәрбайҗандагы һәм Беларусьтагы милләттәшләребез бу мөмкинлек белән ныклап файдаланалар, алар үзләренең күп чараларын Россотрудничество биналарында үткәреп киләләр.

Бүгенге көндә БТКның ватандашлар белән эшчәнлеге күпкырлы, ул тулы бер системага әверелде. Конгресс составына 45 илдән 147 берләшмә керә. Чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшчәнлекне Башкарма комитет структурасында 2002 елда оешкан Чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү комитеты алып бара. Комитетның төп бурычлары:

– чит илләрдә гомер итүче милләттәшләребезне берләштерү, аларның милли-мәдәни, социаль-икътисади һәм рухи үсешенә ярдәм итү;
– Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының чит илләрдәге татар оешмалары белән бәйләнешен булдыру;
– чит илләрдәге татар оешмаларының һәм милли-мәдәни үзәкләрнең эшчәнлеген координацияләү;
– БТК Башкарма комитетының чит ил вәкилләре катнашында уза торган чараларын әзерләү;
– чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмаларына чараларын үткәрүдә һәм проектларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү һ.б.

Милли үзенчәлегебезне саклау, үз составларында фәнни интеллигенция, мәдәният, мәгариф, бизнес вәкилләре булган татар җәмгыятьләренең

потенциалын куллану һәм үстерү максатыннан, БТК Башкарма комитеты, үз эшчәнлегендә чит илләрдә яшәүче татар халкының төрле категорияләре белән төрле формаларны кулланып, күпкырлы эш алып бара.

Чит илләрдәге милләттәшләребез тормышына Татарстан җитәкчелеге тарафыннан да игътибар зур. Татарстан Президенты кайсы гына илгә бармасын, анда яшәүче ватандашлар белән очрашмыйча калмый. Соңгы елларда гына да мондый очрашулар күтәренке рухта Финляндиянең Хельсинки, Швейцариянең Женева, Италиянең Милан, Австриянең Вена,

Бөекбританиянең Лондон, Согуд Гарәбстанының Җиддә, Төркиянең Әнкара һәм Истанбул, Таҗикстанның Дүшәнбе, Төркмәнстанның Ашхабад, Беларусьнең Минск, Кыргызстанның Бишкек, Үзбәкстанның Ташкент һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә узды. Әйтергә кирәк, мондый очрашуларны, Президентның җылы мөнәсәбәтен милләттәшләребез зур канәгатьлек белән, дулкынланып кабул итәләр. Аларның нәтиҗәсе буларак, бу илләрдә яшәгән татарлар үзләренә булган игътибарны тоеп кына калмыйлар, ә үз мөрәҗәгатьләре нигезендә эшләнгән хөкүмәт күрсәтмәләре белән турыдантуры ярдәм дә күрәләр. Моның мисаллары да күп, әйтик: Әнкарада Габдулла Тукайга һәйкәл ачу, бу шәһәрдә урнашкан Татар йортын татар халкының мәдәнияте, тарихы, көнкүрешенә бәйле экспонатлар белән тулыландыру; Истанбулда Татар йортын ачу; Җаек шәһәрендә Тукайга һәйкәл һәм аның мемориаль комплексын булдыру, хәзер исә биредә татар бистәсен һәм Тукай белән бәйле тарихи урыннарны төзекләндерү буенча эш алып барыла; Киев шәһәрендә Татар мәдәни үзәген булдыру; Ташкентта татар оешмасы урнашкан кабинетка ремонт ясау һәм җиһазлар алу; Бишкектагы «Асыл бала» мәгариф үзәгендәге классны Татарстан Республикасының «Зарница» җитештерү берләшмәсе җиһазлары белән тулыландыру, әлеге үзәк урнашкан бинаны татар оешмасына арендага алуда ярдәм күрсәтү; Россиянең Беларусьтагы илчелегендә Кол Шәриф мәчете төшерелгән мозаикалы картина урнаштыру; Минск шәһәренең «Чишмә» татар-башкорт мәдәни үзәгенә тирмә бүләк итү; Бохараның «Мир-Араб» мәдрәсәсендә мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанигә мемориаль такта кую, Беларусь Республикасы Витебск өлкәсенең Фәрит Яруллин исемен йөрткән Дубровно балалар сәнгать мәктәбе территориясендә Бөек Ватан сугышы вакытында биредә һәлак булган мәшһүр композиторыбызга бюст урнашатыру, һ.б.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президентының аерым күрсәтмәләре нигезендә Минскида мәчет салуда матди ярдәм; Польшада Татар утарын торгызуда матди ярдәм; Казакъстан Республикасының Семей шәһәрендәге Татар сәнгать мәктәбенә бина сатып алу; Азәрбайҗанның

Баку, Казакъстанның Семей, Кыргызстанның Бишкек шәһәрләрендәге татар оешмаларына микроавтобуслар бүләк итү; Австралиядәге татарлар мөрәҗәгате буенча Аделаидага Татарстаннан имам җибәрү; Төркиядә яшәгән күренекле татар галиме Надир Дәүләтнең фәнни хезмәтен Татарстанда нәшер итү; Кытайның Синьцзянь-Уйгыр автоном районыннан килгән милләттәшләребезне Казандагы югары уку йортларында укыту проекты, Татарстан Республикасы ярдәме белән Австралия, Бельгия, Алмания, Италия, Австрия, Беларусь, Литва, Эстония, Таҗикстан, Швейцария, АКШ, Төркия, Азәрбайҗан, Казакъстан, Канада, Кыргызстан, Финляндиядәге татар иҗтимагый оешмалары өчен татар милли костюмнарын тегү һ.б.



*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Согуд Гәрәбстаны татарлары белән очрашуы*

Бүгенге көндә исә Беларусьта Бөек Ватан сугышында катнашучы, капитан Әдһәм Кәримовның каберен төзекләндерү; Бишкек шәһәрендә урнашкан, биология, физиология өлкәләрендә дөньякүләм танылган галим, биология фәннәре докторы, профессор, академик Әнвәр Гәрәев исемен йөрткән Урта Азиянең иң зур ботаник бакчасында (гомум территориясе – 160 гектарга якын) милләттәшебезгә мемориаль стела урнаштыру; Үзбәкстан, Финляндия, Беларусь татарлары энциклопедияләрен язу; Согуд Гарәбстанындагы милләттәшләрнең Татарстан белән эшлекле хезмәттәшлекләрен булдыру һәм башкалар буенча күләмле эшләр алып барыла.

Югарыда саналганнардан күренгәнчә, ватандашлар мәнфәгатьләрен кайгырту йөзеннән конкрет эшләр башкарыла.

БТК уставы нигезендә аның төп максатлары – татар халкын берләштерү; Татарстан Республикасының милли-мәдәни, социаль-икътисади һәм рухи үсешенә ярдәм итү; татар халкы яшәгән җирлекләрдә милли-мәдәни мәнфәгатьләрен кайгыртуга юнәлгән проектларны тормышка ашыру һ.б. Шул максаттан БТК Башкарма комитеты тарафыннан һәрдаим төрле форматта чаралар уздырылып килә, шулар арасында чит илләрдән вәкилләр катнашында уза торган иң масштаблылары: БТК сьезды, Бөтендөнья татар яшьләре, «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре», татар дин әһелләре, татар галимнәре, татар хатын-кызлары форумнары, Изге Болгар җыены, «Татарча диктант» акцияләре, төрле темаларга фәнни-гамәли конференцияләр һ.б. Мондый масштаблы мәйданчыклар белән безнең илдә башка бер генә милләт тә мактана алмый.

**Бөтендөнья татар конгрессының съезды**

Бөтендөнья татар конгрессының беренче съезды 1992 елда була. Бу тарихи вакыйгадан соң инде 30 ел вакыт узган. Съезд 5 елга бер тапкыр уздырыла. Әлеге зур чарада халкыбызның киләчәккә үсеш юлларын билгеләү, милләт язмышы хәл ителүгә кагылышлы мөһим сорауларны хәл итү кебек җитди мәсьәләләр күтәрелә. «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлеге эш планы нигезендә, 2022 елның 30 июль – 3 август көннәрендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды уздырылачак. Съезд эшендә 1000 артык татар милләте вәкилләре, шул исәптән чит илләрдә яшәүче 250гә якын милләттәшебез катнашыр, дип көтелә. Съезд программасы нигезендә, пленар утырыш һәм секцияләр уздыру белән беррәттән, төрле мәдәни-мәгълүмати һәм экскурсион чаралар үткәрү дә күздә тотыла.

**Бөтендөнья татар яшьләре форумы**

Бөтендөнья татар яшьләре форумнары – яшьләр хәрәкәтенең иң масштаблы проектларының берсе, дисәк тә хата булмас. Оешманың уставы нигезендә яшьләр форумнары ике елга бер уздырыла. Аларның төп максаты: яшь буын вәкилләренең халкыбызның милли үзенчәлеген, тел, тарих, мәдәният кебек милли кыйммәтләрен саклау өлкәсендәге эшчәнлеген активлаштыру. Әлеге форумнардан соң гадәттә чит илләрдә татар яшьләре хәрәкәте көчәю күзәтелә, яңа яшьләр төркемнәре барлыкка килә. Мисалга Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Алманиядә барлыкка килгән яшьләр оешмаларын китереп була.

Узган форумнарга киң иҗтимагый кызыксыну тудырып, яшьләрне милли һәм кешелек кыйммәтләре тирәсенә берләштерү хас иде. Бөтендөнья татар яшьләренең читраттагы форумын 2022 елның август ахырында уздыру планлаштырыла.

Яшь ватандашлар белән эшләүдәге тагын бер мөһим проектлар – берсе – татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларына кабул итү программасы. БТК Башкарма комитеты, ТР Президенты йөкләмәсе нигезендә, 2005 елдан башлап чит илләрдәге милләттәшләребезне Татарстандагы югары уку йортларына укырга кертүдә ярдәм күрсәтеп килде. Соңгы унбиш ел эчендә генә чит илләрдән барлыгы 3500 артык студент Татарстанда урнашкан уку йортларына кабул ителде. Бүгенге көндә әлеге эшчәнлек Россиянең чит илләрдәге илчелекләре һәм Россотрудничество вәкиллекләре, шулай ук Татарстан Республикасындагы югары уку йортларының чит илләрдә оештырган күчмә кабул итү комиссияләре аша алып барыла.

**«Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы**

Дөнья буенча сибелеп яшәүче татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калуда эшлекле милләттәшләрнең өлеше зур. Татарстаннан читтәге милли җәмгыятьләр, мәдәни үзәкләрнең ни дәрәҗәдә колач җәюе еш кына эшмәкәрләр күрсәткән игътибарга бәйле. Социаль-икътисади үсеш ягыннан Россиянең алдынгы төбәкләреннән саналган Татарстан белән соңгы елларда ныгып, аякка баскан татар эшмәкәрләренең көч-куәтен, татар милли тормышын җанландыру өчен берләштерү максатыннан, БТК Башкарма комитеты тарафыннан «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумнары уздырыла. Чара кысаларында узган очрашулар һәм сөйләшүләр вакытында татар эшмәкәрләре арасында эшлекле мөнәсәбәтләр булдыру өчен элемтәләр тудырыла.

Уңай мисал итеп, татар эшмәкәрләре ярдәме белән Казакъстанның Усть-Каменогорск шәһәрендә Муса Җәлилгә, Семей шәһәрендә Габдулла Тукайга һәйкәл ачуларны китереп була. Гомумән, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстандагы милли оешмаларыбыз үзләренең проектларын тормышка ашырганда татар меценатларының ярдәмен даими рәвештә тоеп торалар.

**Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы**

Чит илләрдә татар тарихын һәм мәдәни традицияләрне популярлаштыру өлкәсендә мөһим урынны милли кием һәм милли ашларыбызның презентацияләрен ясау алып тора. БТК Башкарма комитеты һәм «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы тарафыннан уздырыла торган форумның төп максаты – татар хатын-кыз оешмаларын торгызу, яңа оешмалар ачу һәм гаиләдә телне, гореф-гадәтләрне саклауда хатын-кызның ролен күрсәтү. Оешманың ике елга бер була торган форумы уздырылып килә, съездга килгәндә, I Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары съезды 1917 елның 24 апрелендә узган һәм бер гасырдан соң 2019 елның 19 апрелендә Бөтендөнья татар конгрессы II Бөтендөнья татар ха-

тын-кызлары съездын җыйды. Аның эшендә 500дән артык делегат катнашты, шулар арасында 17 чит илдән 63 милләттәшебез дә бар иде.

Чит илләрдә эшләп килүче оешмалар арасыннан, мисал итеп, Швеция, Азәрбайҗан, Казакъстан һәм Алманиядәге татар хатын-кызлар берләшмәләрен китереп була. Европада яшәүче татар хатын-кызларының «Ханым» берлегенең төп проектларын гына санап китик: һәр елны милли тематикалы татар календаре чыгару, татар киеме көне флэшмобы, дөньяның төрле почмаклары турында татар телендә «Шәһәремә, авылыма рәхим итегез!» проекты, татар чигүе сәнгате, җыр-бию, татар ашлары буенча мастер-класслар, Татарстан, Башкортостан, Себердәге кечкенә татар авыллары китапханәләренә татарча газета, журналлар яздыру һ.б.

**Татар галимнәре белән бәйләнеш**

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты шулай ук чит илләрдә яшәүче галимнәр белән дә тыгыз элемтәләр булдырды. Бүгенге көндә якын һәм ерак чит илләрдә фәнни өлкәдә 150гә якын милләттәшебез хезмәт итә. Алар арасында дөньякүләм танылган галимнәр: Рәшит Сюняев, Роальд Сәгъдиев, Айша Рорлих, Гөнүл Пултар, Тасин Җәмил, Юлай Шамилуглы һәм башка бик күпләрнең исемнәрен атарга була. Аларның күпчелеге техник һәм фундаменталь фәннәр өлкәсендә эшлиләр. Аерым ассызыклап узасы килә – Рәшит Сюняев һәм Юлай Шамилуглы БТК Милли Шура әгъзалары да булып торалар.

**Этник туризм**

Бүген Татарстанны тарихи ватаныбыз, Казанны рухи мәркәзебез дип атау гына җитми, Татарстан белән кызыксынган милләттәшләребезне бирегә китерү – мөһим бурычларның берсе. 2004 елдан башлап милләттәшләребез БТКның этник туризм программасында катнашалар. Әлеге программа буенча Австралия, Беларусь, Бельгия, Германия, Нидерланды, Польша, Казакъстан, Кыргызстан, Кытай, Литва, Украина, Төркия, Үзбәкстан, Финляндия, Эстония кебек илләрдә яшәүче гомум саны 1000 артык милләттәшләребезнең беренче тапкыр Казанга экскурсияләре оештырылды. Гадәттә, алар өчен бик эчтәлекле һәм тулы программа төзелә: Казанның истәлекле урыннарына экскурсия, Болгарга, Тукай-Кырлайга сәяхәт, Татарстан авылларына бару, музейлар белән танышу, татар интеллигенциясе вәкилләре белән очрашулар, Сабантуй бәйрәмендә катнашу һ.б.

**Халкыбызның милли бәйрәме – Сабантуй**

Татарларның мәдәни мирасы һәм яңарышы символларының берсе – Сабантуй. Татарстан Республикасы бу чарага зур әһәмият бирә. Без аңа гади бер күңел ачу чарасы гына итеп карамыйбыз, аны туган телне,

милли мәдәниятне, гореф-гадәтләребезне саклау механизмы рәвешендә файдаланабыз. Зур масштабларда уза торган мондый бәйрәм, һичшиксез, анда катнашкан халыкларның үзара аңлашуына хезмәт итә, милләттәшләребезнең абруен күтәрә. Юкка гына аны халыкара этномәдәни хәрәкәт дип бәяләмиләр. Моның әһәмиятен урындагы хакимиятләр дә яхшы аңлый, күп җирләрдә Сабантуй чарасы илләрдә, төбәкләрдә уза торган бәйрәмнәрнең рәсми исемлегенә кертелә.

Соңгы елларда Сабантуйны әзерләү һәм үткәрүнең тотрыклы, үз-үзен аклаган формалары барлыкка килде. 2003 елдан башлап БТК Башкарма комитеты ТР Мәдәният министрлыгы белән берлектә Сабантуй бәйрәмен оештыручылар һәм аның режиссерлары өчен махсус курслар үткәрә. 2020–2021 елларда ул онлайн форматта узды.

Сабантуйларны үткәрүдә Татарстан Республикасы Хөкүмәте зур ярдәм күрсәтә. Әлеге ярдәм, нигездә, сәнгать осталары, спортчылар һәм иҗат коллективларының чит илләрдәге Сабантуйларга баруын оештыруга бәйле. Чарада республикабыз делегациясенең катнашуы, бу бәйрәмнең әһәмиятен арттыра. Татарстаннан читтә уздырылган Сабантуйларда катнашучыларга ТР Президенты сәламләвен җиткерү шулай ук яхшы традициягә әверелде. Мондый мөрәҗәгатьләр милләттәшләребезне илһамландыра, тарихи ватаннары белән бәйләнешләрен ныгыта. Сабантуйлар үткәрү географиясе елдан-ел арта бара, моннан 10 ел элек милли бәйрәмебез Сабантуй дөньяның 22 иленең 64 шәһәрендә уздырылган булса, быелгы графикка инде 33 чит илдә узачак 92 Сабантуй керде.

Сабантуй үткәрүдә Федераль, Бөтенроссия күләмендәгеләр белән берләттән, халыкара форматта уздыру да практикага керде. Мәсәлән, 2014 елдан башлап, Европадагы татар иҗтимагый оешмалары тырышлыгы белән, «Европа Сабан туе» уздырылып килә. Ул 2014 елда – Ригада, 2015 – Берлинда, 2017 – Вильнюста, 2019 – Таллинда узган булса, киләсе V Гомумевропа Сабан туен Болгария башкаласы Софиядә үткәрү планлаштырыла. Гадәттә, Европа Сабан туен үткәрүдә ярдәм күрсәтү өчен Татарстаннан Әлмәт муниципаль районы җаваплы итеп билгеләнә. Россиянең аерым төбәкләренә һәм кайбер чит илләргә Татарстан районнары һәм шәһәрләре делегацияләрен беркетү тәҗрибәсе үзен тулысынча аклады. Мондый эш төре республика һәм татарлар яшәгән җирлекләр арасында элемтәләр урнаштыра һәм мәдәни, эшлекле бәйләнешләрне ныгыта. Татарстан районнары делегацияләре җирле Сабантуйларга милли колорит өсти.

Шунысы үзенчәлекле, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан кебек илләрдә Сабантуй илнең башкаласында гына түгел, ә дистәләгән шәһәрләрендә уза. Мәсәлән, быел бәйрәмне Казакъстанның 20 шәһәрендә үткәрү планлаштырыла. Бу илдә һәр елны чиратлап кайсы да булса өлкә

үзәгендә Гомумреспублика Сабан туе оештырылып килә. Быел исә ул Көнчыгыш Казакъстан өлкәсенең Семей (Җидепулат) шәһәрендә «Иртыш буе Сабан туе» исеме астында узар дип көтелә. I Халыкара Иртыш буе Сабан туе урыны итеп юкка гына Семей шәһәре сайланмады, чөнки быел биредә урнашкан бик күп профессиональ сәнгать әһелләрен тәрбияләп, дөньяга таныткан Татар сәнгать мәктәбе 30 еллыгын бәйрәм итәчәк. 1718 елда Җидепулат шәһәренә нигез салучылар арасында татарлар аерым урын алып торганнар. Элек-электән шәһәрдәге Татар бистәсе иң нык тормышлылардан саналган, ә татарлар арасында бик күп сәүдәгәрләр һәм сәнәгатьчеләр булган. Биредәге татарлар бүгенге көнгә кадәр татар рухын саклап, үстереп яшиләр, конкурс-фестивальләр үткәрәләр, монда Татар сәнгать мәктәбе эшләп килә, мәчетләре бар һ.б.

**Казакъстан җирлегендәге татарлар хәрәкәте**

Гомумән, Казакъстандагы татарлар милләтебезнең рухи кыйммәтләрен саклау өлкәсендә бик күләмле эшләр башкаралар. 2017 елда оешып, Казакъстандагы барлык татар иҗтимагый оешмаларын үз эченә туплаган «Казакъстан татарлары һәм башкортлары конгрессы» Республика иҗтимагый берләшмәсе (җитәкчесе – Кәримов Тәүфыйк Әкрам улы) бүгенге көнгә кадәр уставында каралган максатларына тугры калып килә. Республиканың төрле шәһәрләрендә мәдәни, фәнни, мәгърифәти проектлар тормышка ашырыла: төрле темаларга конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр», спорт-күңел ачу чаралары, музыкаль конкурс-фестивальләр, якшәмбе мәктәпләре эшчәнлеге, татар халкының тарихына, мәдәниятенә багышланган китаплар бастыру һ.б. Казакъ җирлегендә Габдулла Тукай, Латиф Хәмиди, Ибраһим Сәлахов, Нәҗиб Җиһановлар яшәгәннәр, эшләгәннәр һәм милләттәшләребез аларның исемнәрен мәңгеләштерү буенча да зур эшләр башкаралар. Җаекта Габдулла Тукай үзәге, музее эшләп килә. Казакъстанның шәһәрләрендә халкыбызның бөек шәхесләре: Сөембикә, Муса Җәлил, Ибраһим Сәлахов, Гайнан Кормашев, Вәли Хәлфин, Фәрит Фәткульдин һ.б. исемендәге урамнар булуы да – биредәге милләттәшләребез тырышлыгы нәтиҗәсе.

Узган елны БТК һәм Бөтендөнья казакълар Ассамблеясы арасында килешү төзү дә, татар һәм казакъ халыклары арасында гасырлар дәвамында барлыкка килгән рухи һәм мәдәни элемтәләрне тагын да ныгытуга бер адым булды.

Татарлар күпләп яшәгән җирлекләрдә милли музыка фестивальләрен үткәрү яхшы традициягә әйләнде. Аларның кайберләре инде дистә еллар буе яшәп килә. Казакъстан Республикасының Семей шәһәрендә «Иртыш моңнары» фестивале, Габделхак Ахунҗанов тырышлыгы белән, 23 ел элек үткәрелә башлады һәм бүген дә ул милләттәшләребез тарафыннан яратып кабул ителә. Шулай ук биредә Латиф Хәмиди исемендәге халык-

ара конкурс уза. Мондый фестивальләрнең исемнәрен атау гына да мәдәни хәрәкәтнең масштабларын күрсәтә. Әлеге чаралар татар дөньясының гаять бай, тирән, үзенчәлекле мирасын халкыбызга кайтару, саклап калу һәм киләчәк буыннарга тапшыру юнәлешендәге фидакяр хезмәтнең бер чагылышы булып тора.

**Чит илләрдәге татар мәдәнияте һәм сәнгате**

Татарстан һәм татар мәдәнияте дөнья илләрендә һәрвакыт зур кызыксыну уятып килде. Шул уңайдан чит илләрдә татар мәдәнияте көннәрен үткәрү дә матур гадәткә әйләнеп китте. Соңгы елларда мондый чаралар Кыргызстанның Бишкек, Казакъстанның Нур-Солтан, Үзбәкстанның Ташкент, Румыниянең Констанца, Литваның Вильнюс һәм Висагинас, Италиянең Рим, Венгриянең Будапешт, Эстониянең Кохтла-Ярве, Франциянең Париж, Чехиянең Брно, Польшаның Гданьск һәм Белосток шәһәрләрендә уздырылып килде. Һичшиксез, Татарстанның иҗат коллективлары катнашында узган мондый чаралар дөнья җәмәгатьчелегендә Татарстан турында уңай имидж тудыра алалар. Шуның белән Татарстанның абруе да халкыбыз алдында гына түгел, башка милләтләр арасында да нык үсә.

Шулай ук Торонто, Клайпеда, Висагинас, Минск кебек шәһәрләрдә уза торган «Дөнья тирмәсе», «Туган җир», «Rudenines», Дубровнодагы музыкаль фестиваль кебек дөнья халыкларының этнофестивальләрендә татар иҗтимагый берләшмәләренең катнашуы да чит илләрдә киң резонанс тудыра. БТК Башкарма комитеты әлеге чараларда катнашу өчен югарыда әйтелгән оешмаларга татар халкының мәдәнияте һәм тарихы буенча кирәкле күрсәтмә материаллар һәм Татарстан Республикасыннан артистлар җибәрү белән ярдәм итә. Мондый чаралар татар мәдәниятенә карата кызыксыну уята, урыннарда милли-мәдәни тормышның активлашуына булышлык итә. Кагыйдә буларак, шушы иҗади тәҗрибә уртаклашулардан соң яңа ансамбльләр, фольклор төркемнәре дә оеша башлый.

Г. Тукай, М. Җәлил, Н. Җиһанов, С. Садыйкова, С. Сәйдәшев кебек бөек шәхесләребезнең юбилейларын зурлап бәйрәм итү дә татар дөньясына көчле импульс бирә. Бу олуг даталар чын мәгънәсендә халыкара яңгыраш алды. Әлеге даталарга бәйле ел дәвамында татар иҗтимагый оешмалары тарафыннан бик күп чаралар үткәрелеп килә.

Республикадан читтә яшәүче татар рәссамнары иҗаты белән таныштыру максатыннан, БТК Башкарма комитеты татар рәссамнары һәм сынчыларының күргәзмәләрен оештыру өлкәсендә дә зур эшләр башкарып килә. Казанда төрле елларда тамашачы игътибарына Казакъстаннан рәссам-импрессионист, педагог, Казакъстан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Бәхтияр Табиевның; Казакъстанның атказанган эшлеклесе, Татарстанның халык рәссамы, Казакъстанның Дәүләт премиясе һәм Та-

тарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Муллашевның; Казанда туып, бүгенге көндә Юрмалада иҗат итүче Виталий Ермолаевның уникаль техникалы «балкый торган картиналары»; Франциядә иҗат итүче милләттәшебез Ринат Анимаевның «Париж язы» диелгән күргәзмәләре тәкъдим ителгән иде. Мондый күргәзмәләр чит илләрдә дә зур уңыш белән үтә.

Мәсәлән, 2017 елда Бельгиянең Брюссель, ә 2019 елда Дендерлоу шәһәрләрендә «Бельгиядә татарлар» берлеге тарафыннан милләттәшебез рәссам Гүзәл Амальрик (Макутдинова) күргәзмәсе оештырылган иде. Гүзәл Амальрик 1942 елны Түбән Новгород өлкәсендә туып, узган гасырның 70–80 елларында Франциядә киң танылу ала, картиналары белән Америка, Франция, Нидерланд һәм башка Европа шәһәрләрендә узган күргәзмәләрдә уңышлы катнашып килә. Рәссам үлеме алдыннан үзенең әсәрләрен милләттәшләребезгә васыять итеп калдыра һәм бүгенге көндә Бельгиядәге татарларда Гүзәл Амальрикның 150 картинасы саклана.

Быел исә Төркмәнстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам Камил Вәлиәхмәдовның картиналар күргәзмәсен Казанда уздыру буенча оештыру эшләре алып барыла. Зур тырышлык куеп берсеннән-берсе үзгә картиналар тудыручы милләттәшләребезнең бу күргәзмәләре, тамашачыларның күңелен яулап, һичшиксез, татар сәнгатендә үзләренең лаеклы урыннарын табачак.

Татар иҗтимагый оешмалары тарафыннан Азәрбайҗан, Беларусь, Бельгия, Казакъстан, Кыргызстан, Латвия, Үзбәкстан, Украина, Таҗикстан, Эстония кебек илләрдә, гадәт буенча, 28 февральдә, татар кулинары Юныс Әхмәтҗановның туган көненә багышлап, Татар халык ашлары көннәре уздырыла. Дүшәнбе, Бишкек, Джәлалабад, Минск, Ташкент, Баку, Брюссель, София, Вена, Нур-Солтан, Актүбә һ.б. шәһәрләрдә бу дата өчпочмак пешерү буенча мастер-класслар үткәрү белән үзенчәлекле. Әлеге чара вакытында олы буын вәкилләре яшьләргә татар халкының брендына әйләнгән милли ризыгыбыз – өчпочмак пешерү серләрен өйрәтәләр. Шул рәвешле буыннар бәйләнеше барлыкка килә. Ә 4 октябрьдә бик күп илләрдә «Чак-чак party» акциясе үткәрелә, аның идеясе исә III Бөтендөнья татар яшьләре форумы вакытында яңгыраган иде.

Литвада яшәүче татарлар исә үзләренең милли ризыкларын патентлап, Литваның матди булмаган мәдәни мирас исемлегенә дә кертә алдылар һәм бүгенге көндә Европа проектлары аша аларны дөньяга таныту өстендә эшлиләр.

### Күңелләрдән җуелмас Җиңү көне

Һәр елны май аенда Азәрбайҗан, Беларусь, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстан кебек илләрдә татар оешмалары тарафыннан су-

гыш һәм тыл ветераннарына карата күләмле эшләр башкарыла. Инде олы яшьтәге ветераннарыбыз Татарстан Президентының котлауларын һәм татар оешмалары тарафыннан тупланган бүләкләрне зур канәгатьлек, күз яшьләре белән кабул итәләр. Беларусь, Латвия, Венгрия, Алманиядә даими рәвештә I һәм II Бөтендөнья сугышы вакытларында һәлак булган солдатларның мөселман каберлекләрен тәртипкә китерү эшләре башкарыла. Гомумән, бу илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары Бөек Ватан сугышында һәлак булып, ул илләрдә күмелгән татарстанлыларның исемнәрен барлау өлкәсендә дә зур эшләр башкаралар.

Алманиянең «Татарлар Дойчланд» мәдәниара интеграцион үзәге рәистәше Венера Вәгыйзованың Казанга җәлилчеләрнең «Демблин» хәрби лагеренда язылган 4 җырының аудиоязмаларын алып кайтып халыкка чыгаруы да зур вакыйга булды.

Бүгенге көндә Казакъстанның Актүбә шәһәренең Г.Кормашев исемен йөрткән урамында биредә мәктәп директоры булып эшләгән җәлилче Гайнан Кормашка Актүбә өлкәсенең «Шатлык» татар һәм башкорт этномәдәни берләшмәсе тарафыннан элмә такта кую буенча эш алып барыла.

Ветераннарга дан-хөрмәт йөзеннән башкарылган эшләр турында сөйләгәндә Ташкент шәһәре татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге әгъзаларының эшчәнлеген үрнәк итеп, мисалга китереп була. Чөнки алар 15 ел рәттән 9 май көнне инде традициягә әйләнгән «Һәр ветеранга барып җитәргә!» дигән күләмле хәйрия акциясе уздырып киләләр. Актив милләттәшләребез бәйрәм алдыннан шәһәрдә яшәүче ветераннар исемлекләрен яңартып, һәр район өчен җаваплы төркемнәр оештыралар һәм рәсми котлау хатлары белән бергә үзләрендә туплаган күчтәнәчләрне ветераннарыбызның өйләренә барып тапшырып, бәйрәм белән котлыйлар. Җиңү бәйрәме уңаеннан ветераннарга карата оештырылган миһербанлык татар җәмәгатьчелегендә зур күтәренкелек тудыра, чөнки Бөек Ватан сугышы елларында татарлар башка халыклар белән бергә ил сагына басканнар. Үзбәкстан татарлары арасыннан гына да 23 Советлар Союзы каһарманы һәм 4 Дан ордены кавалерлары чыккан, шулай ук меңләгән фронтовик-татарлар һәм тыл хезмәткәрләре орден һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр.

**Үзбәкстандагы татарлар**

Бүгенге көндә Үзбәкстан Республикасында 35 миллионнан артык кеше яши, шуларның 1% тирәсен – 350 меңгә якынын татарлар тәшкил итә. Биредә Ташкент, Янгиюль, Джизак, Бохара, Нәваи, Карши, Фирганә, Сәмәрканд шәһәрләрендә бик актив татар милли-мәдәни үзәкләре эшләп килә. Үзбәкстанда гомер итүче татарлар тарихи ватаннан еракта диннәрен, туган телләрен, мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен саклап яшиләр. Борынгы традицияләр хәзер дә дәвам итә, матур бәйрәмнәр үткәрелә, ха-

лык ансамбльләре иҗат итә. Әлеге саналган эшләрнең башында агымдагы елның 8 апрелендә дәүләт дәрәҗәсендә Үзбәкстанның иң мәртәбәле концертлар залы – 1000 кешелек «Төркестан» сәнгать сараенда, үзенең 30-еллык юбилеен бәйрәм иткән Ташкент шәһәре татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге (җитәкчесе – Нәбиуллин Ришат Хисмәтулла улы) тора.

2022 елның сентябрь аенда Ташкент шәһәрендә «Татар кызы» халыкара бәйгесен уздыру да планлаштырыла. Аның максаты – яшьләрнең халкыбызның бай мәдәни мирасына кызыксыну уяту аша милли гореф-гадәтләребезне һәм йолаларыбызны саклау, катнашучыларның тормыш тәҗрибәсен яңа белем һәм осталыклар белән баету, илләр һәм регионнар арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру. Бәйге кагыйдәләре буенча, «Татар кызы»ның финалы узган елгы җиңүченең туган ягында узарга тиеш. 2019 елда җиңүне Үзбәкстаннан Лилия Камилова яулады, ләкин дөньядагы санитар-эпидемиологик вазгыять аркасында чара уздырылмыйча калган иде. Үзбәк җирендә быел мондый чара уздыру Татарстан белән Үзбәкстан арасындагы дуслыкны тагын да көчәйтер, дигән өметтә калабыз.

**Аурупа татарлары Альянсы**

Милләттәшләр тормышындагы мөһим вакыйгаларга килгәндә, беренче чиратта «Европа татарлары Альянсы» оешуны атап була. Альянс составына Европа Берлегендәге 15 илдән (Австрия, Алмания, Бельгия, Болгария, Бөекбритания, Венгрия, Италия, Латвия, Литва, Польша, Словакия, Франция, Швейцария, Швеция, Эстония) 31 оешма керә. Альянсның оешу конференциясе 2013 елда Бельгиянең Брюссель шәһәрендә Европа парламенты бинасында узган иде. 2014 елда әлеге оешма, рәсми теркәлү узып, Бельгиянең Юстиция министрлыгы реестрына кертелде. 2023 елда ул үзенең 10 еллыгын бәйрәм итәчәк. Альянсның төп максатлары –татар телен һәм мәдәниятен үстерү, Татарстан Республикасы казанышларын Европа Берлеге илләрендә танытуга юнәлгән проектларны тормышка ашыру, Европа илләрендә гомер итүче милләттәшләребез арасында элемтәләрне киңәйтү һ.б. БТК Альянсның оешуын һәм аның эшчәнлеген соңгы еллардагы иң әһәмиятле проектларның берсе, дип бәяли, чөнки бу безгә Европада татар мәдәниятен һәм туган телебезне сакларга киң мөмкинлекләр ача. Моның матур үрнәге итеп, Литваның Кырык Татар авылы һәм Немежис шәһәрләрендә, Польшаның Бохоники һәм Крушиняны авылларында, Европа Берлеге фондларының матди ярдәме белән, яңа татар милли-мәдәни үзәкләрен ачуны да атап була. Мондый үзәкләрнең барлыкка килүен без читтәге татар дөньясы үсешенең төп юлларыннан берсе дип саныйбыз.

Балтыйк буе. Латвиядәге милләттәшләребез дә Европа фондлары грантлары белән бик уңышлы файдаланалар. Әйтик, Латвия татарларының

«Идел» оешмасы тарафыннан 3 телдә (татар, рус, латыш) Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилгә багышланган, 2 басмада «Татар халык ашлары», Ригада яшәүче милләттәшебез Гөлфия Хурамшинаның әсәрләрен туплаган китаплары – барысы да әлеге фондлар ярдәме белән чыгарылган.

Балтыйк буе илләрендә гомер итүче милләттәшләр турында сөйләгәндә, татарларның Литва тарихында мөһим эз калдырулары аерым игътибарга лаек. Татарларның Бөек Литва кнәзлеге җирләрендә урнашу вакыты XIV гасыр азагына карый һәм кнәзь Витовт исеме белән бәйле. Быел татарлар бу җирләргә урнашуларының 625 еллыгын бәйрәм итәләр. Литва дәүләтчелеген, тарихын һәм мәдәниятен формалаштыруга керткән өлешләре өчен рәхмәт йөзеннән, илнең Сеймы 2021 елны Литва татарлары тарихы һәм мәдәнияте елы дип игълан итү дә зур әһәмияткә ия. Әлеге вакыйгага бәйле Литва хөкүмәте татарларның мәдәни, дини яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыру максатыннан, фәнни, мәдәни, фәнни-гамәли чаралар планын раслаган иде. Хәзерге вакытта Литвада татарлар Вильнюс, Немежис, Клайпеда, Висагинас, Каунас, Алитус шәһәрләрендә һәм Ряйжяй, Кырык татар авылларында яшиләр.

Польша. Польшаның Гданьск шәһәрендә татар сугышчысына һәйкәл куелу да милләтебезнең Европада танылуының бер чагылышы булып тора. Ул 2011 елда Польша–Литва дәүләтенең турыдан-туры татар гаскәриләре ярдәм иткән 1410-нчы елда булган Грюнвальд сугышындагы тарихи җиңүенә бәйле куелган. Ачылу тантанасы вакытында Польша Президенты пан Бронислав Комаровски үзенең әнисе белән һәйкәлгә чәчәкләр куйганда, пани Ядвига әтисе ягыннан булган татар тамырлары белән горурлануын сөйләгән иде. Бу хәл полякларның анда яшәгән татарларны үз итеп кабул итүләрен аңлата. Польшада татарлар белән поляклар язмышы бергә үрелгән.

Финляндия. Чит илләрдәге татар оешмаларына бәя биргәндә, без аларның үз илләрендә тоткан урыны турында да әйтергә тиеш. Бу оешмаларның күбесе бүгенге көндә инде ныклап аякларында басып торалар. Әйтик, 1925 елда оешкан Финляндия татарларының «Исламия» җәмгыятенең юбилее уңаеннан, милләттәшләребезгә хөрмәт йөзеннән, татар мәркәзенә Финляндия Президенты үзе килеп җәмгыять активистлары белән очрашты. Мондый очрашуларга Финляндиягә ислам илләреннән һәм төрки дәүләтләрдән килгән башка рәсми шәхесләр дә җәлеп ителә. Бу вакыйгалар, һичшиксез, анда яшәүче татарларның илдәге дәрәҗәсен ачык күрсәтә.

### Массакүләм мәгълүмат чаралары

Чит илләрдә татар оешмаларының тормышы «Летовус тоторяй» (Литва), «Өмет», «Фикер», «Семипалат татарлары» (Казакъстан), «Татар ка-

рашы» (Польша), «Дуслык» (Украина), «Мәхәллә хәбәрләре» (Финляндия) кебек газета-журналларда яктыртылалар. Шулай ук чит илләрнең Рига (Латвия), Бишкек (Кыргызстан), Таллин (Эстония), Ташкент (Үзбәкстан) шәһәрләрендә җирле радиоларда татар телендә радиотапшырулар булу да зур әһәмияткә ия. Үзбәкстан белән Казакъстанда «Татарстан-Яңа Гасыр» телеканалының корреспондентлык пунктлары да эшли.

Агымдагы елның истәлекле вакыйгаларының берсе булып чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең иҗат җимешләрен туплаган «Кыйтгалардан килә татар сүзе» китабы басылып чыгуны әйтеп була. Китап Австралия, АКШ, Беларусь, Казакъстан, Латвия, Төркия, Үзбәкстан, Швеция, Эстониядәге милләттәшләребезнең җирсү хисләре белән сугарылган иҗат үрнәкләре белән таныштыра. Бүгенге көндә чит илләрдә яшәп, үзләренең талантлары белән әдәбият үсешенә өлеш керткән татар телендә иҗат итүче милләттәшләребезнең мондый уникаль әсәрләр җыентыгы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты тарафыннан беренче тапкыр тәкъдим ителде. Китап, үз укучысын табып, халкыбызның әдәби мирасын, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрен баетуга өлешен кертер, дигән өметтә калабыз.

* * *

Бүгенге көндә татар җәмгыятьләре тормышында күп кенә уңай үзгәрешләр бара. Бу барлык милли өлкәләргә – иҗтимагый оешмаларга, яшьләр хәрәкәтенә, дин эшлеклеләренә, эшмәкәрләргә һ.б. кагыла. Соңгы вакытта татарларның үзләренең рухи ватаннары итеп санаган Татарстан башкаласында тагы да ныграк берләшергә омтылышы күзәтелә, алар республика үсешендәге уңышларга сөенеп, туган кыенлыклар өчен борчылып яши.

Әлеге язмада БТК Башкарма комитетының чит илләрдәге милләттәшләр белән эшчәнлегенә, чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары тарафыннан башкарылган эшләргә бәя бирү максаты куелмады. Кайбер мөһим эшләр, бәлки, әйтелмичә дә калгандыр. Бүгенге көндә дөньяның төрле кыйтгаларында милләтебезнең кайгыларын, шатлыкларын тоеп яшәгән шәхесләребез, татар халкына хезмәт итәргә теләгән кешеләребез, шөкер, бик күп! Ә менә шушы олы көчне бер учка берләштерү, безнең уртак максатыбыз һәм изге бурычыбыз булып тора.

*Юлай Шамилуглы*

# ТАТАРНЫҢ КОСМОПОЛИТ ЮГАРЫ МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ



Мин 1958 елда Нью-Йорк шәһәрендә туган бер татар баласымын. Әтием Башкортостанның Чакмагыш районында Митрәй-Аюп исемле авылда туган бер татар, әнием – Пензадан күчеп киткән татар-мишәр гаиләсеннән. Икенче Дөнья сугышында Кызыл Армиядә алманнарга әсир булып төшкән, сугыштан соң Алманияда калган, 1951 елда АКШка күчә алган. (Аның мөхәҗирәт итә алуы өчен башта Казан татарларының «сары җенестән» булмаганын раслаган бер мәхкәмә карары чыккан иде, аның турында аерым бер мәкалә язарга уйлыйм.) Әнием, Амур елгасы буендагы Благовещенскида туып, Маньчжуриядәге Харбин шәһәрендә үсте. Төркия Республикасы, Ерак Шәрыктәге төрки халыкларны кардәш милләтләр буларак танып, аларга Төркия ватандашлыгын бирде, шулай итеп әниемнең гаиләсе 1950-нче елларда Төркиягә күчте. Әтием, АКШ паспортын алганнан соң, 1957 елда, дусларын күрергә Төркиягә барганда әнием белән танышып, бергә тормыш корырга аңлашалар. Әнием шул ук елны әтиемнең янына мөхәҗирәт итә. Мин туй көннәренә бер ел калмый торып, дөньяга киләм. Шулай итеп, минем «туган ягым» – Нью-Йорк, шушы шәһәренең «The Bronx» дигән районы...

Өйдә әти-әни гел татарча сөйләшкәч, Нью-Йоркта тууыма карамастан, ана телем – татар теле. Өйгә килгән кунаклардан сирәк кенә урыс телен ишетә идек. Инглиз телен мин һәм энем телевидениедән өйрәндек бугай; табигый, берара инглиз теле көчлерәк була башлады, әмма татар телен һич онытмадык. Әни гарәп хәрефләре белән, әти яңалиф белән язалар иде, әмма әти, русча азбукалар сатып алып, безгә кирилл хәрефләрен өйрәтергә тырышты. Шуны аз-маз өйрәнеп калган идек, ләкин мин, гимназиядә 11 класста (энем шул ук вакытта 10 класста иде) урыс теленнән дәрес алганчыга хәтле, кириллицаны яхшы өйрәнә алмаган идем. Ялгышмасам, шул ук вакытта Индиана Университетына заказ биреп, «Татар Мануал» исемле бер китапны алдым, аның белән хәзерге татар әдәби телен берүзем укый башладым.

Табигый, минем әтием дә, әнием дә татар җанлы, милләтпәрвәр кешеләр иде. Бигрәк тә әти «Казан утлары» журналына язылган, шул журнални укый иде. Мөмкинчелек булганда, татарча пластинкалар табып ала иде. Университетта укыганда Нью-Йорктагы «Four Continent» исемле кибеткә барып, тюркологиягә кагылышлы китапларны эзли идем, татарча пластинкалар сатып алып, әтигә бүләк итә идем. Шуның өчен без балачактан ук татар халык җырлары, Илһам Шакиров, «Шүрәле» балеты һәм Рөстәм Яхинның җырлары белән үстек. Музыкадан дәрес алганга, энем белән бергә Нью-Йорктагы Татар клубында (исеме «American Tatar Association», ул әле дә бар, аның сайты: https://www.atany.com/) татар кичәләрендә татар җырларын уйнап бирә идек, олылар да татар халык җырларын һәм Рөстәм Яхинның җырларын яратып җырлый иделәр. (Кайбер гаиләдә тасмада да музыка бар иде, шуны әле Мюнхеннанмы таба алганнар?) Тукай кичәләрендә Тукай шигырьләре яңгырый иде, дини бәйрәмнәрдә анда намаз укырга, Пәйгамбәребезнең туган көнен билгеләр өчен «Мәүлет» шигыре укылганда аны тыңларга бара идек. (Кыйсса сүзен соңрак, тюркология укыганда гына өйрәндем.) Берничә тапкыр сәхнәләр дә булды дип хәтерлим... (Ләкин драматург кем булган икән, Гаяз Исхакыймы? Хәтерләмим...). Төрле көннәрдә (мисал өчен, АКШта май аенда әниләр көнен билгелиләр...) чәйләр дә булыр иде, пәрәмәч кичләре дә... (Нью-Йоркта өчпочмакны белми идем, беренче тапкыр 1989 елда Казанга барганымда күрдем...) Шуңардан тыш, ел саен бер дәүләт бакчасында Сабан туен да уздыра идек...

Мин Колумбия университетында укыган чагында, төрки һәм гарәп филологиясен һәм ислам мәдәниятен укый башлаган идем (бу турыда 2022 елның май аендагы «Казан утлары» журналында укып була). Ул чорда әти дә миңа Шиһабетдин Мәрҗани һәм Габдулла Тукайның сурәтләрен бүләк иткән иде. Төрки халыкларның һәм шуның арасында Совет чорыннан элекке татар ислам мәдәнияте белән кызыксынганлыктан, табигый, аларның да исемнәрен китапларда очраттым. Бигрәк тә Шиһабетдин Мәрҗани минем өчен бик кызык бер фигура булды. Аның турында ни булса да өйрәнү авыр иде, аның турында бик язмаган иделәр. Ш. Мәрҗанинең татарча ике томлык әсәрен «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» беренче тапкыр, ялгышмасам, 1985 елда табып укый алдым. Мин инде ул чакта Алтын Урда буенча диссертациямне якладым, Индиана университетында лектор идем. Вакыт узу белән XIX–XX гасыр татар ислам мәдәниятенең нинди булганын аңлый башладым. Шулай ук, чит илдә татар диаспорасының бер вәкиле буларак, Совет чорыннан элек җыйналган мирасыбызны кулга алып укырга мөмкинлек юк иде, аның татарча, гарәпчә, хәтта кайчакта фарсыча язылган әсәрләрен Европа һәм

Америка китапханәләрендә бик табып булмый иде әле. Хәзер инде, Аллаһка мең шөкер, күп әсәр яңадан басылып чыккан, күп әсәр кириллицада яңадан чыгарылган, күп яңа китап Интернеттан табыла, Татарстан мөфтиятенең сайтыннан Совет чорыннан башлап борынгы мирасыбызны инде дөньяның дүрт почмагыннан компьютердан (шул сайттның адресы: https://darul-kutub.com/) укып була! Әлеге хатирәләремне ни өчен аңлатам? Бөтендөнья татар конгрессы татарларга ни бирә, Россиядәге татар диаспорасына ни бирә, дөнья татар диаспорасына ни бирә? Шуны аңлап, яисә аңлата алу өчен тагын бер мәсьәләне күтәрмичә булмый, ул мондый: кем ул татар? Мин фәнни юлымнан йөреп, халыкара белемнең төрле теорияләренә һәм принципларына таянып, шуны аңладым: татар үзаңы һәр дәвердә үзгәреп торган, яңа чор заманасына килгәндә (модернлык, современность), бик каты үзгәргән һәм Совет чорында яңадан каты үзгәргән. Шуның классификациясен ясасак, күренә:

1. **Беренче дәвер – яңа чор заманыннан элгәреге чор (пре-модерн).** Халыкаралык теориясенә карасак, ул дәвердәге кешеләр үз-үзләренең кайдан килгәннәренә бәйле (гарәпчәдә нисба, мисал өчен әл-Казани шуны күрсәтә), яисә кабиләсенә карап (татарларда да кабилә яисә ырулар булган, шуларның кайберәүләре башкортлар белән уртак!), яисә диненә күрә таныткан (мисал өчен мөселман, христиан, яһүди). Бу дәвердә хакимияттә булган биләүченең дине дәүләт дине буларак өстен булыр иде, үрнәк буларак Госманлы империясендә һәм Казан ханлыгында – ислам дине, Мәскәүдә – православ христиан дине, Италияда – католик-христиан дине һ.б. Бу дәвердә динсез (секуляр) бер данә дә юк. Мөселман татарларының тормышында ислам диненең тышында тормыш, белем бирү булмаган. Татарларның йолалары, гореф-гадәтләре һ.б. мөселманныкы дип кабул ителгән булган. Минем өчен болгарчылар да үз-үзләрен ислам диненә бәйле күреп, аны бу дәвернең бер күренеше яисә феномены буларак аңларга була....
2. **Икенче дәвер – яңа чор заманасы чоры (модернлык).** Күпчелек галимнәр (һәммәсе түгел) бу дәвернең башлангычын XVIII гасырның ахырына, Франциядәге инкыйлабка бәйли. Татарларда шул замана XIX гасырдагы татар яңарышына туры килә. Ул дәвердән башлап дини булмаган предметлар укытыла башлый. Дини булмаган газетлар һәм китаплар нәшер ителә башлый, һәм дингә генә нигезләнмәгән кемлек, ягъни үзаң барлыкка килә. Вакыт узу белән, яңача сәяси идеологияләр дә барлыкка килә. Бу процесста Шиһабетдин Мәрҗанинең керткән өлеше турында күп язганнар, ул татар этносын коручы түгел, ә Урта Идел буеның җирләренә нигезләнгән яңа

бер милли татар тарихы концепциясе аркылы яңа бер татар үзаңы концепциясен коручы булды. Ул дәвердә яңача белем бирүдә аның өлеше булса да, аңардан тыш бигрәк тә Исмәгыйль Гаспралының яңа мәктәпләр ачуга керткән өлеше бик әһәмиятле. 1917 елга хәтле татарларда бик көчле бер милли хис барлыкка килгән иде, моны Тукайдан һәм Исхакыйдан аңлыйбыз. Шул ук вакытта андый яңача үзаңны инкяр итүчеләр дә булган (алар, ислам диненең иске хәлен хуплап, яңача белем бирү һәм башка күренешләргә каршы иделәр), шуның белән бергә татар урынына «төрек» дип әйтүчеләр дә булган, Бу исә Исмәгыйль Гаспринскийның йогынтысы (моның турында бик күп әйтергә була, урыны монда түгел...).

3. **Өченче дәвер – Совет чоры.** Шул дәвердән башлап, татарларны башкортлардан аеру процессы рәсмиләштерелгән. (Һәм, гомумән, төрки халыкларны бер-береннән рәсми рәвештә яңадан атап бүлү киткән), татар этносының бер әсасы булган ислам мәдәниятен тыеп, татарларны аңардан ераклаштыру, татар прозасының иң мөһим шәхесен, Гаяз Исхакыйны тыю, татар һәм төрки дөньясының зыялыларының каймагын да, сөтен дә репрессияләү аркылы яңа бер автономиялек республикасының, яңа бер әдәби теле, яңа әдәбияты, яңа каһарманнары, яңа мәдәнияте корылды. Бу килешнең хуш яклары да, хуш булмаган яклары да бар, дип әйтергә була (Эстетика ягыннан карасаң, мин үзем Европа сәнгатенең төрк мәдәниятенә яисә татар мәдәниятенә дә йогынты ясавына каршы түгелмен, матур музыка, әдәбият, рәсемнәрне һәммә кеше ярата алсын, дип ышана алам...).
4. **Дүртенче чор – Советтан соңгы чор, Татарстан Республикасы, Бөтендөнья татар конгрессы чоры...**

Шул 3–4 дәверне истә тотмыйча, татар дөньясын аңлап та, тасвирлап та булмый. XIX гасырның соңында (мисал өчен, Финляндиягә) мөһаҗирлек иткән татарлар дөньясында дини үзаң бик көчле булган, татар милли фикере аларда 1980 еллардан башлап кына көчле була башлады. СССРда һич яшәмәгән татарларда әле дә көчле, кайбер гореф-гадәт тә саклана килә. Күп кеше урыс телен белми; белүчеләрнең Төркиядә, АКШта, Австралиядә үскән балалары русча белми. Алар Совет кешесе түгел, постсовет кешесе дә түгел!

Гафу итегез, тагы бер теорияне аңлатмыйча булмый, ул да кемлек яисә үзаң турында өч төп академик караш. Кыскача гына татарларны үрнәк итеп күрсәтсәк:

- Беренчесе – примордиализм: «татарлар, иң борынгы заманнан башлап, аерым бер халык булган»;

- Икенчесе – эссенциализм: «татарларны татар ясаган татарга хас махсус әйберләр бар». Үрнәк буларак, моң, түбәтәй, өчпочмак, гармун, һ.б. нәрсәләрне күрсәтеп була...
- Өченчесе исә – конструктивизм: «татарлар концепциясе / теориясе ясалма». Ясалма, дигәнем дә шулай: мәгълүм бервакытта, мәгълүм кешеләр тарафыннан, мәгълүм сәбәпләрдән һәм максат белән чыгарылган. (Мисал өчен, татарлар буенча татар теориясен XIX гасырда зур галимебез Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре уйлап чыгарган. Аның нигезендә үз дәверендәге татар этносы һәм җирлеге тора.) Күп галим шулай итеп уйлый, әмма этносның роле турында күп бәхәс бар, мөмкин шуны балаларга мәгълүм сәбәпләрдән укыту дөрес булмас, әмма тарихчылар аны белергә тиеш...

Тел мәсьәләсе дә бар. Шәхсән, минем үзем өчен телсез татар – татар була алмый, әмма кайбер милләт хәтта өч телле, мисал өчен Швейцария...

Шуларның һәммәсен исәпкә алып һәм «кем ул татар?» дигән сорауны истә тотсак, Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык эшчәнлеге турында нинди нәтиҗәләргә килеп була?

1. БТК татар диаспорасы белән тыгыз элемтәдә. Бу бик дөрес. Рәсәй эчендәге татар диаспорасы белән күрешү уңайлы, шуның хәбәрләрен БТК сайтыннан күреп барырга була (сайт: tatar-congress.org). Рәсәй тышындагы элемтәләр тагын да якын булса, яхшы булыр иде. Пандемия сәбәпле, онлайн режимга күчү бик уңышлы һәм файдалы булды, кайчакта технологик проблемалар булуына карамастан. Технологик проблемаларның ни булганын өйрәнеп, аларны хәл итү кирәк.

2. Дөньяның һәр почмагыннан татарлар катнашканда бернәрсә бик ачык аңлашыла: БТКның җыелышларында русча чыгыш ясаганда яисә сөйләгәндә, электән СССРның тышында яшәүче диаспора әгъзаларының күбесе аңлый алмый, зарланучылар була, хәтта җыелыштан чыгып китүчеләр дә була. Рәсәй тышындагы диаспора белән элемтәләрне татар теле белмәгәнлектән өзү дә дөрес булмас! Бу мәсьәлә каралырга тиеш, урыс телен куллануны дәвам итсәгез, дөньядагы татар диаспорасы белән хушлашырга кирәк булыр, ә татарча белмәгәннәрне чыннан, стратегия буларак, татар дип исәпләргәме?

Иң азында Zoom программасында ике канал, татарча – бер канал, урысча – бер канал (кирәк булса) һәм мөмкин, өченче – инглизча бер канал (?) кулланырга кирәк.

3. БТК – Татарстанда, Башкортостанда һәм Рәсәй Федерациясенең башка республикалар һәм төбәкләрендә, элеккеге СССР республикаларында һәм дөньяның һәр мәмләкәтендә яшәүче татар диаспорасы өчен нигез салучы, ярдәм итүче, илһам бирүче, фундаменталь бер таяныч,

телне, кызыксынучылар өчен динне, һәм барыбыз өчен мәдәниятне саклауга этәргеч булырга тиеш. Төбәкләргә эстрада җырчыларын, биючеләрне, гармун тартучыларны җибәрү – яхшы, ярый әле мунча өстерәп йөрмиләр! Татар диаспорасына өчпочмак, чәкчәк ашатуларга каршы түгелмен (ләкин шәхсән минем өчен бу җитәрлек түгел).

4. БТКның үзенең генә татар телен, татар мәдәниятен саклап калырга көче юк. Татарстан Республикасы, «Татарстан-Яңа гасыр» каналы белән берләшеп, татар теле, татар мәдәнияте буенча программаларны көчәйтергә тиеш. (Казакъстанда кайвакытта «ТНВ-Планета»ны ачканда урыс телендә гади программалар белән каршыласаң, татар диаспорасына аның кызыгы юк инде...) Татар телен укыту буенча аерым программа кирәк. Татар теле эчендә булган төрки дөньясында телне укыту методикасы бер фаҗига, материаллар яхшы түгел. (Төркиядә бу мәсьәлә инде хәл ителә бара.) Яхшырак методика буенча телне укыту, яхшы материаллар әзерләп, шуларны бөтен татар дөньясы белән Интернет аркылы бүлешү бүгенге көндә бик реаль. Татар теле үлсә, татар дигән милләт юкка чыгачак, Гаяз Исхакый әйтмешли, 200 елдан соң инкыйраз (100 ел гына калды...). Татарстан Республикасы һәм министрлыклары, «ТНВ-Планета», БТК берләшеп, шуның белән шөгыльләнергә тиеш.

5. Мин авылда тумадым, әтиемнең авылына, кызганычка каршы, бер генә тапкыр бара алдым. Миндә туган ил хәсрәте юк. (Табигый әтиемдә бар иде!) Мин Нью-Йоркта, Нур-Солтанда операга йөрим, өйдә классик Европа музыкасын, дөнья музыкасын (ягъни, төрле халыкларның музыкаларын), джаз тыңлыйм. Төрле халыкларның ашлары белән сыйланам. Хобби буларак, үзем дә аш пешерергә яратам. Ел саен Яңа ел көнне, әниемнең туган көнен искә алу өчен, пәрәмәч тә ясыйбыз. Космополит бер татар буларак, Илһам Шакиров җырлаган җырларны һәм татар халык җырларын тыңлыйсы килә. Болар компакт дискта Казанда табыла. Бала чакта әтием белән бергә тыңлаган Яруллинны, Яхинны да тыңлыйсы килә, Казанда булсын, Интернетта булсын, таба алмыйм... Казанга барганда, йә театр сезоны түгел, яисә эшләрем арасында театрга барырга вакыт таба алмыйм. Нур-Солтанда бер тапкыр Буа театрын күрдем, мине чакырганнарына рәхмәт. (Аларны БТК китергән булыр, дип уйламыйм...) Совет эстрадасы да СССРда үсмәгән татарлар өчен бераз ят бер феномен. Татардагы иң югары сәнгатьнең дә үрнәкләре татарлар яшәгән һәр урынга килеп җитсә иде. «ТНВ-Планета» кебек каналларда, Интернетта яңгыраса иде.

Татар-ислам мәдәниятенең тамырлары бик тирән. Теләсәгез, 250 еллык, 550 еллык, теләсәгез инде, 1100 еллык! 1917 елга хәтле татарлар төрки дөньясының бер полюсы, ягъни бер котыбы иде. Инде нинди мес-

кен хәлгә төшкәнне карагызчы! БТК татар фәне турында диаспорадагы яшьләр арасында яңадан кызыксынуны уятырга ярдәм итсә! Татар югары мәдәниятенә хөрмәт күрсәтеп, аны татар дөньясына тарату кирәк. Тукайны бер сайт (http://gabdullatukay.ru) аркылы укырга була, шуңа, шөкер, ләкин диаспорадагы яшь татарларның күбесе кириллицаны белми. Мин үскәндә татар хисен көчәйтү өчен Тукай кичәләре бик мөһим роль уйный иде. БТК дөнья буенча Тукай кичәләрен оештырырга ярдәм итә микән? Татар милли китапханәсенә бармый торып, татар әдәбиятын чит илдә ничек укып була икән? Татар диаспорасы Тукайны, Исхакыйны укый алмаса, Яруллин һәм Яхинны тыңлый алмаса, татарча сәхнәләрне күрә алмаса, бу нинди татар диаспорасы, татар кинофильмы турында әле бәхәсләшеп булмый да...

Мин, бәлкем, бераз артыгы белән каты әйткәнмен. Авыл халкында милләтнең чын күренешен табу фикере XVIII гасырда Алманиядә башланган, бу күп халыкта, урысларда да бар. Татарларда шундый күренеш бар дип гаепләп булмый. «ТНВ-Планета» өчен булсын, кайчакта каналны Казакъстанда ачканда, татарча сәхнә (яисә «Таңчулпан», яисә башка кызык программалар) бар. Ләкин студиядә авылдагы биюләрне күрсәткәндәй программалар булганда, мин андыйны карый алмыймын, сүндереп башка каналга күчәм. Мин бит Нью-Йоркта туып үскән космополит бер татармын!

БТКның эшчәнлегендәге бер юнәлештә СССРда үсмәгән татарларга игътибар җитми, бер-беребезне аңларга тырышсак та, бик авыр. Бер яктан, тел мәсьәләсе бар: татарлар өчен татар теле бик кадерле, ләкин БТКда телгә шул ук дәрәҗәдә бәя бирелми, төбәкләргә инде барып татарча сөйләшмәгән кешеләргә чыгышлар, биючеләр, гармун тартучыларны китереп, өчпочмак һәм чәкчәк ашатып, урысча чыгыш ясап, интервью алалар. Шундый тамашаны күреп, ашап-эчеп, артык татарча белү кирәкми бит! Татар мәдәниятен саклап, күтәреп, җанландырып, килештереп, көчәйтеп, дөньяга тәкъдим итеп, дөньядагы татарларга мәгънәви ризык бирү – ул күпкә авыррак шул... Мин Бөтендөнья татар конгрессыннан шуны көтәм, татар диаспорасында туып үскән бер татар җанлы галим буларак, шуны таләп итәм. Инкыйразга 100 генә ел калды...

*З.И. Канапацкая*

# НАЦИОНАЛЬНО-РЕЛИГИОЗНОЕ ВОЗРОЖДЕНИЕ БЕЛОРУССКИХ ТАТАР В КОНЦЕ XX – НАЧАЛЕ XXI ВВ.

*К 625-летию проживания татар на землях Беларуси, Литвы и Польши*



История татар на землях Беларуси насчитывает более 600 лет и неотделимо связана с исламской религией. В результате длительного проживания в новых условиях, татары утратили родной язык и даже сменили хозяйственный тип деятельности, единственным фактором, позволившим избежать ассимиляции в окружении значительно более многочисленных этносов, стал для них ислам. Несмотря на различные социально-политические потрясения, войны, периоды религиозных гонений, татары сумели сохранить религию предков.

Возрождение исламской религии в Беларуси, начавшееся в конце 1980-х гг. осуществлялось в тесной взаимосвязи с национально-культурным возрождением татар, составлявших абсолютное большинство мусульман на территории республики, фактически представляя собой единый процесс.

Условно можно выделить его три основных этапа: с конца 1980-х до 2005 г., с 2006 по 2015 гг. и с 2016 г. по настоящее время.

У истоков движения национального и религиозного возрождения белорусских татар стояли Исмаил Меметов, Ибрагим Канапацкий, Якуб Якубовский, Исмаил Александрович, Али Шагидевич, Магомет Богданович, Мустафа Шабанович, Исмаил Шабанович, Мустафа Радкевич, Али и Юсуф Криницкие, Александр Криницкий, Ибрагим Александрович [Жизнь: 2004. С. 2].

В 1989 г. в Минске и Гродно были созданы первые татарские культурно-просветительские общества, которые в августе 1991 г. объединились в Белорусское объединение татар-мусульман «Аль-Китаб» [Канапацкі: 2018] (в январе 2001 г. переименовано в Белорусское общественное объединение татар «Зикр уль-Китаб). Это позволило привлечь к движению возрождения новых активистов, которые, в свою очередь, привнесли с собой новые идеи и предложения. Следует отметить, что основное вни-

мание в процессе национального возрождения было уделено изучению богатого исторического наследия белорусских татар [Жизнь: 2004. С. 2].

Активная деятельность в указанном направлении развернулась в других местах компактного проживания татарской диаспоры. В частности, в 1994 г. в Слониме был проведен Международный съезд татар, в котором приняли участие гости из разных уголков Беларуси, а также Англии, США, Польши, России [Мусульманский вестник: 2014. С. 6].

Практически одновременно началась работа по возрождению традиционной религии белорусских татар – ислама, состоявшего на первоначальном этапе из изучения арабского алфавита, знакомства с правилами чтения молитв при выполнении намазов, изучения коротких сур Корана. В 1992 г. были зарегистрированы мусульманские религиозные общины в Минске, Гродно и Новогрудке, в 1993 г. в Ивье. Всего до 1994 г. было официально зарегистрировано 11 мусульманских общин [Жизнь: 2004. С. 2]. В 1994 г. в Минске состоялся I съезд мусульман Беларуси, результатом которого стало создание Республиканского объединения «Мусульманское религиозное объединение в Республике Беларусь». Первым председателем (муфтием) религиозного объединения был избран уроженец Клецка И.М. Александрович. Первым съездом мусульман страны, а также Вторым (1996 г.) и Третьим (1998 г.), в качестве первостепенных задач возрождения и развития ислама в стране были закреплены следующие: организация новых мусульманских общин, обучение детей и взрослых основам ислама, приобретение или строительство помещений и мечетей для учебы и молитв, установление и развитие контактов с исламскими странами и организациями.

Первое десятилетие деятельности Мусульманского религиозного объединения Республики Беларусь было достаточно успешным в решении поставленных задач. Так, в период с 1994 г. по 1999 г. было организовано 13 новых мусульманских общин [Там же]. Одним из важнейших направлений деятельности стало восстановление и строительство культовых зданий, так как на момент начала религиозного возрождения в Беларуси функционировала всего одна мечеть в Ивье, что не могло удовлетворить потребности верующих. В вышеуказанный период были построены, восстановлены и введены в действие 7 культовых зданий и помещений: в Слониме (1994 г., Гродненская область), Смиловичах (1996 г., Червенский район Минской обл.), Новогрудке (1997 г., Гродненская обл.), Видзах (1999 г., Браславский район Витебской обл.), Клецке (2000 г., Минская обл.), Ловчицах (2002 г., Новогрудский район Гродненской обл.), Молодечно (2002 г., Минская обл.). Открыт исламский культурный центр в Ивье (1995 г., Гродненская обл.). Символическое значение для мусульман

Беларуси имело начало строительства в апреле 2003 г. здания Соборной мечети в Минске рядом с бывшим мусульманским кладбищем на пересечении улиц Игнатенко и Грибоедова, осуществлявшееся при финансовой поддержке международной неправительственной организации «Лига исламского мира» (Саудовская Аравия). Важным свидетельством возрождения татарских религиозных и национальных традиций стало возобновление на регулярной основе ежегодных съездов на мизарах (мусульманских кладбищах).

Знаковое событие в сфере национального возрождения – празднование 600-летия поселения татар на землях Великого княжества Литовского, отмечавшееся в течение 1997 г. и проходившее в несколько этапов. Торжества были организованы на территории Беларуси, Литвы и Польши с привлечением широкого круга татарской общественности указанных стран, а также из Татарстана, Крыма и иных регионов. В числе мероприятий, приуроченных к торжественной дате, состоялись Международная научно-практическая конференция «Татары-мусульмане на землях Беларусі, Літвы і Польшчы», проведенная в Минске, съезды на мизарах в Видзах, Докшицах, Мяделе, встречи представителей татар Беларуси, Литвы и Польши в Вильнюсе, Каунасе и Белостоке, открытие после реконструкции мечети в Новогрудке, проведение «Караван-Байрамов» в Новогрудке, Ивье и Смиловичах, а также заседание Исполкома Всемирного конгресса татар и праздничный концерт в Минске [Жизнь: 1998. С. 7]. Об общегосударственном масштабе указанного события и внимании со стороны органов власти и управления к юбилею свидетельствуют встреча Президента Беларуси с руководством мусульманских религиозных и татарских общественных организаций в ноябре 1997 г., а также принятие Мингорисполкомом решения о переименовании улицы Вилейской в районе бывшей Татарской слободы в Минске в улицу Татарскую [Там же].

Ключевое значение для возрождения исторического, культурного и религиозного наследия татар имела развернувшаяся в рассматриваемый период активная научно-исследовательская и издательская деятельность. Так, в 1993–2005 гг. при заинтересованном участии председателя минской татарской общины, заместителя муфтия Беларуси, Ибрагима Борисовича Канапацкого было проведено 11 международных научно-практических конференций, посвященных истории и проблемам ислама и татарской диаспоры. В их работе приняли участие более 150 ученых из различных стран мира [Канапацкая: 2015]. Кроме того, было организовано проведение ряда региональных научно-практических конференций по истории татар, «круглых столов», семинаров по исламской тематике.

Одним из важнейших направлений стало изучение рукописного книжного наследия белоруско-польско-литовских татар из коллекции Центральной научной библиотеки Национальной академии наук Беларуси, а также библиотеки Мусульманского религиозного объединения и объединения «Зикр уль-Китаб», получившее дополнительный импульс в 1990-е гг. на волне татарского национального и религиозного возрождения. Результатом указанной деятельности стало открытие в декабре 2001 г. выставки-презентации «Рукописи литовских татар XVII–XX веков из коллекции ЦНБ НАН Беларуси», организованной отделом редкой книги и рукописей ЦНБ совместно с Мусульманским религиозным объединением в Республике Беларусь и Белорусским общественным объединением татар «Зикр уль-Китаб».

В 1991 г. впервые за всю 600-летнюю историю проживания на белорусской земле появилось первое татарское печатное издание – ежеквартальный журнал «Байрам. Татары на зямлі Беларусі». С 1994 до 1997 года выходил ежемесячный мусульманский журнал (вышло 24 номера под различными названиями – «Аль-Джихад», «Аль-Ислам», «Жизнь») [Канапацкая: 2015]. В 1997 г. стала издаваться ежемесячная газета Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь «Жизнь». С 2001 г. в качестве приложения к «Жизни» начал выходить бюллетень объединения татар «Зикр уль-Китаб» «Жыццё татарскае». В 2004–2005 гг. вышел ряд номеров журнала «Ислам сегодня». Помимо этого, необходимо отметить издание мусульманской религиозной общиной Слонима газеты «Нур-Свет», выходившей в течение 3 лет в начале 2000-х гг. и распространявшейся в 18 городах Беларуси [Мусульманский вестник: 2014. С. 6].

В начале 1990-х и в 2000 гг. вышли в свет обобщающие работы по истории белорусских татар. Так, в 1993 г. была издана работа С.В. Думина и И.Б. Канапацкого «Беларускія татары: мінулае і сучаснасць». В сентябре 2000 г. состоялась презентация книги И.Б. Канапацкого и А.И. Смолика «Гісторыя і культура беларускіх татар», значительное место в которой занимают материалы, посвященные в том числе языковой культуре, письменности белорусских татар, их обрядовой традиции, религиозной жизни, быту и основным занятиям [Жизнь: 2000. С. 2].

Дважды – в 1997 и 1999 гг. Мусульманским религиозным объединением осуществлялось издание «хамаилов» (молитвословов) с использованием кириллического алфавита [Жизнь: 2000. С. 5].

Значительные шаги были сделаны в сфере возрождения религиозного образования в татарских общинах. Так, за вышеуказанный период времени была организована работа 8–9 воскресных школ в общинах [Жизнь: 2004. С. 2]. Проведено 9 учебно-оздоровительных лагерей-«мухайемов»

(в 1994–2001, 2003 гг.) мусульманской молодежи Беларуси, которые помимо изучения основ ислама, включали в себя культурную, спортивную и развлекательную программы. Данные мероприятия носили массовый характер, что свидетельствует о масштабах движения возрождения. В частности, в летнем лагере 1999 г. приняло участие более 100 детей из 25 мусульманских общин Беларуси [Жизнь: 1999. С. 4].

С декабря 1999 г. при мусульманской религиозной общине Минска действовали курсы по обучению исламским обрядам [Жизнь: 2000. С. 8], с июля 2001 г. проводились семинары имамов и руководителей мусульманских общин [Жизнь: 2001. С. 3]. На протяжении нескольких лет (1999–2001 гг.) представители татарской молодежи из Беларуси, по приглашению Мусульманского религиозного союза Польши, принимали участие в работе летней Академии знаний о польских татарах в Сокулке и Домброве (Польша). Во время проведения академий были организованы лекции по истории, культуре татар, исламской религии. В августе 1999 г. попытка возрождения традиции проведения татарских балов была предпринята руководством мусульманской религиозной общины Слонима. В рамках указанного мероприятия состоялся съезд татарской молодежи, в котором приняли участие около 150 представителей татарских общин из 13 городов Беларуси, а также гости из Литвы [Жизнь: 1999. С. 4].

Необходимо отметить, что в процессе организации учебных занятий в воскресных школах, учебно-оздоровительных лагерей, религиозных мероприятий руководством объединения, а также руководителями отдельных региональных общин активно привлекались в качестве преподавателей уроженцы арабских стран, проживавшие в республике. Большинство из них составляли студенты и аспиранты белорусских ВУЗов. Помимо объективной пользы, отдельные из указанных иностранцев привнесли в мусульманскую общину Беларуси идеи религиозной нетерпимости, превосходства над другими религиями, радикализма, абсолютно не свойственные традиционному религиозному мировоззрению белорусских татар. Указанные обстоятельства в последующем имели негативные последствия для развития белорусского ислама. Помимо арабов руководством объединения и общин к осуществлению религиозной деятельности периодически привлекались исламские священнослужители из Турции, а также Татарстана.

Активное развитие на данном этапе получили международные отношения Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь и Белорусского общественного объединения татар «Зикр уль-Китаб». В числе основных направлений международного сотрудничества

можно выделить следующие: с мусульманскими религиозными и общественными организациями Турецкой Республики (Управление по делам религий Турции), арабских стран (Лига исламского мира – Саудовская Аравия; Всемирная организация исламского призыва – Ливия), Российской Федерации (Всемирный конгресс татар, Совет муфтиев России).

Кроме того, были налажены активные контакты и взаимодействие с мусульманскими организациями и татарскими общинами Польши и Литвы. В этой связи заслуживает внимания попытка организации единого координирующего органа татар четырех государств: в августе 2000 г. в польском Сокулке был подписан акт о создании Международной федерации татар Беларуси, Литвы, Польши, а также Украины – «Millet» («Народ») [Жизнь: 2000. С. 2]. Федерация была организована в качестве правопреемницы существовавшего в Петербурге и Вильно в 1917–1922 гг. Союза татар Беларуси, Литвы, Польши и Украины. В апреле 2002 г. вышел первый номер одниименного журнала «Millet». В состав редакционной коллегии указанного издания вошли крупные ученые и общественные деятели из Беларуси, Польши, Литвы, Украины и России.

Важное значение для укрепления связей между татарами Беларуси, Литвы и Польши имел международный форум с участием делегаций трех стран, состоявшийся в рамках празднования 10-летия мечети в Каунасе (Литва) в июле 2001 г. [Жыццё татарское: 2001. С. 3].

Несмотря на очевидные успехи в сфере национально-религиозного возрождения с конца 1999 – начала 2000 гг. в деятельности Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь наметились кризисные явления, обусловленные в первую очередь личными амбициями отдельных лиц в руководстве структуры и региональных общин, а также разногласиями в вопросах организации дальнейшей деятельности в сфере национально-религиозного возрождения. Указанные кризисные явления проявились в ходе очередного IV съезда мусульман Беларуси. Материалы периодических изданий объединения указанного периода свидетельствуют о конфликтной ситуации, возникшей между действующим руководством Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь с одной стороны и одним из членов муфтията И.М. Вороновичем, а также отдельными руководителями и членами региональных общин, с другой. На съезде кандидатура И.М. Вороновича была выдвинута для включения в состав муфтията, однако не прошла в результате голосования [Жизнь: 2000. С. 2]. В течении 2001 г. в объединении назревал раскол, о чем свидетельствует факт организации и регистрации И.М. Вороновичем вторых (помимо уже имевшихся) мусульманских религиозных общин в Минске («Свет Ислама») и Клецке

(«Ислам») [Жизнь: 2001. С. 3]. Попытки создания аналогичных структур осуществлялись в Могилеве и Молодечно [Там же]. Результатом указанной деятельности группы оппозиции стало создание в октябре 2002 г. на базе 5 мусульманских общин: Слонима, Витебска, Ляхович (ранее входивших в состав МРО в РБ), второй общины Клецка и второй общины Минска в лице Республиканского религиозного объединения «Духовное управление мусульман в Республике Беларусь» во главе с И.М. Вороновичем. Необходимо отметить, что большинство мусульманской общественности Беларуси, а также соседних стран негативно отнеслось к расколу [Там же]. Период 2004–2005 гг. ознаменовался еще более серьезным кризисом в Мусульманском религиозном объединении в Республике Беларусь, обусловленном в первую очередь негативным влиянием на ситуацию иностранных религиозных миссионеров и основного спонсора строительства Минской Соборной мечети – организации «Лига исламского мира» из Саудовской Аравии. В результате из состава объединения были выведены две молодежных организации, позже прекратившие свое существование [Шабанович: 2012]. После того как государственными органами были депортированы из Беларуси два представителя ЛИМ, последняя прекратила финансирование строительства мечети [Шабанович: 2012]. Об остроте кризиса свидетельствует факт несостоявшегося в 2004 г. очередного съезда мусульман Беларуси, а также смена руководства объединения в ходе V внеочередного съезда в октябре 2005 г. В результате выборов новым муфтием (председателем) Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь стал председатель Белорусского общественного объединения татар «Зикр уль-Китаб» А.-Б.Ю. Шабанович. Кризис первой половины 2000-х гг. усугубился в связи со скоропостижной смертью председателя минской общины, заместителя муфтия мусульман Беларуси, известного ученого Ибрагима Борисовича Канапацкого. Эта тяжелая потеря крайне негативна отразилась на процессе национально-религиозного возрождения белорусских татар, привела к ухудшению кадрового потенциала, практически полному прекращению научно-исследовательской и издательской деятельности мусульманских религиозных и татарских общественных организаций, снижению международной активности. Строительство Минской соборной мечети на длительный срок было практически остановлено, возобновляясь лишь эпизодически.

Новый этап, наметившийся в истории татарской диаспоры и белорусского ислама, охарактеризовала на страницах своего печатного издания редакция журнала «Байрам» как «темное время, черная полоса в духовной жизни, интеллектуальном движении татар» [Жизнь: 2019. С. 1]. Си-

туация в среде мусульман Беларуси в начале 2000-х гг. характеризуется деятельностью двух мусульманских религиозных объединений: Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь и Духовного управления мусульман в Республике Беларусь. Продолжающиеся разногласия между руководством указазнных структур непосредственным образом отражались и на обстановке в региональных общинах. В марте 2005 г. членами религиозной общины мусульман в Гомеле (зарегистрирована в 2004 г.) было принято решении о выходе из состава МРО в РБ и о вхождении в состав ДУМ в РБ [Мусульманский вестник: 2006. С. 2]. В это же время из состава МРО выходит религиозная община Гродно, продолжившая свое существование в качестве автономной. Вместе с тем, в сентябре 2005 г. члены мусульманской религиозной общины «Ихляс» Слонима (в 2002 г. объявившие об автономном статусе общины) приняли решение о повторном вхождении в состав Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь.

Несмотря на имеющиеся трудности и проблемы в указанный период, необходимо отметить и отдельные положительные моменты. В 2005 г. Духовным управлением мусульман в Республике Беларусь начинает издаваться газета «Вестник» (с 2006 г. – «Мусульманский вестник»), которая длительное время оставалась практически единственным мусульманским периодическим изданием в Беларуси (несколько раз предпринимались попытки возобновления издания газеты «Жизнь»). В мае 2008 г. впервые в Беларуси началось производство халяльных продуктов питания в Гомеле [Мусульманский вестник: 2008. С. 4]. В декабре 2008 г. религиозной общиной мусульман Гомеля впервые организован конкурс чтецов Корана [Мусульманский вестник: 2009. С. 2]. В 2012 г. для выдачи сертификатов стандарта халяль Мусульманским религиозным объединением в Республике Беларусь уполномочено ООО «БелХаляль» [Мусульманский вестник: 2014. С. 6]. В марте 2013 г. по согласованию с Духовным управлением мусульман Беларуси с аналогичной целью создано ООО «Халяль» [О центре: 2012]. С 2015 г. в Гомеле начинает функционировать новый мусульманский молельный дом – члены местной мусульманской общины реконструируют под мечеть помещение бывшего склада [Мусульманский вестник: 2015. С. 4].

Достаточно активную деятельность в национально-культурной сфере осуществляет Международное общественное объединение «Татарско-башкирское культурное наследие «Чишма», зарегистрированное в Минске еще в 1998 г. Указанным объединением ежегодно проводятся онлайн курсы татарского языка, мероприятия памяти татар, погибших в Великой Отечественной войне, памятные вечера, посвященные творчеству

татарского поэта Габдуллы Тукая, татарские Сабантуи, концерты национального творчества. В мае 2014 г. в Слониме начались съемки документального фильма «Непрыкметныя героі невядомай вайны», посвященного участию солдат-татар в Первой мировой войне. В съемках фильма приняли участие историки и эксперты из России, Германии, Франции, Литвы, Беларуси [Мусульманский вестник: 2014. С. 6]. С октября 2014 г. на базе минской общины «Свет Ислама» начали работать курсы по изучению татарского языка [Мусульманский вестник: 2014. С. 3]. Также, на данном этапе продолжались ежегодные собрания на мизарах, осуществление работ по их благоустройству.

Основные усилия руководства Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь в указанное время были направлены в первую очередь на поиск финансовых средств, необходимых для завершения строительства соборной мечети в Минске, которое периодически возобновлялось при участии спонсоров из арабских государств, России, Турции, а также за счет пожертвований верующих из Беларуси. Муфтий А.-Б.Ю. Шабанович в ходе очередных VI (2008 г.), VII (2012 г.), VIII (2016 г.) съездов объединения последовательно переизбирался на руководящую должность. В руководстве Духовного управления мусульман в Республике Беларусь в сентябре 2011 г. произошли изменения. После смерти И.М. Вороновича в ходе внеочередного съезда объединения муфтием был избран А.И. Воронович.

На протяжении последних десяти лет продолжают активно развиваться международные контакты мусульманских объединений Беларуси. Их представители принимают участие в крупнейших международных мусульманских форумах, съездах Всемирного конгресса татар. В июне 2014 г. делегация белорусских мусульман из Минска, Гомеля, Гродно по приглашению муфтия Польши Т. Мицкевича принимала участие в международном учебном лагере для молодых мусульман. Участников лагеря представляли мусульмане из стран Восточной Европы, Балтии, России, Азербайджана [Мусульманский вестник: 2014. С. 7]. В сфере религиозного образования налаживаются отношения с учреждениями, организациями Татарстана и Турции, куда на обучение направляются студенты из Беларуси. Мусульманским религиозным объединением в Республике Беларусь подписано соглашение с турецким Управлением по делам религий («Diyanet») о подготовке юношей и девушек из Беларуси для поступления в высшие учебные заведения Турции [А.-Б. Шабанович: 2012]. С начала 2010-х гг. при участии «Diyanet» возобновляется практика проведения международных научно-практических конференций по исламской и тюркской тематикам. Так, в октябре 2012 г. в связи с

615-летием возникновения татарско-мусульманской общности на землях ВКЛ в Минске состоялась международная научно-практическая конференция «Беларусь и тюркско-исламский мир», с участием исследователей из Беларуси, России, Украины, Литвы, Польши и Турции [Сынкава: 2015. С. 4]. В апреле 2015 г. прошла научно-практическая конференция «Преемственность духовного наследия Пророка Мухаммада – гарантия этноконфессионального мира и социально-политической стабильности в современном гражданском обществе», в которой приняли участие ученые и религиозные деятели из Беларуси и Турции [Мусульманский вестник: 2015. С. 4]. С конца 2014 – начала 2015 гг. при поддержке турецкой стороны возобновляется строительство здания соборной мечети в Минске.

Несмотря на определенные успехи в сфере религиозного возрождения в 2006–2015 гг., анализ событий указанного периода свидетельствует о значительном снижении первоначального всплеска национально-религиозного энтузиазма в татарском обществе Беларуси, обусловленного кризисными явлениями и расколом в движении возрождения. Одновременно негативное влияние на ситуацию оказывает неуклонное сокращение общей численности татарского населения страны. Ситуация, сложившаяся в указанный период в местах компактного проживания татар, свидетельствует о тенденции снижения религиозности татарского населения, что, в свою очередь приводит к утрате национальных традиций и своеобразия, постепенной ассимиляции татар, особенно характерной для наиболее малочисленных татарских общин. Наглядной иллюстрацией данной тенденции могут служить события в мусульманской религиозной общине городского поселка Видзы (Браславский район Витебской области), где осенью 2014 г. прекратил функционировать местный молельный дом, так как в поселке не осталось молящихся мусульман [Мусульманский вестник: 2014. С. 3]. В 2017 г. по сходным причинам прекратила свое существование мусульманская община в г.п. Острино (Щучинский район Гродненской области). Аналогичная ситуация складывается во многих местах компактного проживания татар и региональных мусульманских общинах, часть из которых осталась существовать лишь формально. Так, из 4 религиозных общин (Минск, Гомель, Клецк, Ляховичи), входящих в состав Духовного управления мусульман Республике Беларусь, регулярные религиозные мероприятия проводятся только в 2 (Минск, Гомель), при том что в Ляховичах и Клецке имеются довольно крупные общины татар-мусульман. Из 17 религиозных общин (Минск, Мядель, Клецк, Молодечно, Смиловичи, Узда, Ивье, Новогрудок, Лида, Скидель, Ошмяны, Слоним,

Видзы, Орша, Глубокое, Брест, Могилев) Мусульманского религиозного объединения в Республике Беларусь регулярные богослужения проводятся только в 8–9. Кроме того, религиозная деятельность на постоянной основе осуществляется мусульманской религиозной общиной в Гродно, имеющей автономный статус.

Обращает на себя внимание тот факт, что наибольшая религиозная активность отмечается в общинах крупных городов, в составе которых белорусских татар либо практически нет (Могилев, Гомель), либо они составляют незначительный процент от общего числа верующих (Минск, Гродно, Брест). В то же время, даже в наиболее многочисленных местах компактного проживания татарского населения, таких как Ивье и Новогрудок, количество постоянных посетителей джума-намаза не превышает 10–15% от общего количества татар. Во многих общинах единственной формой участия в религиозной и культурной жизни татарской общности является ежегодное посещение и наведение порядка на мизарах. За указанный период в мусульманских общинах сократилось также число воскресных школ и групп выходного дня по изучению основ ислама. Так, в настоящее время учебные занятия проводятся в 7 общинах (Минск – 2 общины, Могилев, Новогрудок, Ивье, Гомель, Гродно).

Помимо вышеперечисленных обстоятельств, определенную угрозу для культурного своеобразия белорусских татар представляет иностранное религиозное влияние, обусловленное как приглашением для осуществления религиозной деятельности в Беларуси иностранных священнослужителей, так и обучением белорусских мусульман в зарубежных исламских образовательных учреждениях, а также распространением иностранной религиозной литературы и материалов.

Отдельно необходимо отметить тот факт, что сокращение численности татарского населения происходит на фоне увеличения общего числа мусульман, проживающих на территории Республики Беларусь, которое происходит в основном за счет притока мигрантов из арабских стран, Афганистана, Средней Азии и Кавказа, а также отдельных новообращенных мусульман из числа этнических белорусов. Указанная среда является более подверженной распространению радикальной исламистской идеологии, нежели татарская общность, имеющая многовековой опыт толерантности и совместного добрососедского проживания в поликонфессиональном окружении.

Окончание строительства и торжественное открытие в ноябре 2016 г. соборной мечети в Минске с участием президентов Беларуси и Турции знаменует собой начало нового этапа в развитии татарско-мусульманской общности нашей республики. Наметившиеся в указанный период

*Татар халкы борын-борыннан аш-су әзерләргә бик оста булган. Бәйрәм табынына куела торган ризыклар арасында нинди генә камыр ризыклары юк: өчпочмак, кош теле, чәкчәк, гөбәдия һ.б. Бу ризыклардан башка бернинди бәйрәм дә узмыйдыр, мөгаен. Шулар арасыннан татар халкының табын күрке булган милли ризыгыбыз – гөбәдия пешерү ысулын тәкъдим итәбез. Һәркем аны үз рецепты буенча, күңел җылысын салып әзерли.*



***Гөбәдия камыры өчен:*** 1 кап маргарин мае, 3 йомырка, 50 гр чүпрә, бер чеметем тоз, 1 аш кашыгы шикәр комы, кирәгенчә он кушып, йомшак кына камыр басабыз. Аны, пакетка салып, суыткычка күпертергә куябыз.

***Эчлек өчен:*** 1,5 стакан бүрттерелгән дөге, 3 йомырка, 300 гр корт, 200 гр эретелгән ак май, шикәр комы, 200 гр йөзем җимеше.

***Әзерләү ысулы:*** Әзер камырны икегә – берсе зуррак, икенчесе кечерәк кисәккә бүләбез (өстен каплыйсы кисәк кечерәк булырга тиеш). Майланган табага камырның зур кисәген җәябез һәм төбе җебеп йомшармасын өчен аз гына дөге, аның өстенә әзер корт, аннары тагын дөге салабыз. Дөгенең өстенә эре угычтан уылган 3 пешкән йомырка, аннан тагын дөге, соңгы катлам итеп өстенә алдан әзерләп куелган йомшартылган йөзем җимешен сибәбез. Һәр катлам саен аз гына шикәр комы салып калдырырга кирәк. Болай эшләгәндә гөбәдия татлы килеп чыга. Барысы да әзер булгач, эчлеккә эретелгән ак май салабыз. Өстенә кечерәк җәемне каплап, табадагы камыр белән чит-читләрен бөгеп куябыз. Уртача кызулыктагы мичтә 35–40 минут пешерәбез.

Гөбәдия өстенә сибү өчен 2 аш кашыгы онга, бер бал кашыгы шикәр комы яки бал һәм аз гына ак май салып, уалып торган катнашма ясыйбыз һәм гөбәдия өстенә, пешеп чыгарга 5 минут кала, сибәбез.

Гөбәдияне өлешләргә бүлеп, чәй табынына кайнар килеш чыгаралар.

* * *

**Корт**

*Табын күрке гөбәдияне кортсыз күз алдына да китереп булмый. Без сезгә корт әзерләү ысулын тәкъдим итәбез. Әлеге рецепт Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында яшәүче Гөлсинә Гомәр кызы Сәләхиевадан язып алынды.*

***Кирәкле:*** 3 литр сөт (әчегән сөт тә ярый), 1 аш кашыгы уксус, 1 чәй кашыгы сода, 1 йомырка, 1 стакан катык яки кефир, кирәгенчә шикәр комы.

***Әзерләү ысулы.*** Сөтне салыр алдыннан казанның эчен майлыйбыз һәм 3 литр сөтне салып җылытабыз. 1 аш кашыгы уксус, 1 чәй кашыгы сода, 1 йомырка, 1 стакан катыкны бергә кушып, яхшылап болгатабыз да, сөткә акрын гына салабыз. Кабат болгатып, көчле утта кайнатып чыгарабыз. Кайнап чыккач, сүрән утта 2–2,5 сәгать тотабыз. Корт кызара башлагач, кирәгенчә шикәр комы өстибез. Болай әзерләнгән корт бик йомшак килеп чыга. Әзер кортны сөзгечкә салабыз һәм шулай берничә сәгать тотып, сыркытабыз. Аннары савытларга тутырып, суыткычка куябыз. Ваграк корт кирәк булса, аны иттарткычтан да чыгарырга мөмкин.

*Дания Фәйзуллина*

* * *

**Домашнее печенье.**

***Необходимо:***

Сахар – 1/4 стакана;

Масло сливочное – 200 гр;

Сода, гашенная уксусом – 0,5 ч.л.;

Яйцо – 1 шт.;

Молоко – ¼ стакана;

Мука – сколько войдёт.

***Способ приготовления:***

Замесить тесто. Оно должно быть мягким и 1–2 часа подержать в холодильнике. Тесто из холодильника вынимаешь и разделываешь на печенье. Можно украсить изюмом или маком.

Выпекать до золотистого цвета.

*Гульнафис Валеева*

## Юбилярлар турында сүз

## Слово о юбилярах

# МӘҮЛИЗӘ ГОМӘРОВА: БӘХЕТЛЕЛӘРНЕҢ БӘЙРӘМЕ КҮБРӘК БУЛА

***60 яшьлек юбилее уңаеннан***



*Бу дөньяга кеше туа, яши, уңышларга ирешә. Гомер юлын узганда адаша, абына, изгелекләр кыла. Су үз юлын тапкан кебек, кеше дә бу тормышта үзен таба. Бүгенге әңгәмәдәшебез – Бөтендөнья татар конгрессы халыкара Берлеге медале иясе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәкәре Мәүлизә Гомәрова.*

*Гомәрова Мәүлизә Шәрифулла кызы Бәрәңге районы Мазарбашы авылында 4-нче бала булып дөньяга килә. Әтисе Шәрифулла – Арча районы Әзәк авылыннан, әнисе – Бәрәңге районы Мазарбашы авылыннан. Бик музыкаль гаилә, әтисе өздереп тальянда уйнап, әнисе бик матур итеп җырлый. Элегрәк авылда бу гаиләсез бер кунак та узмаган. Мәүлизә Куян авылы урта мәктәбен тәмамлый. Аннан һөнәри училищеда тегүче һөнәрен үзләштерә. Шулай да өйдә гармун, җыр тавышы аңа тәэсир итми калмый. Колхоз рәисе Нурислам Фатыхов киңәше буенча мәдәният өлкәсенә кереп китә. Мәдәният колледжында укый, соңрак Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлый. 1993 елдан – Мари Республи-*

*касы Мәдәният министрлыгында милләтара дуслыкны ныгыту буенча белгеч. Шул елларда чит төбәкләрдә 10 мари милли мәдәният үзәге ача. Мари Республикасының Мари-Төрек районында удмурт мәдәни үзәге, татар мәдәният үзәген ачканда үзеннән зур өлеш кертә. Звенигово районында ике чуваш «йорты» ача. 1997 елда татар мәдәнияте үзәген ачкач, директор, аннан директор урынбасары булып хезмәт куя. Соңрак, Йошкар-Ола шәһәре хакимиятендә яшьләр бүлегендә эшли, шуннан лаеклы ялга китә. Республикада бердәнбер «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булган райондашыбыз ул безнең. Ә менә татар яшьләрен югары дәрәҗәгә күтәрү, республика тарихында беренче тапкыр 1993 елдан – 1999 елга кадәр республика тарихында беренчеләрдән булып татар җыры бәйгесен уздыру, җиңүчеләрне Казан шәһәренә, Халыкара җыр бәйгесендә катнаштыру, 1994 елда, беренче «Болгар» җыр һәм бию ансамбле оештыру, Республика күләмендә ел саен «Рамазан» җыр һәм бию фестивальләре уздыру, балалар өчен «Ягымлы яз» җыр һәм бию бәйгесе, төрле фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр уздыру, милли бәйрәмебез Сабантуйларны оештыру, алып бару, болар – аның эшчәнлегенең бер өлеше генә.*

*Мәдәният министры кушуы буенча, Мәүлизә ханым 1993 елда Мари дәүләт телерадикомпаниесенә эшкә килә. 1993 елдан «Туган тел» тапшыруы, 1999 елда «Бүләккә – җыр тапшыруы», 2000 елдан Мари радиосында «Туган як» информацион-музыкаль тапшыру, Йошкар-Ола шәһәр хакимиятендә эшләгәндә, 2001 елдан мари, рус, татар телләрендә «Бергә, Пырля, Вместе» тапшыруларын алып бару, болар барысы да – аның хезмәт җимеше. Менә шушы чорда салынган ныклы нигездә республикада татар мәдәнияте бүген чәчәк ата. Аның булышлыгы белән күп кенә җырчыларыбыз бу тормышта үз юлларын тапты һәм инде бүгенге көндә халкыбызга матур гына хезмәт итә (Дилә, Булат Нигъмәтуллинар, Ришат Фазлыйәхмәтов, Кәрим Тинчурин театрында эшләгән хәзер мәрхүм актер Фәрит Нигъмәтуллин һ.б.).*

*Әйе, кеше язмышы бер бит ак кәгазьгә сыеп бетә. Аның артында, никадәр уйланулар, йокысыз төннәр, кешеләрнең битарафлыгы, каршылыклар җыйналган. Мәүлизә Йошкар-Ола шәһәр хакимиятенә эшкә күчкәч тә милләтен ташламый, республикадагы талантлы яшьләрне җыеп, Татарстан артистлары белән берлектә «Кар кызында кунакта» исемле маҗаралы концертлар оештыра, татар яшьләре форумнары, шәһәрнең 10 техникумда, 3 югары уку йортында, мари, рус, татар мәдәният үзегендә яшьләр арасында эшмәкәрлек буенча клублар ача. Студентлар арасында «Успешный старт» исемле бизнес-план яклый торган бәй-*

*геләр, семинарлар, төрле очрашулар уздыра. Ул – республикадагы барлык эшмәкәрләрне дә үзе янына җыя да һәрбер клубка җаваплы итеп беркетә. Мәскәү шәһәреннән бизнес-тренерлар чакыртып, атналар буе яшьләрне үз эшен ачу серләренә төшендерә. 2010–2014 елда укыган студентлар арасында 38 кеше үз эшен ача. Алар арасында татар балалары да бар.*

*2004 елны милли бәйрәмебез – Федераль Сабантуйны уздыру да аның җилкәсендә була.*

*2010 елдан ул эшләгән яшьләр арасында шәһәркүләм Совет төзи. Советка Йошкар-Ола шәһәре җирлегендә урнашкан зур оешмалар керә (ОАО «ММЗ», ОАО «Контакт», ОАО «ЗПП», ОАО «Фармбиомаш», ОАО «Марбиофарм», МУП «ТЭЦ-1», Управление Федерального Казначейства по РМЭ, Сбербанк России, ООО «Марийскгаз», МП «Троллейбусный транспорт»). Эшләгән яшьләр белән ул форумнар, очрашулар, «түгәрәк өстәл»ләр, ел саен «Муравейник» дигән җыр һәм бию фестивале оештыра.*

*Мәүлизә ханым төп эшендә эшләп, параллель рәвештә 25 ел буе Мари дәүләт телерадиокомпаниесендә тапшырулар алып бара. Шигырьләр яза. Аның шигырьләренә Мари Республикасының атказанган артисты Станислав Шакиров көй яза һәм аларны татар телендә башкара. Мәүлизәнең җырлары, танылган җырчыбыз Айдар Галимовның җыр репертуарында да бар. Ул мари, рус кызларын татар телендә җырларга өйрәтә һәм үзе уздырган чараларда бик теләп катнаштыра.*

*1993 елда Мәдәният министрлыгында эшләгәндә Морки районыннан «Яшьлек» вокаль инструменталь ансамбле халкыбыз арасында беренчеләрдән булып «халык» исеменә лаек була. 1995 елда «Ялкын» вокаль инстурменталь ансамбле «халык» исемен яулый. Ә соңрак Бәрәңге районыннан «Альянс» төркеме дә ала ул исемне.*

***– Тормыш юлыгыз кызык һәм бай эчтәлекле икән, Мәүлизә ханым. Бүген башкарган эшләрегез белән дә таныштырып китмәссезме?***

– Бүгенге көндә мин яраткан эшем белән шөгыльләнәм. 25 ел буе ике эштә эшләп, лаеклы ялда булсам да, 15 елдан артык дәвам иткән проект өстендә эшлим. Бу – минем өчен бик кадерле проект, ягъни республикада урнашкан чиста татар авылларының казанышларын яздырып, республика тарихына кертеп калдыру. Үзенә күрә ул бик күп көч, тырышлык таләп итә. Бу эш белән шөгыльләнгәндә искитмәле бөек кешеләр чыккан авылларга тап булдым. Мәсәлән, Морки районы Октябрьский поселогын алыйк. Анда Япониядәге Саппоро (1972 ел) шәһәрендә узган Олимпиадада катнашып, олимпиада чемпионы булган якташыбыз Ринат Сафинның сеңлесе белән аралаштым. Ринат Сафин бүгенге көндә Пе-

тербург шәһәрендә гомер кичерә. Шунда ук Бөек Ватан сугышы вакытында куылып килгән кырым татарлары, пленга төшеп, эшкә җибәрелгән немецлар урнашкан һәм төзеген ике катлы баракларга тап булдым. Ул баракларның стеналары сөйләшә алса, безгә нәрсә сөйләрләр иде икән? Татарстаннан күчеп килгән милләттәшләребез белән аралашырга туры килде. Кызганыч, алар инде мәрхүмнәр. Республикада урнашкан һәрбер татар авылының тарихы бик бай, матур эз калдырган милләттәшләребез бик күп. Беләсезме, кайбер тапшыру геройлары шулай матур, мавыктыргыч итеп үзенең гаиләсе, туганнары, авылы турында сөйли, авызыңны ачып, хисләнеп, тыңлап утырасың. Минем күңелемдә безнең милләт өчен шулкадәр горурлык хисе уяна. Бу – әйтеп бетергесез халәт. Аны аңлатып бетерә торган түгел, шаһиты булырга кирәк. Аллага шөкер, бүгенге көндә Морки, Мари-Төрек районындагы татар авылларының тарихлары язылып бетте, Бәрәңге поселогы турында яздыру өчен эзләнү эшләре алып барыла. Республикадагы татар авылларының тарихы язылып бетә, дигән сүз. Рәхмәтемнең иң олысын тарихчыларга әйтәсем килә. Алар – Фәнил Мусин, Наил Бариев, Рафис Гайнанов, инде мәрхүм Рафаиз Гайнанов, бөртекләп җыеп, барысын туплап, тамашачыларга җиткерергә әзерләр. Республикада татарлар гына яшәгән барлыгы 50 авыл булган. Кызганыч, бүгенге көндә 18 татар авылы инде бетеп, юкка чыккан. Үткән белән хәзерге көнгә күпер бар. Ул – хәтер дип атала. Шул хәтер, халкыбызның һәрбер кешесендә матур хатирәләр тудырсын иде. Тарихыбызны онытмасак иде.

– ***Сез күп еллар Йошкар-Ола шәһәре хакимиятендә шәһәр яшьләре белән күп эшләдегез. Элеккеге һәм хәзерге яшьләр арасында аерма бармы?***

– Аерма бик зур. Без үскән чорда яшьләр бик мөстәкыйль иде. Мәктәпне бетергәнче кая укырга керәсен, нинди һөнәр алып чыгасын алар үзләренә максат итеп куя иде. Хәзерге яшьләр күп очракта үз язмышларына битараф, дип, әйтимме? Китереп биргәнне көтеп утыручылар да бар. Һөнәр сайлаганда да, тормыш корганда да. Юкка гына безнең республикада татар яшьләре арасында катнаш никахлар 45%тан югары түгел. Башка милләт белән чагыштырганда, бу иң югары күрсәткеч. Икенче яктан, бик талантлы яшьләребез бар, аларга бераз ярдәм кирәк. 25–30 ел эчендә дөньяның асты-өскә килде бит. Замана бик үзгәрде, аның белән без дә үзгәрдек. Әтиемнең, мине шәһәргә озатканда әйткән сүзләре бүген дә ядкяр булып, йөрәк түрендә ята. «Кызым, укырга китәсең, яхшы укы, син үзең йөрткән фамилиягә кызыллык китермә!» Бу сүзләрдә тирән мәгънә ята. Ул әби-бабайларның рухы сарылган матур исем белән әйтелә торган татар фамилиясе – син бик каты яраткан бабаеңның исеме. Икенче

яктан, алар өй түрләрендә кияү, килен итеп, акыллы, мили гореф-гадәтләр белән тәрбияләнгән кияү, кәләшне күрәселәре килгән. Барлык милләт халкын хөрмәт итәм мин, шулай да гаилә корганда бүгенге татар яшьләре бик игътибарлы булсалар иде. Монда инде начар язмыш белән туу куркыныч түгел, ә начар исем алу куркыныч. Яшерен түгел, Йошкар-Ола шәһәре хакимиятендә эшләгәндә 10 елдан артык яшүсмерләр комиссиясе әгъзасы булырга туры килде. Күп очракта тәртип бозучы яшүсмерләр катнаш никахтан туган балалар иде. Үз көең, үз җөең, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Киленең яисә киявең белән кара-каршы утырып, үз телеңдә татарча сөйләшеп, чәй эчү дә – зур бәхет ул. Һәрбер кеше үз милләте эчендә үз бәхетен, парын табып, бәхетле булсын иде, дигән теләктә мин.




*Мари Иле буйлап татар авылларын барлап...*

– ***Тормыш булгач, төрлесе була, күңелсез вакыйгалар да булмыйча калмагандыр****?*

– Тормыш юлымда андый вакыйгалар, әйтеп бетергесез! Мари Мәдәният министрлыгында милләтара дуслыкны ныгыту буенча белгеч булып эшләгән чор. Мин мари халык ансамблен алып Свердлау өлкәсе, Красноуфим районы Большая Тавра дигән авылга Өлкәкүләм Мари милли мәдәни үзәк ачырга киттем. 10 көн йөреп, мари милли мәдәни үзәкне ачып, очрашулар уздырып, республикага кайтып төштек. Шуннан башыма, бездә дә ачып була ич мондый үзәкне, дигән уй килеп, куанып, үземнең уйларымны туплап, өлкә профсоюз җитәкчесе булып эшләгән Сафин Равил Хөснетдин улы янына киттем. Мине бүлдермичә генә тыңлады да: «Слушай, националист булып йөрмә, үз эшеңне эшлә», – дип, мине чыгарып җибәрде.

Әлбәттә, мин күз яшьләремә тыгылып кайтып киттем. Бер атна узгач, бу мине чакырып китерде. Күрәсең, минем сүзләрдән соң ул да уйлангандыр. Мин кабат бар нәрсәне сөйләп бирдем. Ул чорда президентка кандидат Вячеслав Александрович Кислицынның сайлау кампаниесенә кереп киткән чорым. «Равил абый, сайлау кампаниесе бара, шунда кушылыйк, бәлкем, минем хыялымны тормышка ашырып булыр», – дим. Шулай итеп без бергә эшли башладык. Төнге 11дә президентка кандидат В. Кислицын янына кердек. Мин барысын да сөйләп бирдем. Шунда Кислицын: «Мин җиңеп чыксам, бу мәдәни үзәкне ачабыз», – дип сүз бирде. Мари Дәүләт телерадикомпаниесендә мин татар телендә мөрәҗәгать яздырдым, концерт программасы булдырып, үземнең Йошкар-Ола шәһәрендә төзегән «Болгар» җыр һәм бию коллективы белән чыгышлар ясап, Кислицын кандидатурасын күрсәтеп, республика буенча 17 концерт куйдык. Сайлауларда В. Кислицын җиңеп чыкты. 10 көн узгач, мин моның янына кердем. «Все остается в силе, открываем Центр татарской культуры», – диде. Ул чорда минем кул астында республикадагы барлык мәдәният оешмаларының уставлары иде. Мин инде шул уставларны карап, ачыла торган мәдәни үзәкнең уставын эшләп куйган идем. Бинасын эзләп таптым. Президент миңа булышчы итеп, ул чорда дәүләт секретаре булып эшләгән Н.Н. Гавриловны беркетте. Без бергә уставларны теркәдек. Шулай итеп, Республикада беренчеләрдән булып, Мәдәният министрлыгыннан финанслана торган итеп, 19,5 штат белән, аерым бинада Республиканың татар мәдәният үзәге ачылды. Никадәр йокысыз төннәр, мәшәкатьле көннәр, таяк тыгулар булды. Барысына да түздек, Аллага шөкер. Равил абый һәр адымымны барлап, башкарган эшләремне хуплап торды. Үзе инде мәрхүм. Урыны оҗмахта булсын! Мин аңа бик рәхмәтлемен.

Тагын йөрәгем аша узган бер вакыйганы исемә төшереп үтәсем килә. 2004 ел. Мин Йошкар-Ола шәһәре хакимиятендә яшьләр бүлегендә эшлим. Шәһәрнең мэры булып В.В. Тарков эшли. Мине үзенә чакырып кертте дә, менә безгә Федераль Сабантуй уздырырга кирәк, ди. Эшкә жигелеп кереп киттем. Һәрбер регионнардан килгән кунакларны кайда ашатырга, нинди бүләкләр алырга, нинди коллективларны чакырырга, тагын бик күп эш минем өскә өелде. Ул вакытта Мари Элның Президенты – Леонид Маркелов иде. Ә аларның мэр белән бөтенләй дә дуслыклары булмады. Президент исә Сабантуйны уздырырга каршы төшеп килде. Шул чорда Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләре килеп, Президент белән сөйләшүләр уздырып карады. Мин ике ут арасында, мэр кабинетыннан чыкмадым, диярлек. Шәһәр хакимиятендә, идән юучыга кадәр, татарның Федераль Сабан туен уздыру өчен әзерлек эшләре алып бара. Минем өчен бу бик авыр чор булды. Президент карары белән Сабантуй-

га шәһәрдәге оешмалар катнашырга тиеш түгел иде. Бәрәңге районының райпосы аркылы кибетләр китердек, шәһәр карамагында эшләгән барлык жыр-бию коллективларын оештырдык. Төнге сәгать 12гә кадәр Сабантуй мәйданын ачып җибәрер өчен атлар эзләү, дисеңме, телефон аркылы янаулар, дисеңме, фатир ишегемә, «Аллаһу әкбәр», дип язып китүләрме, Сабантуй барышында уен уздыра торган реквизитлар – чиләк, көянтә, аркан юкка чыга. Болар барысы да кеше башына сыя алмый торган әйберләр. Шул конне Л. Маркелов кич сәгать 5тә Рус театры бинасында туган көнен дә уздырды бит әле. Әлбәттә, бөтен татар җитәкчеләре шунда катнашырга тиеш иделәр. Аларның барысын да куркытып бетергәннәр иде. Рус егете, шәһәр мэры оештырган Сабантуйны бер татар җитәкчесе дә хупламады. Бу бик кызганыч һәм аяныч хәл булды. Сабантуйны бетереп, Сабантуйның эмблемасы – Тулпар атны – Чиләбе өлкәсенә тапшыруга чират житкәч, атыбыз югалды. Мат астыннан эзләп табып, Тулпар атны тапшырдык. Сабантуй бетте, өемә кайтып егылдым. Мэр стадион эчендә кочып, рәхмәт әйтеп, 3 көн ял бирде. Эшкә чыккач, үзенә чакырып кертте. Чәй өстәле артына утыргач: «Мин, Мәүлизә, татарлардан мондый хәлне көтмәгән идем», – диде. Минем шул мәлне йөрәкләрем өзгәләнде. Татар җитәкчеләренең минем өчен бәяләре бер тиенгә төште. Монда инде, ул чорларда беренчеләрдән булып оештырылган шәһәркүләм автономия җитәкчесе Вафин Рамил Каюм улына (Сабантуй уздыру эмблемасын шул алып кайтты), аның абыйсы Вафин Наил Каюм улына (Бәрәңге районында райпо председателе) рәхмәт әйтер идем. Егетләр бик тырыштылар.

Андый хәлләр минем тормышымда бик күп булды. Сатулар, нахак сүзләр, таяк тыгулар. Вакыты житкәч, Аллаһы Тәгалә барысын да үз түгәрәгенә кайтара икән. Бүгенге көндә, республика күләмендә дәүләт, шәһәр Собраниеләрендә бер татар кешесе дә юк. Менә инде бу татарның индикатор кебек республикада нинди урын алып торганын билгели. Бер кешене дә гаепләргә теләмим, болар инде тарих, шулай да мин узган гомер юлы татар милләтенә бик яхшы сабак булсын иде! Киләчәктә берләшеп, татар дәрәҗәсен күтәрү өстендә нык тырышып эшләргә кирәк булачак. Барлык тармакларда да татарның кадрларын әзерләү өстендә эш алып бару кирәк.

***– Сез гомер буе халык арасында эшлисез, бәндәләрнең телләре тигәнәкле. Гайбәтләргә, яман сүзләргә игътибар итәсезме?***

– Беләсезме, яшь вакытта ялган, шакшы, нахак сүзләргә хатерем калып, күз яшенә тыгыла идем. Бүгенге көндә гайбәтнең әйбәтен генә ишетергә колак күнеккән. Үз хаталарын күргән кешенең, башкаларны тикшерергә вакыты калмый. Аннан усал кеше тиз картая, дигән әйтем бар. Шуңа күрә андый сүзләр мине куркытмый. Омар Хәйямнең бер әйтеме бар: «Чем ниже человек душой, тем выше задирает нос. Он носом тянет-

ся туда, куда душою не дорос». Миндә гайбәт таратучылар кызгану хисе генә уята. Һәрбер кеше бу дөньяда җылылык көтә. Ә кайберәүләр, бик күп кеше дип әйтер идем, гаилә җылысын тоймыйча, туңып та яшәргә мөмкин. Мәсәлән, байларның бар нәрсәсе дә бар. Ә бармы икән аларда күңел җылысы? Шуңа күрә кайда гына кем булып, кемнәр белән генә эшләмә, бу тормышта иң беренче гади кеше булып калырга кирәк, минемчә.

– ***Сез үзегезне бәхетле дип саныйсызмы?***

– Бәхет дигән төшенчә күпкырлы ул. Миңа килгәндә, әйе, мин үземне бик бәхетле, дип әйтә алам. Чөнки 55 ел әти-әниемнең канаты астында яшәдем. Алар булганда синең дөньяң түгәрәк, син бик бәхетле. Минем өчен алар тормыш маягы, сөртенеп егылганда ярдәм кулы сузучы, авыр чакларда, өзгәләнеп, ярдәмгә килүче, матур киңәшләре белән юл күрсәтүче фәрештәләрем иде. 52 яшенә кадәр укып һәм инде 25 ел буе ике эштә эшләп, халкыма хезмәт иттем. Бүгенге көндә милләтемә эшләгән эшләрем өчен бик горурланам. Кешегә кирәк булмасаң, син иң бәхетсез кеше! Кошның  матурлыгы төсенә карап, кешенең матурлыгы эшенә карап билгеләнә бит!

– ***Инде үзегезнең гаилә турында әйтеп китсәгез иде?***

– Минем бүгенге көндә улым бар. 5 оныгым үсеп килә. Алар шәһәрдә яшәсәләр дә, авылга кунакка еш кайталар. Авылны бик яраталар. Әлбәттә, тырыша-тырыша татарча сөйләшергә өйрәнәбез. Элек балаларны авылга татарча сөйләшергә өйрәнеп килсен, дип кайтарсалар, хәзер оныклар әбиләрне рус телендә сөйләшергә өйрәтеп китә. Бу бик кызганыч. Авыл урамнарында русча сөйләшүләр еш ишетелә. Йөрәк әрни. Мәктәпләрдә дә күбрәк рус телендә аралашалар. Кайтарасы иде дә бит без укыган мәктәп елларын! Замана бик тиз үзгәрә шул...

Озакламый 60 яшьне түгәрәклим. Күп кенә эшләр башкарылган. Гаиләдә балалар үсеп, үз юлларын табып, оныклары үскән вакыт. Бу – бик бәхетле минутлар, дип әйтер идем. Әлбәттә, ниндидер эшләргә нәтиҗә ясар вакыт та ул. Узган гомерне барлап, киләчәккә зур өметләр белән яши торган тормыш. Матур мизгелләр әле алда булсын!

– ***Татар халкына җиткерер нинди теләкләрегез бар?***

– Беләсезме, иң беренче мине бу якты дөньяга тудырган, юл күрсәткән әти-әниемә зур рәхмәтле мин. Аннан миңа белем биргән укытучыларыма, остазларыма зур рәхмәтләр әйтәсем килә. Минем туган авылымда колхоз рәисе булып эшләгән Фатыхов Нурислам абыйга, Сафин Әүлияр абыйга, Габдуллин Шамил абыйга. Алар миңа ышандылар, мин аларның ышанычларын акларга тырыштым. Шәһәргә киткәч, инде иң беренче остазларым: мәрхүмнәр Сафин Равил Хөснетдинович, Сабирьянов Рафис

Ясауевич. Шулай ук Фәйзиев Нурфис Каюмович, Нурмөхәмәтов Мансур Галимулловичка рәхмәтләрем чиксез. Аннан соң Татарстан Республикасы хөкүмәтенә, Бөтендөнья татар конгрессына, 1995 елларда ТР мәдәният министры булып эшләгән Марсель Мазгарович Таишевка, академик Индус абый Таһировка, Тәэминә апа Биктимировага, бөек җырчыбыз Илһам абый Шакировка. Алар гомерләре буе халыкка хезмәт иттеләр һәм инде миңа акыллы киңәшләрен биреп тордылар. Шундый изге җанлы кешеләр белән очраштырганга язмышыма рәхмәтлемен һәм инде мин бу яктан үземне бик бәхетле дип саныйм. Минем остазларым бар, булды һәм, Алла бирсә, булачак, дип уйлыйм.

Тормыш матур булса да, катлаулы. Бер мәшәкать бетми, икенчесе өстәлә. Минемчә, һәрбер татар кешесе үзенең халкына хезмәт итеп, матур эз калдырырга тиеш.

Без бик затлы, укымышлы, тарихы бай булган халык. Горурланып яшәргә хакыбыз бар, Аллага шөкер. Күп талантлар, бөек кешеләребез, акыл ияләре, күбесе тумышлары белән авылдан. Авыл – милләтнең сакчысы. Авылда гына без үзебезне бик бәхетле, бай мираслы халык итеп тоеп күрсәтә алабыз. Авыл җирләре әби-бабайларыбызның, әти-әниебезнең, кендек каны тамган бөек җире. Тир түгеп басуларын эшкәрткән, тургай сайраган болыннарында йөргән җир. Иртәгәге көнгә зур өметләр белән караган урыннар.

Шуңа күрә дә, һәрбер кешенең җанына якын туган авылларыбызны бетерергә хакыбыз юк! Мирас булып калган авылны торгызу – ул һәркайсыбызның изге бурычы. Күп җирләрдә авылга күченеп кайтулар күзәтелә. Безнең дә авылларда эш урыннары булса, яшьләр кайтыр иде. Алла бирсә, авыл урамнары кабат бала-чага тавышлары белән тулыр. Татар халкы үз кыйбласын югалтмасын иде. Кеше күпкырлы, кызык, мәхәббәтле. Һәр кеше сабыр булып калсын иде, дигән теләктә мин.

**– *Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Сезгә тазалык, уңышлар телим.***

– Сезгә дә рәхмәт. Бик зур һәм кирәкле, җаваплы эш белән шөгыльләнәсез. Уңышлар Сезгә! Иҗат чишмәгез саекмасын! Һәм инде бу җирдә барыбыз да сау-сәламәт, бәхетле булыйк. Бәхетлеләрнең бәйрәме күбрәк була!

*Әңгәмәдәш – Фәнил Мусин*

## ЛЕГЕНДА СИБИРСКИХ ТАТАР



15 апреля исполнилось 80 лет замечательному человеку, патриоту, лидеру и легенде татарского национального движения Яхиной Розе Набиевне.

Р.Н. Яхина (Бариева) родилась в 1942 г. в д. Кайсы Усть-Ишимского района Омской области. По окончании Тебендинской школы она работала в колхозе им. В.И. Ленина в д. Кайсы. В 1960 г. она вместе с семьей переехала во Владивосток, где работала маляром в Стройуправлении. А в 1962 г. семья Бариевых вернулась на родину и поселилась в с. Абаул. С 1964 г. работала директором сельского Дома культуры в с. Тебендя, 7 лет была секретарем комсомольской организации, депутатом сельсовета. После окончания вечерней средней школы с 1967 по 1972 гг. училась в Омском культпросветучилище. В дальнейшем проходила курсы повышения квалификации в Омске и Новосибирске.

В 1968 г. Роза Набиевна была избрана председателем Большетебендинского сельского совета. На всех занимаемых должностях и постах она проявляла себя как ответственный, инициативный работник. Была награждена почетными грамотами Омского обкома КПСС (1968), Усть-Ишимского Исполкома райсовета КПСС (1967), отдела культуры с. Усть-Ишим (1967–1974) и т.д. Активная, жизнерадостная, принципиальная и очень красивая Роза Яхина была центром всеобщего притяжения.

В 1970 г. по семейным обстоятельствам Роза Набиевна переехала в Малую Бичу – взяла на воспитание в свою семью 5 сирот от 2 до 15 лет в связи со смертью жены брата. В пос. Малая Бича она стала работать директором в клубе. Здесь она создала женский и мужской ансамбли, насчитывавшие до 50 человек. Эти ансамбли с концертами объездили всю

Омскую область, где пользовались большой популярностью. Остается только удивляться, как она все успевала!

В 1990 г. Роза Набиевна создала ансамбль «Чишмә», с которым ездила с концертами в Омск и по населенным пунктам Омской области. В 1991 г. ансамбль с таким же названием создала в Усть-Ишиме, также пользовавшийся большой популярностью среди населения области. Ездили с концертами в Тару и Омск, принимали участие в международных марафонах.

В татарское общественное движение Роза Набиевна включилась с его первых дней в конце 1980-х гг. При её активном участии в Омской области был создан Комитет Возрождения сибирских татар Усть-Ишимского района, ставший филиалом Комитета Тюменской области. Основными целями организации были «возрождение языка и культуры, изучение истории и этнографии сибирских татар». Р.Н. Яхина принимала самое активное участие в общественных мероприятиях, часто ездила в Казань, общалась с лидерами ТОЦ, в т. ч. с его первым президентом, народным депутатом Татарстана Маратом Мулюковым, выходцем из сибирских татар.

В июне 1990 г. вместе с другими сибирско-татарскими лидерами – Булатом Сулеймановым и Анасом Гаитовым, принимала участие в научно-практической конференции «Сибирские татары: история и современность». 14–15 декабря 1990 г. в Тюмени состоялся Первый (учредительный) съезд Ассоциации татар Тюменской области, созданный в противовес ранее организованного Б.В. Сулеймановым Комитета Возрождения Тюменской области. На этом съезде остро обозначились требования сибирских татар о признании их самостоятельным народом и необходимости решения вопроса о национально-территориальной автономии сибирских татар.

В 1991 г. Р.Н. Яхина вместе с Р.М. Насибуллиным и А.Г. Гаитовым поехала в Москву в Верховный Совет СССР защищать интересы сибирских татар, куда они повезли письмо о признании их самостоятельности. В Верховном Совете они общались с Председателем Совета национальностей Верховного Совета Б. Олейником, познакомились с М. Мулюковым, В. Жириновским. На следующий день пошли на киностудию «Мосфильм», где снимался фильм «Ермак», общались с режиссерами и потребовали достоверного отражения в фильме исторических событий.

В 1991 г. Роза Набиевна переехала в Тобольск и начала работать в Центре сибирско-татарской культуры сначала методистом, затем лаборантом историко-этнографического музея.

Еще одна важная страница жизни Розы Набиевны связана с возрождением исламских традиций в Сибири. Сама она из рода шейхов, принесших из Средней Азии в Сибирь ислам, Р.Н. Яхина принимала активное

участие в работе научной конференции, посвященной 600-летию принятия ислама в Сибири в апреле 1995 г. Вместе с Абдельмачит-хазратом Алеевым принимала участие в открытии в с. Ембаево медресе. Одним из первых шакирдов медресе был ее старший сын Рустам.

Роза Набиевна всегда принимает активное участие во всех национальных общественных процессах и старается поддерживать родную культуру, язык, традиции. Вместе с соратниками участвует во всех культурных мероприятиях (научные конференции, встречи, фестивали и т.д.).

С 2007 г. по сегодняшний день Роза Набиевна является руководителем ансамбля ветеранов-педагогов «Яшьлеккә сәяхәт». С концертами эта известная группа объездила многие населенные пункты Тюменской области.

За большой вклад в дело сохранения и развития языка, культуры и обычаев сибирских татар Р.Н. Яхина награждена почетными грамотами Центра сибирско-татарской культуры Тобольска, Национально-культурной автономии татар Тобольска, Национально-культурной автономии татар Тюменской области, Конгресса татар Тюменской области, благодарственными письмами Всемирного конгресса татар, грамотой Комитета по делам национальностей Тюменской области, медалью Всемирного конгресса татар.

Обладательница великолепного голоса, Роза Набиевна – многократный лауреат Международного фестиваля историко-культурного наследия «Искер-джиен», областного татарского фестиваля «Түгәрәк уен», Международного фестиваля «Көзге Иртеш моңнары», V Всероссийского фестиваля «Түгәрәк уен» (Самара, 2012) и др. В 2012 г. Р.Н. Яхина стала обладателем премии Конгресса татар Тюменской области им. Б.В. Сулейманова.

Роза Набиевна – человек с активной жизненной позицией. В настоящее время она – член Совета НКА сибирских татар Тобольска и ведет большую общественную работу. Всю свою жизнь она служит своему народу. Глядя на неё, не верится, что ей – 80 лет. Она молода душой, полна сил и энергии, впереди у неё – множество планов, которые предстоит осуществить.

Мы желаем нашей любимой Розе Набиевне крепкого здоровья, неутомимости, благополучия, оставаться таким же центром притяжения, каким она всегда является.

*Зайтуна Тычинских*

* * *

Редакция журнала присоединяется к поздравлению и желает Розе ханум крепкого здоровья, духовного спокойствия и благополучия. Да ниспошлет ей Аллах долгих лет жизни!

## Авторлар буенча белешмә

## Сведения об авторах

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**Бекиров Надир Валериан улы**, фәлсәфә фәннәре кандидаты.

**Вәлиев Римзил Салих улы**, журналист, БТК Башкарма комитетының «Дөнья» студиясе баш мөхәррире.

**Вәлиева Гөлнәфис Айрат кызы**, алып баручы, җырчы, Халыкара конкурслар лауреаты.

**Габбасова Рәмзия Илдус кызы**, Удмуртия Республикасы татарларының төбәк милли-мәдәни мохтарияте идарәсе рәисе, «Яңарыш» газетасының баш мөхәррире, Удмуртия Республикасы Башлыгы каршындагы милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет әгъзасы.

**Гайсаров Фәнүр Шәрифулла улы**, Оренбург өлкәсе татарларының «Яңа вакыт» газетасы баш мөхәррире.

**Галәүтдинов Идеал Муса улы**, татар милли хәрәкәте активисты, «Дуслык» Самара төбәк иҗтимагый оешмасы президенты киңәшчесе, журналист, китаплар авторы, отставкадагы полковник.

**Гарифуллин Илнар Зөлфәт улы**, тарих фәннәре кандидаты, политолог, «Туган җир. Родной край» журналының web-редакторы.

**Гатауллин Ринат Фәйзлтдин улы**, икътисад фәннәре докторы, РФА ӨФҮ СЭТИ.

**Закиров Ринат Зиннур улы**, БТК киңәшчесе, 2002–2020 елларда конгрессның Башкарма комитеты рәисе, тарих фәннәре докторы.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журналның баш мөхәррире.

**Канапацкая Зорина Ибраһим кызы**, тарих фәннәре кандидаты, М. Танк ис. Беларусь дәүләт педагогия университеты доценты, Минск.

**Кутеева Ленара Раиф кызы**, БТК Башкарма комитетының якын һәм чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге җитәкчесе.

**Минастинова Айгөл Ильяз кызы**, «Татар-Дуслык» Самара татарлары яңалыклары сайтының баш мөхәррире.

**Миннемуллин Илсур Гафиулла улы**, Удмуртия Республикасының Татар иҗтимагый үзәге рәисе.

**Мусин Фәнил Зөлкәфир улы**, Бәрәңге районы «Безнең тормыш» газетасының баш мөхәррире, «Якташлар» газетасын нәшер итүче, Мари Эл

Республикасының Татар тарихчылары җәмгыяте Советы рәисе, Бәрәңге районы тарихчы-архивчылар җәмгыяте рәисе.

**Мохтасаров Фәрит Шамил улы**, Мәскәү өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Назин Сәлим Нәҗип улы**, Пермь крае татарлары милли-мәдәни мохтарияте рәисе урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Пермь краендагы вәкиле.

**Рәшитов Фрид Айни улы**, тарих фәннәре докторы, профессор.

**Сайганова Розалия Мәгәрип кызы**, «Татар дөньясы» газетасы редколлегия әгъзасы, «Ибирь» Омск җирле татар милли-мәдәни мохтарияте Советы әгъзасы.

**Таһиров Индус Ризак улы**, тарих фәннәре докторы, профессор, ТФА академигы, ТР атказанган фән эшлеклесе, җәмәгать эшлеклесе, 1992–2002 елларда БТК Башкарма комитеты рәисе.

**Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы**, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБның Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

**Фәйзуллина Дания Илдус кызы**, журналның корректоры, ТРның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре.

**Шакиров Әмир Тәлгать улы**, «Мари Эл республикасы татарларының төбәк милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасы Советы рәисе.

**Шамилуглы Юлай**, Назарбаев университеты (Казакъстан) һәм Висконсин-Мэдисон университеты (АКШ) профессоры.

* * *

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель.

**Бекиров Надир Валерианович**, кандидат философских наук.

**Валеев Римзиль Салихович**, журналист, главный редактор судии «Дөнья» Исполкома ВКТ.

**Валеева Гульнафис Айратовна**, ведущая, певица, лауреат международных конкурсов.

**Габбасова Рамзия Илдусовна**, председатель правления ОО РНКАТ УР, главный редактор газеты «Яңарыш», член Общественного совета по вопросам межнациональных отношений при Главе Удмуртской Республики.

**Гайсаров Фанур Шарифуллович**, главный редактор газеты татар Оренбургской области «Яңа вакыт».

**Галяутдинов Идеал Мусинович**, активист татарского движения, советник президента Самарской региональной организации «Дуслык», полковник в отставке, журналист, автор книг.

**Гарифуллин Ильнар Зульфатович,** историк, политолог, кандидат исторических наук, web-редактор журнала «Туган җир. Родной край».

**Гатауллин Ринат Файзлтдинович**, доктор экономических наук, профессор, ИСЭИ УФИЦ РАН.

**Закиров Ринат Зиннурович**, советник Всемирного конгресса татар, председатель Исполкома ВКТ в 2002–2020 гг., доктор исторических наук.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, главный редактор журнала.

**Канапацкая Зорина Ибрагимовна**, кандидат исторических наук, доцент Белорусского государственного педагогического университета им. Максима Танка, Республика Беларусь, Минск.

**Кутеева Ленара Раифовна**, начальник комитета по работе с общественными организациями татар стран ближнего и дальнего зарубежья Исполкома ВКТ.

**Минастинова Айгуль Ильязовна**, главный редактор новостного сайта Самарских татар «Татар-Дуслык».

**Миннемуллин Ильсур Гафиуллович**, председатель Татарского общественного центра Удмуртской Республики.

**Мусин Фаниль Зулькафирович**, главный редактор Параньгинской районной газеты «Наша жизнь», учредитель, издатель, редактор газеты «Якташлар», председатель Совета Татарского исторического общества Республики Марий Эл, председатель Параньгинского районного Общества историков-архивистов.

**Мухтасаров Фарит Шамилевич**, председатель Региональной татарской национально-культурной автономии Московской области, заслуженный работник культуры РТ.

**Назин Салим Назипович**, заместитель председателя национально-культурной автономии татар Пермского края, представитель Всемирного конгресса татар в Пермском крае.

**Рашитов Фрид Айниевич**, доктор исторических наук, профессор.

**Сайганова Розалия Магариповна**, член редколлегии газеты «Татар дөньясы», член Совета Омской местной татарской национально-культурной автономии «Ибирь».

**Тагиров Индус Ризакович**, доктор исторических наук, профессор, академик АН РТ, заслуженный деятель науки РТ, общественный деятель, председатель Исполкома ВКТ в 1992–2002 гг.

**Тычинских Зайтуна Аптрашитовна**, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

**Файзуллина Дания Ильдусовна**, корректор журнала, заслуженный работник печати и массовых коммуникаций РТ.

**Шакиров Амир Толгатович**, председатель Совета ОО «РНКАТ РМЭ».

**Шамильоглу Юлай**, профессор Университета Назарбаева (Казахстан) и Университета Висконсин-Мэдисон (США).

# ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- *методика и методология историко-краеведческих исследований;*
- *история краеведения и историко-краеведческое наследие;*
- *проблемы региональной истории;*
- *новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;*
- *публикация источников;*
- *история конкретных сел и деревень;*
- *история музеев и публикация музейных коллекций;*
- *жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;*
- *использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;*
- *популярные статьи по краеведению;*
- *краеведческая хроника (конференции, встречи и т. д.);*
- *рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.*

*Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:*

***Технические требования к оформлению статей***

*1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом* [Аминов: 2017. С. 82.]; [Денисов: 2012. С. 25; Черкас: 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф. 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]

*2.* Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

***Источники и литература***

1. Аминов Р.Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.

*2.* Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.

3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.

4. Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.

5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению****:*

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате .doc или .docx;
2. А4;
3. Поля: слева – 3 см., справа – 1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа;
4. Шрифт – Times New Roman;
5. Размер шрифта – 14;
6. Межстрочный интервал – 1,5;
7. Абзацный отступ – 1,0.

***Требования к иллюстративным материалам***:

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

***Сведения об авторе:***

1. Фамилия, имя, отчество ____________________
2. Ученая степень ____________________
3. Ученое звание ____________________
4. Занимаемая должность ____________________
6. Почтовый адрес с индексом ____________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________
8. Контактный телефон ____________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии она в случае соответствия всем требованиям передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край».

# Туган җир

*Төбәк тарихы буенча журнал*

# Родной край

*Краеведческий журнал*
2’2022

Электронная версия журнала размещается:
http://tuganzhir.org

Подписано в печать 05.06.2022 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 999 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



Татар Иҗтимагый Үзәге Оештыру съездының Идарә әгъзалары. Татар дәүләт академия театры. Казан. I7-I8 фев.I989ел.



*Республикакүләм фәнни-гамәли конференция. Әлмәт*



*Беларусь Республикасы татарлары*



*Удмуртия Республикасында «Татарча диктант» язу*




*Самара шәһәре татар хатын-кызлары оешмасы*




*Тубыл шәһәре себер татарлары милли-мәдәни мохтарият Советы әгъзалары Тубыл районы Епанчино авылында*



*«Боз озату» йоласы. Омск*




*Сабантуй бәйрәме. Мәскәү өлкәсе*

**Милләттәшләребезне милли бәйрәмнәребез белән котлыйбыз!**



**И туган тел, и матур тел
Әткәм-әнкәмнең теле…**